Икенче тематик юнәлештә Тукай иҗаты татар әдәбият белеме мәсьәләләре белән бәйләнештә, гомуми, проблематик планда карала. Ягъни Тукайның сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләре, аның лирикасы, жанрлары, иҗат методы, ысулы, стилистик алымнары, шулай ук дини-әхлакый карашлары игътибар үзәгендә тора, халыкчанлык, миллилек һ.б. мәсьәләләр тикшерелә.

Өченче тематик юнәлештә сүз шагыйрьнең бабалары, ата-анасы, кан-кардәшләре, иптәшләре, дуслары, танышлары, замандашлары, укытучылары, шәриктәшләре турында бара, әмма барлык төр мәгълүматларның Тукайга мөнәсәбәтлеләре генә бирелә.

Дүртенче тематик юнәлештәге язмаларда Тукай иҗаты татар әдәбияты белән бәйләнешләре яссылыгында шәрехләнә. Мәкаләләрдә Тукайның урта гасырлар төрки-татар әдипләре иҗатына мөнәсәбәте, замандаш язучылары белән реаль тормышта һәм иҗат мәйданында “очрашуы”на нисбәтле яклар, Тукай шәхесенә, иҗади мирасына, традицияләренә үзенчәлекле фикер-карашларын гәүдәләндерелгән әсәрләр турында сүз бара.

Бишенче тематик юнәлешнең мәкаләләрендә Тукайның татардан тыш дөнья белән бәйләнеше шәрехләнә. Алтынчы тематик юнәлеш буенча язылганнарында Тукай шәхесе һәм иҗатының татар сәнгатенең төрле юнәлешләрендә – театр, телевидение, кино, сынлы, декоратив, һәм музыка сәнгатендә яктыртылуы тикшерелә. Җиденчесендәге мәкалә һәм

белешмәләрдә Тукайның тәрҗемә хәле һәм иҗаты белән бәйле урыннар турында сөйләнә. Сигезенче тематик юнәлешкә Тукай фәненә өлеш керткән татар галимнәренең эшчәнлеген яктырткан мәкаләләр керә.

Димәк, гыйльми басмаларның иң югары ноктасы булган энциклопедия күренекле шагыйрь Г. Тукай фәнни биографиясен һәм киңкырлы рухи мирасын халкына ирештерүдә һәм аларны әдәбият белеме ирешкән казанышлар ноктасыннан шәрехләүдә җитди адымнарның берсе булып тора.

**Әдәбият**

1. Габдулла Тукай. Энциклопедия. – Казан: Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. – Б. 6–8.

2. Габдулла Тукай. Энциклопедик сүзлек-белешмә (мәкаләләр һәм белешмәләр исемлеге). – Казан, 1998. – 78 б.

3. Гыйлаҗев Т.Ш. Габдулла Тукай. Энциклопедия. – Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 861 б., илл. б-н) басмасына бәяләмә // TATARICA. - 2017. – №2 (8). – Б. 200–204.

4. Тукай Г.М. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда: 4 т . – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 431 б.

## КУЛИНАРИЯ ТЕКСТЛАРЫ ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ ТРАНСЛИТЕРАЦИЯ АЛЫМЫ

*Миннекеева А., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Р.С. Нурмөхәммәтова*

Соңгы елларда тел гыйлемендә кешегә юнәлтелгән лингвистик юнәлеш зур тизлек белән үсеш ала. Шуңа бәйле рәвештә әлеге фән тел фактлары белән генә эш итеп калмый, тарих, мәдәният, халыкның дөньяны күзаллавына да мөрәҗәгать итә. Телне антропологик юнәлештә өйрәнү кулинария, гастрономия өлкәсенә карата зур кызыксыну уянуга сәбәпче була. Татар ризык атамаларын җентекләп өйрәнүче галимә Р.С. Нурмөхәммәтова болай дип яза: “...татар халкының элек-электән килгән матди һәм рухи байлыгын үзләрендә саклап калган ризыклар күпсанлы. Бу ризыкларны әзерләү үзенчәлекләре һәм аларның атамалары буыннар тәҗрибәсен, татарларның тормыш итү рәвешен, андагы үсеш-үзгәрешләрне ачык чагылдыра” [3: 192]. Әнә шундый олы хәзинә тәрҗемә вакытында чит телгә милли үзенчәлекләрне, оригинал текстта башкара торган вазифаларын саклап бирелергә тиеш.

Бүгенге көндә кулинария текстлары социаль коммуникациядә иң киң таралганнар рәтендә. Ни дисәң дә, туклану культурасы, дөнья халыклары ментальлегенең әһәмиятле компоненты буларак, кешенең көндәлек тормышының аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Әмма ул халыкның элек-электән килгән традицияләре нигезендә генә яшәми, башка халыклардан да бу өлкәгә күпсанлы ризыклар үтеп керә. Әлбәттә, аларны әзерләү тәртибе тәрҗемә текстларда бәян ителә.

Татар милли ашлары да күп халыкларда кызыксыну уята. Моңа көннән көн ныграк үсеш ала барган туризмның да тәэсире зур. Шул сәбәпле бу эштә татар ризыклары рецептларын рус теленә тәрҗемә итүдә күзәтелгән лексик үзенәлекләрне барлау максат итеп куелды. Чыганак буларак Ю.Ә. Әхмәтҗановның “Татар халык ашлары” (1999) җыентыгы һәм аның рус теленә тәрҗемәсе (“Татарские народные блюда”, 2000) хезмәт итте.

Мәгълүм булганча, тәрҗемә метод-алымнары тәрҗемә ителә торган текстның тематикасы һәм жанрына бәйле төстә сайланалар. Кулинария текстлары, үзләрендә төрле ризыклар әзерләү буенча рецептларны колачлаучы белешмәлектән гыйбарәт. Кулинария лексикасы исә, шушы өлкәгә караган барлык лексемаларны колачлаучы тел катламы.

Тикшеренүләр барышында татар кулинария текстларын тәрҗемә итүнең төп ысуллары буларак транскрипция һәм транслитерация алымнарының кулланылыш үзенчәлекләре ачыкланды, татар кулинария текстларын тәрҗемә итүдә калькалаштыру һәм лексик алыштырулар очраклары өйрәнелеп, аларның үзенчәлекләре билгеләнде, татар кулинария текстларын рус теленә тәрҗемә итүдә төшереп калдыру һәм өстәү алымнары кулланылышы анализланды.

Кулинария текстлары тәрҗемәсендә транскрипция һәм транслитерация алымнары, гомумән, башка төр тәрҗемәләргә дә хас булганча, еш кулланыла. Шуңа күрә кулинария текстларының тәрҗемәсен нәкъ шушы алымнарның кулланылыш үзенчәлекләрен барлаудан башлау максатка ярашлы дип уйлыйбыз. Тәрҗемәдә алар аерым-аерым да куланылалар, шул ук вакытта бер-берсен тулыландырып та киләләр. Галимнәр фикеренчә, “хәзерге вакытта тәрҗемә итү практикасында әйдәп баручы ысул булып транслитерация элементлары белән транскрипция санала” [4: 93].

Безнең татар-рус тәрҗемәсе очрагында, татарлар да, руслар да хәзерге вакытта кирилл графикасы белән эш итүгә карамастан, алфавитта татар хәрефләре белән рус хәрефләренең тулаем тәңгәл килмәве (мисал өчен, татар алфавитында рус телендә булмаган хәрефләр булу, кайбер хәрефләрнең ике авазга билге булып йөрүе) алда әйтелгән ысулны куллануга китерә. Мисалларга мөрәҗәгать итеп үтик. Чыгышлары белән рус-европа алынмалары булган сүзләр кулланылган барлык очраклар да транслитерация алымы белән биреләләр, аңлашыла ки, бу алынмалар ике телдә дә бердәй языла, бердәй яңгырый: *Шундый итне **рулет** рәвешендә төрәләр дә, **колбаса** бәйләгән кебек, бау белән бәйләп, пешәр-пешәмәс итеп табада кыздыралар* [2: 39].

Тәрҗемәдә: *Приготовленное таким образом мясо завертывают в виде **рулета**, перевязывают шпагатом, как **колбасу**, и жарят на сковороде до полуготовности* [1: 24].

*1 өлешкә: 110 г* ***помидор,*** *30 г каймак, тоз һәм борыч* [2: 13].

*Шушы җөмләнең тәрҗемәсен карыйк:* ***Помидоров*** *неочищенных – 100 г, сметаны – 30 г, соль, перец* [1: 10].

Татар һәм рус телләрендәге уртак алынма берәмлекләр тәрҗемә процессында иң җиңел очрак. Әмма кулинария текстларында реалияләр булу табигый, аларның икенче телдә эквивалентлары юк, шунлыктан кайбер сүзләрнең язылышларында, әйтелешләрендә үзгәлекләр килеп чыга. Мәсәлән, эшебездә *калҗа – калжа, пәрәмәч – перемяч, пәхләвә – пахлава, чәкчәк – чакчак* кебек очраклар теркәлде. Бу мисалларда татар хәрефләрен рус язуына күчергәндә күпмедер дәрәҗәдә закончалыклы фонетик тәңгәллекләрне күзәтергә мөмкин.

Гомумән алганда, татар тел белемендә кулинария текстларына фәнни игътибар көчәйгәннән-көчәя бара. Бүгенге көндә кулинария текстларын тәрҗемә итү проблемасы да алгы планга чыга. Кулинария текстлары миллилекне дә чагылдыра, үз эчләренә этник, мәдәни, иҗтимагый-дини үзенчәлекләрне дә ала. Димәк, аларны өйрәнү һәм тәрҗемә итү – заман ихтыяҗы.

**Әдәбият**

1. Ахметзянов Ю.А. Татарские народные блюда. – Казань: Раннур, 2000. – 408 с.

2. Әхмәтҗанов Ю.Ә. Татар халык ашлары. – Казан: Раннур, 1999. – 464 б.

3. Нурмөхәммәтова Р.С. Кайбер татар ризык атамаларына лингвомәдәни күзәтү // Язык – культура – этнос. – Казань: Отечество, 2013. – Б. 192-198.

4. Салимова Д.А., Патенко Г.Р. Антропонимия романов Д.И. Стахеева. – Елабуга:, 2008. – 100 с.

## БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯРМӘКӘЙ РАЙОНЫ АБДУЛЛА АВЫЛЫ ТОПОНИМИКАСЫ

*Миннибаева А., М Акмулла ис. БДПУ, II курсы студенты*

*Фән. җит. – филол.фән. докт., проф. И.С. Насипов*

Һәр авылның үз тарихы, үз атамалары бар. Халык авылның урам-тыкырыгына, кое-чишмәсенә, елга-күленә, тау-калкулыгына, ялан-басуына, урман-болынына бик матур исемнәр биргән. Бу исемнәр (билгеле бер торак пунктның ялгызлык атамалары системасы микротопонимнар дип атала), буыннан-буынга күчә барып, зур үзгәрешләр кичереп, бүген безгә килеп җиткәннәр. Шуңа күрә алар бик кыйммәтле мәгълүматларны хәбәр итә торган әһәмияте чал тарих хәбәрчеләре булып саналалар.

Бу кечкенә хезмәттә мин Абдулла авылы топонимикасының кайбер берәмлекләренә игътибар итеп узасым килә. Авыл урнашкан җирләрнең матурлыгы, гүзәллеге һәркемне сокландыра. Ирексездән, авылга беренче килеп утрыган кешеләр бик зәвыклы, матурлыкны, гүзәллекне аңлый, ярата торган кешеләр булгандыр, дигән фикер туа. Чыннан да, авыл төньяктан көньякка сузылган, көнчыгыш яклап

ярымдуга рәвешендәге тау тезмәләренә сыенган, шуңа да ул үзе дә дуганы хәтерләтә. Авыл Башкортстанның Ярмәкәй районының төньяк-көнбатыш өлешендә Ык елгасының уң як ярында, Татарстан белән чиктәш җирдә утыра. Аны Ык елгасы Татарстан Республикасының Баулы районы җирләреннән аерып тора. Иң якыны тимер юл станциясе 58 км ераклыкта Туймазы шәһәрендә, иң якын шәһәр – Октябрьский 40 км ераклыкта урнашкан.

Тарихи документлар буенча, Абдулла авылы, Колбай, Рәтамак, Иске Шах, Суккул авыллары белән беррәттән, Ярмәкәй районының иң борынгы торак пункты булып санала. 1737 елда чыгарылган Уфа провинциясе картасында авыл беренче телгә алына. Бу вакыттан санасак, инде 278 ел узган. Ә инде әлеге картаны әзерләп чыгаруга киткән вакытны да исәпкә алсак, авылга 280, ә бәлки 300 ел, дип фаразларга мөмкин. Болары бер чыганаклар буенча. Ә Ярмәкәй районың энциклопедиясендә түбәндәгечә язылган: “XX гасырның 80 нче елларында авыл янында бура (б.э.к. II мең, бронза гасыр) табылган». Димәк, авыл утырган җирләрдә моннан 4 мең еллар элек үк кешеләр яшәгән. Кемнәр алар – башка мәсьәлә. Моңа таянып без, Абдулла авылы кебек җирләр археологик яктан да начар тикшерелгән, дип әйтә алабыз.

Авыл зур булмаганлыктан, бүген бер үзәк урамнан һәм ике тыкрыктан тора. Авыл урамнарының исемнәрен өлкән буын кешеләре хәзер дә элеккечә атап йөртәләр: *Югары оч* урамы (хәзер - *Чишмә* урамы), *Түбән оч* урамы (*Төньяк* урамы), *Гагарин* урамы (*Тау* урамы). Соңгы икесе тыкырык булсалар да, урам дип атап йөртелә.

Авылда бер чишмә бар. Аны *Урта оч* чишмәсе (*Төп чишмә*) дип атыйлар. Чишмә авыл уртасында, Рауза апа йорты янында урнашкан. Шуңа аның тагын бер исеме – *Рауза әби* чишмәсе. Бу искиткеч чишмәгә багышлап авылыбызның үзәк урамы аталган.

*Эндәш күле*. Исемнең килеп чыгышы турында авыл халкы мондый риваятьне сөйли. Кайчандыр күл бик тирән булган, аның ярында шомырт һәм баланнар үсеп утырган болын булган. Бервакыт болынга бер хатын кечкенә кызы белән балан җыярга килгән. Ана балан җыюга бик бирелеп китеп, кызы югалуын сизми дә калган. Ул бик озак аны эзләгән. “Эндәш инде, кызым,” – дип күл тирәли дә, болын буйлап та кычкырып йөргән. Бөтен авыл халкы белән дә эзләп карасалар да, кыз табылмаган. Берәүләр, кыз соңырак табылган, ди, ләкин бу тикшерелгән мәгълүмат түгел. Чынмы, фаразмы, әмма шул вакыттан бирле күлне *Эндәш күле* дип атый башлыйлар.

*Тирмәнчек тавы*. Бу тауның исеме элек-электән килә. Имеш, кайчандыр башкортлар биредә тирмәләр (чатырлар) корып ял иткәннәр.

Бу сүздән тауның исеме барлыкка килгән. Тау Ык елгасының уң як ярында урнашкан. Биеклеге 20-30 м кадәр җитә.

*Тирмәнче тавы* авыл халкының иң яраткан җире. Бередән күзәтү бик яхшы, бөтен авыл һәм тирә-юнь күренеп тора. Яз көне авыл халкы таудан боз китүен күзәтергә ярата. Тауның атмасы аның итәгендә элекке чорда тирмән утырган булуга бәйле.

*Бүләк* урманы авылның көнчыгыш ягында – Ык елгасының төп үзәне итәгендә Абдулладан 600–700 метр ераклыкта урнашкан. Авыл картлары сүзләренә караганда, бу урман бер бай белән икенче байга бүләк ителгән, шуңа *Бүләк* исемен алган, имеш.

*Баллы чишмә*. Авылга иң якын урнашкан чишмә. Атамасы суның татлы, баллы һәм салкын булуына бәйле кушылгандыр.

Мин биредә эле берничә генә атамага тукталдым. Ә алар безнең авыл җирлегендә бихисап. Топонимик атамаларның аталу тарихын өйрәнү – туган якның тарихын өйрәнү дигән сүз. Алар гасырлар буена тупланып килгән рухи мирас ул. Аларда халкыбызның тарихи үткәне, тормыш-көнкүреше, һөнәрләре, изге, игелекле, ярдәмчел якташларымның исемнәре чагылыш тапкан. Ә туган якны төрле яктан өйрәнеп, без үзебезнең тамырларыбызны барлыйбыз.

Без, яшь буын, туган ягыбызның киләчәге өчен җаваплы кешеләр. Туган төбәгебезнең тарихын җентекләп өйрәнеп, эш-гамәлләребезне аның табигатенә зыян китермәслек итеп оештырырга тиешбез. Шулай булганда гына без сәламәт һәм бәхетле кешеләр булырбыз, бездән соң килгән буынга бай табигый мирас калдырырбыз. Безнең ата-бабаларыбыз безгә авылларны, шәһәрләрне, аралаша торган телебезне, мәдәниятебезне калдырганнар, һәм без аларны сакларга тиешбез.

**Әдәбият**

1. Асфандияров А.З. История сел и деревень Республики Башкортостан и сопредельных территорий. – Уфа: Башкир. кн. издательство, 2009. – 744 с.

2. Давлетбаев Р.Р, Хасанова О.М., Хасанов М.М, Хасанов А.Ш. Абдулла авылы тарихы. – Уфа: Китап, 2017. – 244 б.

3. Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1992.

4. Саттаров Г.Ф. Туган җирем, туган авылым // Мәгариф. –1996. – №11.

## МАТУР ӘДӘБИЯТ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЧАГЫШТЫРУЛАРНЫ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

(Г. Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» әсәре материалында)

*Мисбахова С., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Ф.Р. Сибгаева*

Әдәби әсәрләрдә автор геройларның эчке кичерешләрен тирәнрәк ачу, чынбарлыктагы вакыйгаларның һәм табигать күренешләренең нечкәлекләрен тулырак сурәтләү максатыннан төрле сурәтләү

чараларыннан файдалана. Мәсәлән, чагыштырулар. “Әдәбият белеме сүзлеге”ндә “чагыштыру – нинди дә булса күренешне башка күренешкә охшату ярдәмендә барлыкка килгән сурәтләү чарасы” дип күрсәтелә [1: 191]. Чагыштыру сөйләмнең образлылыгын көчәйтә, кешене яки күренешләрне җанлырак итеп тасвирларга ярдәм итә. Язучы әлеге сурәтләү чарасын кулланып укучыларның кузаллавы көчәюгә йогынты ясый һәм әсәргә аһәң өсти.

Чагыштыруларда ике тышкы күренеш янәшә килә, ягъни бу очракта охшату аркылы объектны предметлаштыру күздә тотылмый, язучы аңа күргәзмәлелек бирү белән чикләнә. Күренешләрне предметлы, конкрет кыяфәттә күз алдына китерү өчен, әдипләр тышкы әйберләр ярдәменә мөрәҗәгать итәләр, һәм шул рәвешле, алар арасына сәнгатьчә бәйләнеш җепләре сузыла [6: 96].

Татар телендә чагыштырулар *-дай/-дәй, -ча/-чә, -рак/-рәк, -чай/-чәй* аффикслары; сыман, кебек, шикелле, төсле бәйлекләре; бәйлек ролендә килгән сүзләр буларак дәрәҗә һәм рәвеш; (бул, ит) ярдәмче фигыльләре; (әйтерсең лә, гүя һ.б.) теркәгечләре һәм мөнәсәбәтле сүзләр аша белдереләләр.

“Теоретик чыганаклардан мәгълүм булганча, төп һәм тәрҗемә текстлары арасындагы тәңгәллек тел һәм сөйләм билгеләренә карап төркемләнә. Тәрҗемәче эш барышында әзер тәңгәллекне алып, я берничә варианттан берсен сайлап алу юлы белән, яки тел закончалыкларына таянып, үз тәңгәллеген тудыру аша, яисә җөмлә төзелешен, сүз сөрешен үзгәртеп тә тәрҗемә итә ала” [2: 3].

Без Г. Яхинаның «Зулейха открывает глаза» әсәрендә һәм аның Ф. Тарханова тарафыннан татар теленә тәрҗемәсендәге чагыштыруларны түбәндәге алымнар буенча карадык:

*1.* Үзгәрешсез тәрҗемә ителгән чагыштырулар: *Темно, **как** в погребе* [5: 9]. *– Баздагы **кебек** караңгы* [4: 5].

*– Иней на березовых ветвях, тонких и длинных, **как** женский волос* [5: 17]. *– Хатын-кыз чәче **төсле** нечкә һәм озын каен ботакларын бәс сарган, көртләр юан-юан буй өемнәр кебек тезелешеп киткән* [4: 14].

*– Щепа брызжет, **как** слезы* [5: 19]. *– Йомычкалар күз яше **кебек** төрле якка чәчрәде* [4: 16].

*– Сидит **как** не на коне – на троне* [5: 91] *– Атта түгел, тәхеттә утырган **кебек** кылана бит* [4: 89].

*– Тело двигается, дышит, но **словно** не свое* [5: 102]. *– Гәүдә хәрәкәттә, сулый, тик үзеңнеке түгел **төсле*** [4: 101].

*– Глаза видят, но **будто** сквозь завесу* [5: 102]. *– Күзләр күрсә дә, ниндидер пәрдә аша гына караган **кебек*** [4: 101].

*– Мысли в голове до сих пор – тяжелые, неповоротливые, **как** хлебное тесто* [5: 102]. *– Баштагы уйлар хәзергә кадәр авыр, ипи камыры **кебек** басынкы* [4: 101].

*– Зулейха бредет по улице против ветра, наклонившись вперед низко, **как** в молитве* [5: 24]. *– Зөләйха, башын дога укыгандагы **кебек** аска иеп, җилгә каршы урам буйлап бара* [4: 21].

*– В сенях холодно, **как** на улице, - кожу щиплет, рубаха не греет* [5: 11]. *– Өйалдында урамдагы **кебек** салкын – тәнне чеметтерә, эчке күлмәк җылытмый* [4: 7].

*– А ползком она прошмыгнет, веса в ней – всего ничего, Муртаза одной рукой поднимает, **как** барана* [5: 12]. *– Мортаза аны бәрән күтәргән **кебек** бер кулы белән генә күтәреп йөртә* [4: 8].

2. Гади бер сүз белән тәрҗемә ителгән чагыштырулар, ягъни конпенсация ысулы ярдәмендә белдерелгән тәрҗемә һәм гыйбарәләр. Бу очракта тәрҗемә телендә кулланылган чара, гади сүз яки сүзтезмә белән тәрҗемә ителә:

*– Уши – слышат, но **как** издалека* [5: 102]. *– Колаклар да ишетә, әмма һәр аваз ерактан килгән тавыш булып кына керә* [4: 101].

*– Да как вообще можно одним и тем же словом выражать свое отношение к таким разным величинам – **словно** класть на две чаши весов какую-то бабу и Революцию* [5: 95]? *– Бу бит, үлчәүнең бер тәлинкәсенә – ниндидер хатынны, ә икенчесенә революцияне куясың, **дигән сүз*** [4: 93].

*– И лицо бледное, нежное – **словно** бумажное* [5: 92]. *– Бите дә ап-ак, үзе нәфис – ак кәгазьдән ясалган **дип белерсең*** [4: 90].

3. Чагыштыру объектын төшерелеп калдырылган очраклар: **–** *Спустя пару лет была слепа и глуха, **как** камень* [5: 11]. *– Ике елдан бөтенләй сукырга һәм чукракка әйләнде* [4: 7].

4. Чагыштырыла торган күренешләрнең грамматик формасы үзгәрү. *– Тот сам виноват – кинулся с топором как бешеный* [5: 92]. *– Котырып, балта белән безгә ташланмасын иде* [4: 90].

*– Кусистые брови сдвинуты к переносице, морщины на мятых со сна щеках глубоки, словно вырезаны ножом* [5: 15]. *– Куакланып беткән кашлары борын тирәсенә җыерылган, йокыдан изелеп беткән яңакларындагы җыерчыклары тагын да тирәнәйгән, әйтерсең лә пычак белән ярып чыкканнар* [4: 11].

5. Алмаштырып тәрҗемә итү: *–…Сумлинский **как** в воду глядел* [5: 342]. *–…Сумлинский алдан сизенгән булып чыкты* [4: 351].

Г. Яхинаның «Зулейха открывает глаза» әсәрендә чагыштырулар киң чагылыш тапкан. Әдип әсәрдә матур эчтәлекле, образлы сурәтләү чараларын бик мул кулланган. Тәрҗемәче исә, үз чиратында, чагыштыруларны күбесенчә үзгәрешсез тәрҗемә иткән. Әлеге ысул бик

актив кулланылышта, ләкин шулай да, чагыштыруларны башка алымнар белән тәрҗемә итү дә күзәтелә. Тәрҗемә вакытында нигездә чагыштырулар уңышлы башкарылган. Алар исә әсәрдәге образлылыкны көчәйтә.

**Әдәбият**


1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Денмухаметова Э.Н. Отражение этнокультурного материала в переводных текстах (на примере сравнений в произведениях А. Гилязова) [Электронный ресурс] // Современный мусульманский мир: электрон. журнал. – 2019. – № 2.
3. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2001. – Б. 312.
4. Яхина Г.Ш. Зөләйха күзләрен ача. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 511 б.
5. Яхина Г.Ш. Зулейха открывает глаза: роман – М.: Издетельство АСТ, 2018. – 508 с.
6. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: Раннур, 2002. – 252 б.


## КЕРӘШЕН ХАЛКЫНЫҢ ЙОЛА, БӘЙРӘМНӘРЕНӘ КАГЫЛЫШЛЫ СЫНАМЫШЛАР


*Михайлов А., Казан, 181 нче мәктәп, X сыйныф*

*Җит. – Ә.Ф. Вәлиуллина*


Без, әнием һәм әтием, Питрәч районында туып Казанда яшәүче керәшеннәр булабыз. Төбәгебездә татарлар һәм керәшеннәр бер милләт булып яшиләр, чөнки телләребез бер, тик диннәребез генә төрле. Керәшеннәр христиан динен тоталар. Керәшеннәрдә яшәп килгән иҗтимагый йола һәм бәйрәмнәрен үткәрү вакыты христиан календаре бәйрәмнәренә туры китерелгән. Аларның исемнәре татар теле үзенчәлекләренә яраклаштырып, русча йөртелгән. Шуңа күрә керәшен татарларының бәйрәмнәре рус халкыныкына охшаш. Ә йола, гореф-гадәтләре башкача. Соңгы елларда халкыбызның туган җиренә, үткәненә, мәдәниятенә игътибары арткannan-арта бара. Бу үзгәреш йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрне үткәрүгә, онытылганнарын торгызуга һәм яңартуга китерә.Буыннан-буынга күчеп килгән, бу рухи байлыкларыбыз бүгенге көннәрдә дә безнең тормышыбызның, яшәешебезнең бизәге булып тора. Эзләнү эшемә итеп” Керәшен халкының йола, бәйрәмнәренә кагылышлы сыналмышлар” дигән теманы сайладым. Мин кечкенәдән үк әбием янына авылга кайтып йөрдем. Әбием аяклы энциклопедия; белмәгән йоласы, җыры юк. Халыклар дуслыгы йортында да алар бик еш кунак булалар. Әбием, әнием сөйләгән, авылда күргән бәйрәм, йолалар мине дә битараф калдырмады. Берничә ел мин Галина Казанцева җитәкләгән **“Айбагыр**” фольклор ансамблендә шөгыльләндем. Буш вакытымда театрга, концертларга йөрергә яратам. Татар теле дәресләрендә еш кына мәкаль , сынамыш, әйтемнәргә тукталыла. Дәрестә “Татар халык аваз иҗаты” китабы белән танышкач миндә андагы сынамышларны аерып карыйсы

килде. Без еш кына ул сынамышларны ишетәбез, ләкин аларның керәшен халкының йола, бәйрәмнәре белән бәйле икәнен күп кеше бәлкем, белмидер... Бу эшемдә мин Питрәч районы Әлбәдән авылында яшәүче әбием авызыннан ишеткән сынамышларны яздым. Минем иң яраткан керәшен халык бәйрәме – Питрау бәйрәме. Хезмәтемдә мин аңа бераз гына тукталырмын.

Керәшеннәрдә ел фасылларына караган, табигать күренешләренә бәйле рәвештә үткәрелә торган төрле йолалар, гореф-гадәтләр бик кызыклы. Борынгыдан килгән ышануларга нигезләнгән йолалар, күмәкләп, бөтен авыл халкы катнашында үткәрелә торган булган. Элекке гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, мәсәлән, нардуган уеннары, бәрмәнчек, тройсын яки каен башы бәйләү (“яфрак бәйрәме” дип әйтелә), питрау һәм башка бәйрәмнәр үзенчәлекле җырлар, такмаклар белән уздырыла торган булган. Христиан бәйрәмнәре итеп чиркәү календаре буенча уздырылса да, аларда динилек бөтенләй диярлек чагылмый, күбрәк борынгыдан килгән халык йолалары өстенлек алган. Кызганычка каршы, ул борынгы йолалар һәм йола җырлары хәзерге вакытта онытылып баралар, аларның матурларын яңартып, авылларга ямь өсти торган итеп, халыкка кире кайтару зарурлыгы нык сизелә хәзер.

**Кышкы Микулыга халык сынамышлары:**

Кышкы Микулы нинди булса, җәйге Микулы да шундый була.
Микулыдан каты салкыннар башлана.
Микулада буран булса, кыш буе буран бала.
Микулыга каршы бәс булса, солы яхшы уңа.
Микулыда бәс булса, барлык игеннәрдә яхшы үсә.

**Раштуа (Рождество)га сынамышлар:**

Бу көнне кар яуса, иген уңышы мул була.
Өй кыегыннан кар ятса, арыш хәм печән биек булып үсә.
Көн җылы булса, ашлык куерып үсә.
Буран булса,умарта оясы яхшы аера.
Раштуа яңа айга туры килсә, ашлык уңышы начар була.
үткәрергә тырышалар.

**Май чабуга карата халык арасында йөри торган сынамышлар**:

Май чабу алдыннан килгән якшәмбедә көн бозылса, җәй көне гөмбә күп була.

**Язгы Микулы сынамышлары:**

Микулыдан соң 12 тапкыр кырау була.
Микулы көнне бакалар кычкырса, солы уңа.
Микулыга кадәр карабодай чәчәргә, сарык йонын алырга ярамый.

**Питрау сынамышлары:**

Питрау үтә-җәй үтә.
Питраудан соң кошлар да сайрамый.
Питраудан соң сандугачның теле бетә, үләннең тәме бетә.

Булса аяз Питрау көн-булыр яшел печәнең, яңгырлы булуыкырда печән черүе.

Әгәр Питрауга бер атна кала күке кычкырудан туктамаса, көз тиз килер, Питрау үткәч тә бер атна кычкырса-озак булыр.

**Элҗен сынамышлары**:

Элҗен җәйне тәмамлый.

Элҗендә көн ике сәгатькә кыскара.

Элҗендә сары яфраклар күбрәк күренә башлый.

Элҗендә көн ничек булса, 27 сентябрьдә шулай була.

Элҗеннән башлап төшкә кадәр җәй, төштән соң көзгә тарта.

Элҗеннән соң яңгырлар еш ява.

**Соңгы Спас сынамышлары:**

Беренче Спаста карлыгачлар җылы якка күченеп китә башлый.

Беренче Спаста салкын чык төшә.

Урта Спастан соң төннәр салкын була.

Урта Спаста сабан ашлыгы өлгерә.

Әгәр дә торналар соңгы Спаста китсәләр, Покраууда (11 октябрь) салкын була.

**Көзге Көҗмә-Демьян сынамышлары***:*

Көҗмә-Демьянда көн карлы булса, яз көне су җыела.

Агачлардан яфрак коелмаса, киләсе ел салкын була.

Көҗмә-Демьян кадак кага, Микулы күпер сала.

Борынгыдан килгән йолаларыбыз, гореф-гадәтләр инде онытыла, юкка чыга баралар дип әйтсәк тә, әле халкыбызның хәтерендә, өлкән буын кешеләренең телендә бик күп истәлекләр, тел һәм рухи байлыгыбыз саклана. Керәшен фольклоры – бик борынгыдан килә торган культура катламы ул. Гасырлар дәвамында табигатьтәге еллык үзгәрешләргә, бабаларыбызның хуҗалык эшләренә һәм тормыш-көнкүрешенә бәйле рәвештә күп төрле йолалар барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчеп камилләшкән, искергәннәре кулланыштан чыккан. Хезмәтемдә әбием сөйләгән сынамышларны язып ,аларны сынап карау теләге уятты. Соңгы еллардагы табигатьтәге үзгәрешләр генә бу теләгемә ирешергә комачаулар төсле... Мин халкымның йолаларын өйрәнүне дәвам итәрмен дип уйлыйм .

**Әдәбият**

1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен д-лек. – Казан: Мәгариф, 2008. – 48 б.

2. Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. – Казан: Матбугат йорты, 1997. – 937 б.

3. Рамазанова Д.Б. Говоры татар среднего Прикамья: Автореф. дис. канд. филол. наук. – Казань, 1970. – 60 с.

## ҚАЗАҚ ТІЛІ ТЕРМИНОЛОГИЯСЫНЫҢ ҚАЗІРГІ ЖАҒДАЙЫ

*Мойнакова А., «Тұран-Астана» университеті, ІІ курс студенті*
*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд., доц. В.А. Шнайдер*

Терминология – саналы икемдеуге және реттеуге оңай көнімді лексиканың ерекше секторын құрайтын, өндірістің, қызметтің, білімнің сапасындағы терминдердің жиынтығы [1: 12]. Яғни, осы жерден алынатын қорытынды белгілі бір кәсіпте,ұйымда,қызметте қолданылатын, нақты ұғым. Терминологияның тарихы әрине тереңде жатыр, өткен заманмен салыстырғанда қазіргі таңда интернационалды терминдер көбейіп, оларды қолданатындар аясы да өсіп жатыр. Себебі біздің елде үш тұғырлы саясат жүргізіліп жатқандықтан жастар қандай да болсын халықаралық терминді бірден қабылдайды, жастардың көпшілігі ағылшын тілін біліп, ол тілде еркін сойлегендіктен халықаралық терминнің пайда болуы жіне халық арасында кең қолданылуы таңқаларлық жайт емес. Әрине қазақ тілінің өзіндік бір ерекшелігін сақтап қалу үшін белгілі бір затқа атау(термин) берілді делік, бірақ ол сөзді халық еркін қабылдап, қолданысқа енгізе алады ма, жоқ па, ол біраз ойланарлық мәселе. Ал үнемі ағылшын, орыс тілдерінде айтылып жүрген сөздерді халық міндетті түрде қабылдай алады себебі оны онсыз да сол тілдерде күнделікті қолданады.

Қазіргі таңда термин мәселесі өте қатаң зерттеу мен қадағалауды талап етеді, термин мәселесін тек тілшілер ғана емес сонымен қатар басқа маман саласының аударып, оны қолданысқа енгізген де кездер болады. Ол сөздің тек айтылуын ғана емес жазылуына да мұқият қадағалау қажет. Қаламыздағы дүкен, сауда-саттық, ойын-сауық орталықтары т.б. сондай өз кәсібін ашып отырған азаматтар нені, қалай жазып жатқанына назар аудармайды. Сол сөздерді дұрыс деп, қолданып жүргендер қаншама...

50 өндіріс пен ғылым бағыты елімізде толыққанды жұмыс істеуі үшін, дәлірек айтсақ, мемлекеттік тілдің Қазақстанда толыққанды қызмет етуі үшін бізге кемінде 500 мың термин керек екендігі – дәлелдеуді қажет етпейтін шындық. Ашығын айтсақ, күні бүгінге дейін ресми түрде бекіткен термин саны әлі де жиырма-отыз мыңның әрі-бері жағында екенін ескерсек, бұған қоса, қазақ сөзжасамдық модельдеріне кереғар тәсілдермен жасалғандарын есепке алсақ, онда мемлекеттік тілімізді дамыту үшін біздің алдымызда көптеген қордаланған проблемалардың тұрғанын мойындағанымыз абзал [2: 56].

Яғни, осы жерде ескеретін мәселе терминология мәселесі әлі де көптеген жаңашылдықты, дамытушылықты және де күрделі өзгерістерді талап етеді.Біздің әліпбиіміз латынға ауысқан сәттен бастап термин мәселесі де бірінші орынға ауады, себебі әліпбиді үйренушілер қатары да көбеіп сол сітте жазу мен қолданылу мәселесі де алдыңғы орынға келіп тіреледі. Осы жерде, неге, деген сауал туындайды,себебі: латын әліпбиі

қолданысқа енген кезде қазақша жазылатын сөздерді қолдану күрделі болмас үшін, бәлкім сол қиындық тудыратын сөздер тобын интернационалды терминдермен ауыстырған жөн болар, сол кезде екі жақтан да кем қалмаймыз.

Терминдерді ресми бекітуге ұсыну мен бекіту, сондай-ақ олардың қолданысын орнықтыру жұмысында жүйелілік, сабақтастық жетіспейді. 90-жылдардан бастап терминқорымыздың ұлттық сипатын арттыру мақсатында кезінде орыс тілінен аударылмай өзгеріссіз қабылданған көптеген терминдердің қазақша баламалары жасалып, қолданысқа енгізілді. Олар жұртшылық санасына сіңіп, тілдегі қолданысы енді тұрақтай бастағанда сондай орынға бастаған атаулардың бірқатары қайта қаралып, бастапқы қалпына келтірілді. Мысалы: аукцион (90-жылдарға дейін) – бәссауда (2009) – аукцион (2014), гимн (90-жылдарға дейін) – әнұран (1992) – гимн (2014), музей (90-жылдарға дейін) – мұражай (1998) – музей (2014), процент (90-жылдарға дейін) – пайыз (2000) – процент (2018), принцип (90-жылдарға дейін) – қағидат (2000) – принцип (2014) және т.б.[3: 15]. Осындай халық арасында қолданылып та, қолданылмай да жүрген, немесе қарама-қайшылық туғызған сөздер қатары бұрын да болған, және ол болады да. Сол мәселе жайында дәлел келтіре отырып терминология саласымен айналысып жүрген Шерубай Құрманбайұлының еңбегін назарға ала отырып жоғарыда айтылған мысалдарды көрсеткен болатынбыз. Көріп отырғанымыздай аталған терминдер бірнеше жылдар бойы өзгеріске түсіп қолданылған, бірақ әлі күнге дейін қай нұсқа дұрыс, қай нұсқа бұрыс екендігін білмей, ойланып жүргендер қатары да біраз. Бекітілген терминдерді тұрақтандырып, оларды тіл тұтынушыларына, сала мамандары мен жұртшылыққа уақтылы таныстыру, қажет кезінде электрондық жүйелерден іздеп табу, тілдік қолданысқа енгізу тетігі жасалмаған. Осы жұмыстың жолға қойылмау салдарынан бүгінге дейін бекітілген 24 мың терминнің елеулі бөлігі ғылым тілінде кеңінен қолданылмайды. Мысалы, мына сияқты ресми бекітілген ішкіндік (гипоцентр), түтінтартқы (дымосос), қарымжы (задаток), майтұрақтылық (маслостойкость), айданды (дистиллянт) [3: 11]. Осы жерде ойландыратын мәселе электрондық жүйелерден іздеп табу мәселесі, барлығымыз білеміз қазір қарқынды түрде дамып жатқан технология заманы, дегенмен сол технологиялар қазақ ақпараттарын дұрыс уақтылы өңдеп, оның қолданылу аясын кеңейту мәселесі де қарастырылуды қажет етеді. Жоғарыда келтірілген қарымжы, айданды және т.б. терминдерді қолданып жүрген адамдар жоқтың қасы, тіпті бұл сөздердің баламаларының бар екенін білетін адамдар да саусақпен санарлық немесе жоқ деп айтса да болады.

Терминкомның енгізген сөздер қатары төмендегі сөздермен толыққан болатын:

*аударым – перевод, әдіснама – методика, әзірлеме – разработка, әлеует – потенциал, бағам – курс, бейін – профиль, бітімгер – миротворец, дiңмаңдайша – портик, жағдаят – ситуация, жүктеме – нагрузка, кептеліс – пробка, кешен – комплекс, кілтсөз – пароль, қасбет – фасад, қуғын-сүргін – репрессия, құжат – документ, құзырет – компетенция, майса – газон, оққағар – телохранитель, отшашу – фейерверк, рәсім – церемония, саябақ – парк, тағаттылылық – толерантность, таптаурын – стереотип, тапсырыс – заказ, таралым – тираж, тарихнама – историография, телім – участок, төлем – платеж, түптұлға – прототип, түсім – поступление, тікұшақ – вертолет, тінтуір – мышь, үнтаспа – кассета, ықпалдастық – интеграция, іскі – шприц.* Бұл терминдер арасында өзімізге таныс қолданылып жүрген сөздер де, және де жаңадан енген сөздер қатары да бар. Мысалы, іскі сөзі енгізілгенмен де, оны медецина саласында қолданылып жүрген қызметкерлер жоқ. Себебі ол сөз ашық түрде қолданылып, халық арасында жарияланған жоқ, сол себепті ол туралы ешкім білмейді де. Оны халық арасына жеткізетіндер біз, сондықтан осы мәселе жөнінде де сөз қозғауымыз қажет деп санаймыз. Әр терминді қолданысқа енгізбес бұрын оның өзіндік қағидалары болады. Ол қағида кезіндегі Ахмет Байтұрсынұлы, Құдайберген Жұбанов, Әбдуәли Қайдар сияқты ғалымдарымыз айтып кеткен болатын. Осы жерден ұғатынымыз, терминді енгізбес бұрын сол сөз,ұғым, мағына жөнінде қазақ тілінде болмаса өзге тілден баламасын алуымыз қажет,және сол ұғым қазақ тілі табиғатына сәйкес келу керек, яғни халық қабылдап, қолдана алатын деңгейге жеткізген сәтте ғана терминдер қатарына енгізуімізге болады. Сол сияқты академик Әбдуали Қайдар 11 принцип ұсынған. Ғалымның 11 қағидатының қайсысын алып қарасақ та барлық терминдерді қазақ тіліне икемдеп жасауды талап ететінін көріп тұрмыз, осы қағидаттары арқылы қазақ тілінің өзіндік ерекшелігін сақтап қалуды көздеген болу керек. Яғни байырғы қазақ лексикасын пайдалануды жөн көреді. Ахмет Байтұрсынұлының ойы болсын Әбдуәли Қайдардың ойын алсақ та, екеуі де қазақ тіліндегі тазалық үшін күрескендігін көре аламыз, оны әсіресе қазақ тілінде сол сөздердң ашатын сөз болмай қалған жағдайда ғана, басқа тілден алу керек деуінің өзінде қанша мән-мағына жатыр. Осы қағидаттарды қазіргі таңда назарға алсақ, қазақ терминологиясының жағдайы жақсарады деген сенімдеміз.

**Әдебиет**

1. Орысша-қазақша түсіндірме сөздік: Лингвистика. – Павлодар: Кереку. 2007. – 144 б.
2. Рухани жаңғыру: қазіргі қазақ терминологиясы. – Нұр-Сұлтан, 2019. – 258 б.

3. Құрманбайұлы Ш. Қазақ терминологиясы: зерттеулер, оқулық, сөздік, библиография. – Алматы: Арыс. 2014. – 256 б.

# UNDERSTANDING TEXT COMPLEXITY

*Mohamed Lamine Mariko, KFU, PhD student*
*Academic Adviser Dr. Gafiyatova E.V.*

Text complexity analysis is an important task in Education for it can help teachers choose appropriate texts for their students on the basis of their educational level. In this regard, knowledge is transmitted orally, in writing and through media. Being so, reading is one of the most relevant tools in the learning process. PISA argued that it is our reading capability the one that let us access all this information. There are three interrelated components that examine the complexity in the reading comprehension process and they are as follow: *qualitative dimension*, where complexity is examined by the meaning or purpose of the text; *quantitative dimension*, where indices connected to quantitative aspects such as word length, frequency, incidence of grammar structures, etc. are used to examine complexity; and *reader-task* where variables related to the reader, like motivation and knowledge of the task, are considered [1].

*Coh-Metrix* is a language analysis tool developed in the University of Memphis. It helps assess texts via cohesion, coherence relations and readability measures. More importantly, exposed the idea that cohesion gives more information about the degree that ideas in the texts are plainly related to each other, facilitating a unified situation model for the reader.

*Coh-Metrix 3.0* provides 110 indices in its free version. These indices are categorized in eleven (11) groups: *Descriptives*, used to assess patterns in text such as number of paragraphs, words or syllables per word; Text easability principal components scores, which analyses linguistic features in the text such as temporality, narrativity and connectiveness; *Referential cohesion*, which analyses the number of cohesion relations that a human reader could do based on the propositions and sentences of the text; *Latent semantic analysis*, which scrutinizes the similarities of the sentences and paragraphs; *Lexical diversity*, which measures the type of token ratios to deduce high cohesion; *Connectives*, which counts the incidence of connectives in the text*; Situation model;* with indices related to the reader's mental representation of the text; *Syntactic complexity*, which syntactically assesses the sentence and analyses the word density; *Syntactic pattern density*, which analyses the incidence of different types of patterns in the texts; *Word Information,* which demonstrates the word type density in the text*; and Readability,* which analyses the text readability with formulae such as Flesh Reading Ease and Flesh-Kincaid Grade Level [2]. In the same token, *Text Inspector* is a professional web tool that analyses texts up to five hundred (500) words in its free version. It is a user-friendly web tool for teacher,

students, academics and anyone who desires to measure the vocabulary and discourse difficulty level of any text in English.

This study is based on literature review. This literature review has helped us understand difficulties in English texts suggested that there may be text features that have not yet been assessed or that have not yet been assessed or that can be. We have used Coh-Metrix and Text Inspector to analyse two excerpts from the research project written by Danielle McNamara. The corpus is based on two excerpts Lady Chatterley's Lover and A Mortgage.

According to our analyses the first text is high in narrativity which indicates that it is more story-like and may have more familiar words. More story-like texts are typically easier to understand. It has high word concreteness, which means there are many words that are easier to visualize and comprehend. The second text is Flesh Kincaid Grade Level 11.5. This text is low in narrativity which indicates that it is less story-like and have less familiar words. Less story-like texts are usually harder to comprehend. It is low in syntactic simplicity which means the sentences may have more clauses and more words before the main verb. Complex syntax is harder to process. This text is low in deep cohesion. This means there are few connective words that help to clarify relationships between events, ideas, and, information. Because of this, the text may be more difficult to comprehend, especially for unfamiliar topics.

**Conclusion**

In sum, we can reiterate that understanding text complexity is of a great importance to educators since it helps them select which text is in the optimal zone of the reader and the one that is not. Resolutely, Coh-Metrix and Text Inspector are relevant tools for achieving such goal. It is noteworthy mentioning that Text Inspector is very rich for it provides a very large information about a given text and is self-explanatory, whereas Coh-Metrix offers statistical data and therefore requires a deep interpretation for a whole understanding.

**References**

1. Fisher D., Frey N. and Lapp D. (2012). Text Complexity: Raising Rigor in Reading. International Reading Association.
2. Graesser A.C., Chipman. P., Haynes B. C., & Olney, A. (2005). Auto Tutor: An intelligent tutoring system with mixed-initiative dialogue. IEEE Transactions in Education, 48, 612–618.
3. Graesser A.C., McNamara. D.S., Louwerse, M.M. & Cai, Z. (2004). Coh-Metrix: Analysis of text on cohesion and language. Behavior Research Methods, Instruments, and Computers, 36, – P. 193–202.

## TATAR-INFORM.RU. ҺӘМ BASHINFORM.RU САЙТЛАРЫНДА КУЛЛАНЫЛГАН СПОРТ ЛЕКСИКАСЫНЫҢ СТРУКТУР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Мөдәрисов Д., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Р. Мөгътәсимова*

Татарстанда спорт үсеше республика җитәкчелегенең социаль эшчәнлегендә өстенлекле юнәлеш булып тора. Хәзерге вакытта Татарстан

Республикасы  Россия Федерациясе төбәкләре арасында спорт лидерларының берсе.

Спорт ярышлары һәм спортчыларның тормышы турында мәгълүмат махсуслаштырылган мәгълүмат чараларында гына түгел, ә массакүләм аудиториягә исәпләнгән басмаларда торган саен күбрәк урын ала бара. Даими рәвештә чыга торган һәрбер басма орган спортка һәм, журналистлар фикеренчә, спорт белән бәйле күренешләргә дә игътибар итә. Шулай итеп, спорт терминологик лексикасы үсешенә китерә торган төрле юнәлештәге тенденцияләр күзәтелә. Номинацияләрнең, шул исәптән алынма һәм интернациональ номинацияләрнең күплеге синонимик, омонимик һәм полисемантик терминнар барлыкка килүенә китерә.

Спорт төрле мәдәният вәкилләре арасында бәйләүче буын функциясен үти, шуңа күрә әлеге күренешне өйрәнү лингвистлар өчен дә мөһим. Әмма XXI гасыр башының тел яңалыклары спорт тематикасына караган татар һәм башкорт текстларында җитәрлек өйрәнелмәгән.

Шунлыктан без tatar-inform.ru һәм bashinform.ru сайтларында спорт лексикасының яшәеш үзенчәлекләрен тасвирлауны максат итеп алдык. tatar-inform.ru һәм bashinform.ru сайтларында күзәтелгән спорт лексикасын тәшкил итүче берәмлекләрне компонентлар саны буенча түбәндәге төркемнәргә бүләргә мөмкин:

1. Бер компонентлы терминнар: *футбол, гандбол, теннис, көрәш, каратэ, айкидо, ушу, спортчы, турнир, дзюдо, старт* һ.б. Мәсәлән, Анда 98 илнең 1350 спортчысы 15 спорт төре буенча 136 комплект медаль өчен ярышачак*: каратэ, айкидо, көрәш, ушу, дзюдо, таэквондо, сумо, бокс, самбо, кикбоксинг, кендо, муайтай, сават, фехтование* (“Татар-информ” мәгълүмат агентлыгы); Бәләкәйерәк балаларға – күңелле старттар, ә өсөнсө кластан башлап *баскетбол, волейбол, хоккей* буйынса ярыштар уҙғарыла (“Башинформ” мәгълүмат агентлыгы).

2. Ике компонентлы терминнар: *путалы көрәш, атлетик гимнастика, нәфис гимнастика, җиңел атлетика, дөнья чемпионаты, баш тренер, суга сикерү, чаңгыда узышу, еңел атлетика, өҫтәл теннисы, велосипед спорты, ҡаяға үрмәләү, заманса бишалыш, спорт көрәше, уҡтан атыу* һ.б. Мәсәлән, Татарстан спорт комплекслары 12 спорт төре (*чаңгыда узышу, нәфис гимнастика, җиңел атлетика, өстәл теннисы* һ.б.) буенча өченче этап (Идел буе федераль округы) ярышлары һәм 5 спорт төре (*су тубы, җиңел атлетика, чирәмдәге хоккей, фехтование, шахмат*) буенча финал ярышлары үткәрү мәйданы булачак, дип хәбәр итә ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгының матбугат хезмәте (“Татар-информ” мәгълүмат агентлыгы); Кисәнең төп алышында Өфөнән *ҡатнаш көрәш, кикбоксинг* һәм *хәрби самбо* буйынса спорт мастеры Руслан Яманбаев ҡатнаша (“Башинформ” мәгълүмат агентлыгы).

3. Өч компонентлы терминнар: *тимераякта фигуралы шуу, суга сикерүче спортчы, бөтә стилдәге каратэ, урындан оҙонлоҡҡа һикереү, пневматик мылтыҡтан атыу, физкультура-һауыҡтырыу комплекстары, пуля менән атыу, тау саңғыһы спорты, конькиҙа уҙышыу спорты* һ.б. Мәсәлән, Казан ДАУ студентына *тимераякта фигуралы шуу* буенча Россия спорт Мастеры исеме бирелде ("Татар-информ" мәгълүмат агентлыгы); Башҡортостан спортсылары *пуля менән атыу* буйынса Рәсәй беренселегендә биш миҙал яуланы ("Башинформ" мәгълүмат агентлыгы).

4. Дүрт компонентлы терминнар: *Татарстан Президенты Кубогы турниры, бәләкәй калибрлы пистолеттан атыу, арҡала ятып тәнде күтәреү* һ.б. Мәсәлән, Суга сикерү буенча Татарстан җыелмасы баш тренеры Павел Муякин *Татарстан Президенты Кубогы турниры* тээсирләре белән бүлеште ("Татар-информ" мәгълүмат агентлыгы); Марк Сөләймәнов *бәләкәй калибрлы пистолеттан атыу* буйынса ярыштарҙа етенсе булды ("Башинформ" мәгълүмат агентлыгы).

tatar-inform.ru һәм bashinform.ru сайтларында күзәтелгән бер сүзне тәшкил итүче спорт лексикасы структурасы ягыннан аерыла, чөнки әлеге берәмлекләр сүз ясалышының төрле ысуллары ярдәмендә барлыкка килгәннәр. Алар арасында тамыр (*көрәш, туп, уен* һ.б.) ясалма (*спортчы, капкачы, боксчы, шугалак, рапирасы, хоккейсы* һ.б.) һәм кушма (*тимераяк* һ.б.) сүзләрне күзәтергә мөмкин.

Ике компонентлы терминнарның киң таралган морфологик модельләре арасында исә исем + исем (*футбол кыры, боз аренасы, баш судья, боҙ һарайы*, *өҫтәл теннисы* һ.б.), сыйфат + исем (*җиңел атлет, авыр атлет, синхронлы йөзү, нәфис гимнастика, путалы көрәш, еңел атлетика* һ.б.), исем + фигыль (*чаңгыда узышу, каноэла ишеү, ҡаяға үрмәләү, уҡтан атыу* һ.б.) формалары күзәтелде.

Өч һәм аннан да күбрәк элементлы терминнарга килгәндә, аларның морфологик структурасы өчен шулай ук үз составындагы берничә исемнең кушылуы хас. Мәсәлән, анализланган өч компонентлы һәм дүрт компонентлы күпчелек терминнарда исем һәм фигыль сүз төркемнәре ярдәмендә ясалган: *суга сикерүче спортчы, урындан оҙонлоҡҡа һикереү* һ.б. Әмма сайланган терминнар арасында башка мисалларны да күзәтергә була: *бәләкәй калибрлы пистолеттан атыу, бөтә стилдәге каратэ, тимераякта фигуралы шуу* һ.б.

Анализ күрсәткәнчә, татар һәм башкорт телләренең спорт лексикасы җентекле лингвистик тикшеренүләргә мохтаҗ. Спорт терминнарының күп өлешен интернационализмнар тәшкил итүе  иң зур җитешсезлек. Безнең карашыбызча, Татарстан һәм Башкортстан Республикаларында төрле спорт төрләренең үсеше спорт терминологиясе

өлкәсендә татарча һәм башкортча терминнар барлыкка килүгә ярдәм итәргә тиеш.

**Әдәбият**

1. Ишкинина Л.К. Основные способы образования спортивной терминологии в татарском языке (на примере терминов хоккея) // Филологические науки. Вопросы теории и практики.  Тамбов: Грамота, 2014. № 3 (33): в 2-х ч. Ч.I.  С. 88–91.
2. Новости Татарстана и Казани. Татар-информ. URL: https://www.tatar-inform.ru/ (дата обращения 15.01.2020).
3. Новости Башкортостана и Уфы:  ИА Башинформ.рф. URL: http://www.bashinform.ru/ (дата обращения 15.01.2020).
4. Фатхуллина Ф.Р. Спортивная лексика в башкирском языке // Проблемы башкирского, тюркского и сопоставительного языкознания в свете традиционных и новейших направлений в лингвистике. – Уфа: РИЦБашГУ, 2009. – С. 213–216.

## ХАЛКЫМ ӨЧЕН МӘҢГЕ КИРӘК ТУГАН ТЕЛЕМ!

*Мөхәммәдиева А., Әтнә р-ны Комыргуҗа урта мәктәбе, Х сыйныф*
*Җит. – К.К. Шәмсетдинова*

Кәгазь битен ертып ташлап була, ләкин тарих битен бернишләтеп тә юкка чыгарып булмый, чөнки халкымның хәтере яхшы. Хәтерләрдә ул мәңге саклана.Татарстанда гына түгел, ә татар халык дөньясында татар телен үстерү һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре гомер буена барган, барачак. Тел тарих белән бәйле, тарих битләре шул хакта сөйли.

Татар теленә сокланмаган кеше юк. Телебез моңы җырларда, көйләрдә, телебез драмасы шигырьләрдә, хикәяләребездә, телебез үткенлеге һәм кыскалыгындагы осталыгы татар халкымның буыннардан буыннарга күчеп килгән авыз иҗатында чагыла.

Милләт, халык бөтенлеген күрсәтеп торучы билге – ул тел! Шулай булгач, телебезне бетерү үзебезне бетерүгә тиң!

Акыллы һәр кеше бу мәсьәләгә җитди карап, телебезне үстерүгә, саклап калуга үзеннән өлеш кертергә тиеш. Бу өлеш бик гади, минемчә. Бары тик сөйләшергә кирәк, башны горур тотып сөйләшергә, җырлар, шигырьләр, хикәя, романнар иҗат итүне, әдәбият, сәнгать, мәдәнияттә һәм, гомумән, җәмгыятьтә бар юнәлештә, өлкәдә татарча актив эшчәнлекне дәвам итәргә кирәк.

Татар теле язмышын күзаллау һәм телне саклап калу юлларын билгеләү максатыннан куелган бурычлар:

1. Татар теле язмышы турында күренекле милләттәшләремнең фикерләрен барлау;
2. Туган телемне саклау эшчәнлегендә тәкъдимнәр кертү.

1. Татар теле язмышы турында күренекле милләттәшләремнең фикерләре.

XVII йөздә татар теле бүгенге инглиз теле, урта гасырларда Европада латин шикелле халыкара кулланылышта булган. Бу турыда журналистлар белән очрашуда ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү

институты директоры Искәндәр Гыйләҗев сөйләгән иде. Аның әйтүенчә, XVII гасырда татар теле күпләгән көнчыгыш илләре белән аралашу өчен Мәскәүнең илчелек боерыкларында бик еш кулланылган.

«Үз вакытында татар теле халыкара аралашу теле буларак кулланылган. Ул рус дәүләтенең Көнчыгыш илләре белән аралашуында дипломатик мөнәсәбәтләр теле булып торган. Татар теле илчелек боерыкларында, рус патшаларының рәсми аралашу кәгазьләрендә, мәсәлән, Алексей Михайловичның Һиндстан, Иран, Урта Азия һәм башка күп дәүләтләр белән рәсми язышуларында бик еш кулланылган. Татар теле ул заманнарда бүгенге инглиз, ә урта гасырларда Европадагы латин дәрәҗәсендә торган. Моның шулай икәнен күпләр белми, ә чынлыкта ул шулай» – диде Гыйләҗев.

Бүгенге көн яшәеше замана кешесеннән телләр белүне таләп итә, шул исәптән рус теле, инглиз теле. Әйе бу телләрне белү зыян түгел, киресенчә файда. Үз туган телеңне белеп сөйләшкәндә башка телләрне үзләштерү тагы да уңайлырак.

«Мәрҗани рус телен өйрәтүгә каршы булмаган, ләкин татар сөйләменә рус сүзләрен кыстырып сөйләшүне яратмаган. Ул: «Мин рус түгел, миңа татарча сөйләгез», – дип әйтә торган булган. Шундый бер очрак турында сөйлиләр, берәү Шиһабетдин хәзрәткә вареньедан авыз итәргә кушкан, әмма аннан «мурабба» яки «кайнатма» дип әйтергә кирәк, ягъни татар сүзләре белән сөйләшергә кирәк дигән кискен җавап ишеткән. Мәрҗани кибетләрдә татарча бәя язулары булмаса яки алар аска, күренми торган җиргә куелган булсалар да, бик ачуланган. Татар фамилияләрендә ул беркайчан «-ин», «-ов» дигән кушымчалар кулланмаган, бары тик мөселман ел исәбе-һиҗрине генә кулланган».

Халык язучысы Нурихан Фәттах үз заманында болай язган: «Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә, нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе – йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым!” Язучы тарафыннан әйтелгән әлеге сүзләр бүгенге көн проблемаларын чагылдырып әйтелгән диярсең. Әйе, язучы фикере белән килешәм. Көрәш безнең очракта ул – сөйләшү, үз туган телебездә сөйләшү, бары тик сөйләшү, иҗат итү, халыкка тарату, аңлашу, буыннарга тапшыру, югалтмау! Әлеге фәнни хезмәтне без татар теленең үткәне, бүгенгесе, тел турында күренекле шәхесләребезнең фикерләре һәм татар телен саклап калуга үземнән фикерләр-юллар тәкъдим итүгә багышлап, татар теле язмышы һәм мин аның киләчәген ничек күзалдына китерүебез турында яздык. Татар теле язмышы турында күренекле милләттәшләребезнең фикерләрен барладык һәм туган телемне саклау эшчәнлегендә үз фикерләребезне тәкъдим иттек.

1. Татар телен туу белән өйрәнә башларга, башлангыч сыйныфларда татарча укырга, телнең асылын җанга сеңдерергә кирәк – ул беркайчан онытылмаячак!

2. Татар телен һәрдаим кулланырга. Урыны белән син русча да, инглизчә дә сөйләш! Тик татар телендә аралаш.

3. Татар телендә әдәбиятта иҗат эше дәвам итсен, мәдәниятта актив эшчәнлек башкарылсын.

4. Татар телендә сөйләшкәндә этномәдәни лексиканы куллан, сөйләмең матур, аһәңле, назлы, нәфис булсын; алынма сүзләр кулланма.

Безнең татар теле бик матур тел, йомшак тел. Бары тик матур итеп сөйләшергә кирәк.

**Әдәбият**

1. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан, 2007. – 351 с.

2. Нурмөхәммәтова Р.С., Җамалетдинов Р.Р. Татар теленең этнокультура сүзлеге: матди мәдәният лексикасы. – Казан, 2005. – 146 б.

## АНАЛИТИК ҺӘМ СИНТЕТИК ЧАРАЛАРНЫ ӨЙРӘТҮ МЕТОДИКАСЫ

*Мөхәммәтгалиева Г., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Р.К. Сәгъдиева*

Туган тел ул – халыкның рухы, җаны, иң әһәмиятле билгесе. Телдә һәм тел аша халыкның милли характеры, психологиясе, фикерләү һәм иҗат үзенчәлекләре ачыла, шулай ук аның тарихы, мәдәнияте чагылыш таба. Шуңа күрә туган телне өйрәнү һәм саклау иң зарур эшләрдән санала.

Бүгенге көндә туган телебезне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен, шактый күп әһәмиятле эшләр эшләнә: татар теле Татарстанда яшәүче барлык милләт балаларына да укытыла, татар телендәге матбугат материаллары, интернет, радио-телевидение тапшырулары күпкә арттырылды, туган телдә бик күп чаралар уздырыла һ.б. Татар теленең абруе зур дияргә дә мөмкин. Әмма татар теленең бүгенге халәте, киләчәк язмышы тынычланып яшәрлек түгел.

Туган телне саклау, үстерү төшенчәсе аннан файдаланучыларның санын арттыруны гына түгел, телнең сыйфаты, ягъни дөрес кулланылышы тиешле дәрәҗәдә булуны да күздә тота. Шул ук вакытта һәр коллективтан, һәр укытучыдан рухи һәм физик сәламәт, югары эрудицияле, конкурентлыкка сәләтле, укырга теләге булган, бүгенге тормышта үз урынын таба, максатына ирешә ала торган балалар тәрбияләү өчен, төрле гамәли юллар табу сорала.

Рус телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендә аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне өйрәткәндә кулланылырга мөмкин булган эш төрләре татар мәктәпләрендәге күнегүләр системасыннан әллә ни аерылмый. Шулай да,

әлеге төркемнең татар телен азрак күләмдә укуын һәм укучыларның көндәлек тормышта күбрәк рус телендә аралашуын истә тотып, әлеге укучыларга җөмләләрнең гадирәген сайларга кирәк. Шулай ук рус теленнән тәрҗемә күнегүләре дә әлеге төркем өчен уңышлы булыр.

Заманча педагогика өлкәсендә яңа алымнар һәм методлар гаять күп. Дәреснең кайсы этабында нинди алымнар куллану, укучының белем һәм кызыксыну дәрәҗәсенә китереп кайсы методтан файдалануны билгеләү укытучыдан педагогик осталык таләп итә. Урта гомуми белем бирү оешмаларында аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне өйрәткәндә, түбәндәге эш төрләре кулланылырга мөмкин:

**Грамматик бирем.**

1) Һәр мәкальне укып, мәгънәсе турында фикер алышыгыз. Дәфтәргә язып, иясен, хәбәрен табыгыз, җөмләләрнең схемасын сызыгыз.

*1. Кем намус белән хезмәт итә, шул зур хөрмәткә ия була.*

*2. Эш күрсәткәнне ил онытмас.*

*4. Җил кайдан иссә, болыт та шуннан килә.*

*5. Бер ялганласаң, икенче чын сүзеңә дә ышанмаслар.*

**Күчереп язу күнегүләре.**

1) Җөмләләр арасыннан аналитик иярчен җөмләләрне генә язып алыгыз.

*Тагын шунысы кызык: Наил бер сүз дә әйтми иде.* (Ә. Е)

*Ул үзе менә шунда утыра, ә күңеле әллә кайларда йөри.* (Г. Б.)

*Кояш чыкса, көн матурланыр иде.* (Ф. Я.)

*Кем тырышып укый, шул зур хөрмәткә ия.* (Г. И.)

2) Бирелгән җөмләләргә тиешле бәйләүче чараларны куеп языгыз.

*Идарәнең карары ... : бүгенге көннән башлап син ындыр бригадиры буласың.* (Г. Б.)

*Хикмәт тә ...: сүзләре пеште, серләре килеште.* (Җ. Р.)

*Көтүчесе.... , көтүе ......*(М.)

*... берлек, ....көч.* (М.)

*Бүген көнозын кар яуды,.... вакытында очып китә алмадык.*

*Телең ... әйтсә, колагың ... ишетер.*

**Тест.**

1. Синтетик иярчен җөмләнең бәйләүче чаралары:

а) кушымчалар, фигыль формасы, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору;

ә) мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгеч сүзләр, көттерү паузасы;

б) бәйлек һәм бәйлек сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр.

2. Аналитик иярчен җөмләдә нинди тыныш билгеләре куела:

а) сызык, өтер;

ә) ике нокта, өтер;

б) ике нокта, өтер, сызык.

3. Каршы кую интонациясе ярдәмендә нинди җөмләләр бәйләнә?

а) күренешләрне бер-берсенә каршы куйган җөмләләр;

ә) бер үк вакытта булган күренешләрне санап киткән җөмләләр;

б) бер-бер артлы килгән күренешләрне санап киткән җөмләләр.

**Уеннар.**

1) Укытучы әйткән фикерләр белән килешүче укучылар урыннан торып баса, килешмәүчеләр утырган килеш кала.

- *Ике яки берничә хәбәрлектән торган җөмлә кушма җөмлә була. (Әйе)*

- *Аналитик кушма җөмләдә гади җөмләләр үзара көттерү интонациясе ярдәмендә бәйләнә. (Әйе).*

- *Синтетик кушма җөмләдә бәйләүче чара булып санау интонациясе килә ала. (Юк).*

- *Аналитик кушма җөмләдә гади җөмләләр арасына ике нокта куела ала. (Әйе).*

“Эшләпәдә ниләр бар?” уены. Аналитик иярчен җөмләләрне кабатлау өчен, нәфис эшләпә алырга һәм эченә җөмләләр язылган карточкалар салырга. 1 карточкада 1 җөмлә була. Укучылар карточканы ала, җөмләне укый һәм аналитик иярчен җөмләләрнең баш җөмләгә нинди чаралар ярдәмендә ялгануын аңлата. Әлеге уенны көй ярдәмендә уйнатырга мөмкин.

1 вариант. Аналитик җөмләләр:

1) *Оясында ни күрсә, очканында шул булыр.* (Мәкаль).

2) *Әнисе артык горур табигатьле кеше, шуңа күрә ул этисеннән дә өстен.* (М. Әмир).

3) *Ул вакыт агышын югалтты, әйтерсең аның үз вакыты.* (Ф. Садриев).

2 вариант. Синтетик җөмләләр:

1) *Данилов яралану аркасында, отрядны җитәкләү Вәлитовка тапшырылган иде.* (Г. Бәширов).

2) *Ходай кушылдырганны кеше аера алмас* (Мәкаль).

3) *Үзең тапмаган малның кадере булмас* (Мәкаль)

**Карточкаларда эш.**“ТИК-ТЭК-ТОУ” структурасы.

“Театр” темасы буенча бер сүздән торган 9 карточка тәкъдим ителә.

Карточкалар 3 х 3 итеп таратып куела. Диагональ, өстән аска, уңнан сулга куелган 3 сүзне кертеп, иярченле кушма җөмлә төзергә кушыла.

**Иҗади биремнәр.**

1. Ш. Галиев, Р. Миңнуллин, Х. Сарьян, Ә. Еникиләрнең әниләр турындагы әсәрләреннән өчәр синтетик (аналитик) иярченле кушма җөмләләр язып килегез.

2. Г. Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” әсәреннән 5 аналитик (синтектик) җөмлә язып килегез.

3. Газета-журналлардагы мәкаләләрдән аналитик (синтектик) җөмләләр язып килегез.

**Трансформацияләү күнегүләре.**

1. Бирелгән җөмләләрнең урыннарын үзгәртеп аналитик яки синтетик җөмләләр төзү.

*Шул дәшми. Кем белми.*

*Без юлга кузгалдык. Кояш чыккач. Яңгыр туктап.*

*Ул аңлый иде. Әтисенең ачуланачагын. Икелене күргәч.*

*Чөнки кап-кара болыт килә иде. Ул тизрәк эшләрен бетерергә ашыкты.Кояш чыккан яктан.*

**Тәрҗемә күнегүләре.**

Рус теленнән татар теленә, җөмлә төрен саклап, тәрҗемә итәргә; иярчен җөмләнең төрен (аналитик, синтетик) күрсәтергә.

*Кто не работает, тот не ест* (пословица).

*Не копай другому яму, сам в нее попадешь* (пословица).

*Слово – не воробей, вылетит – не поймаешь.* (пословица).

*Кто рано встает, тому бог дает.* (пословица).

**Кроссворд.**

*1)* Бирелгән җөмләдә бәйләүче чараның төрен билгеләгез. “*Хәл ителде: Павел иртәгә китә* ” *(көттерү паузасы).*

*2)* Баш җөмләдән соң килеп, көттерү интонациясе белән бәйләнгән иярчен җөмлә алдыннан нинди тыныш билгесе куела? *(ике нокта).*

*3)* Тиешле бәйләүче чараны куегыз. “*Кайда берлек, ... көч*” *(шунда).*

*4)* Бирелгән җөмләдә бәйләүче чараның төрен билгеләгез. “*Дөнья өчен эшләсәң, шул яшәвең кадере* ” *(мөнәсәбәтле сүз).*

*5)* Синтетик кушма җөмләдәге иярчен җөмлә ничек атала? *(синтетик).*

6) Парлы мөнәсәбәтле сүз ярдәмендә бәйләнешкә кергән баш һәм иярчен җөмлә арасына нинди тыныш билгесе куела? *(өтер).*

*7)* Тиешле бәйләүче чараны куегыз. “*Тукай артистларны хөрмәт итә, ... бу чорда халык театрны бик ярата* ” *(чөнки).*

*8)* Иярчен җөмлә алдан килеп, баш җөмлә ялгызак мөнәсәбәтле сүздән башланмаса, җөмләләр арасына нинди тыныш билгесе куела? *(сызык).*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, һәр дәрес тибы, дәреснең һәр этабы куелган максатларны тормышка ашырырлык итеп оештырылырга тиеш. Укучы һәр дәрестән, өйрәнелгән лексик һәм грамматик берәмлекләрне кулланып, программада күрсәтелгән темалар буенча аралаша алып, орфоэпик нормаларны белеп, сүзләрне дөрес әйтә белеп, диалогик һәм монологик сөйләм оештырып чыгарга тиеш.

**Әдәбият**

1. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.

2. Мирзаһитов Р.Х., Шакурова М.М., Мусаяпова Н.Х. Татар теле. 9 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 190 б.
3. Сәгъдиева Р.К. Хәзерге татар теле синтаксисы. Лекцияләрнең кыскача конспекты. – Казан: КФУ, 2014. – 129 б.

## ФИГЫЛЬНЕҢ КЫТАЙ ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕНДӘГЕ УРЫНЫ

*Мөхәммәтшина А.Ф., КФУ, 3 курс студенты*
*Фән.җит. – филол.фән.канд., доц. Р.С. Нурмөхәммәтова*

Татар телендә ***фигыль***не иң катлаулы сүз төркеме дип атасак, ялгышмабыз. Татар телендә әлеге сүз төркеменең биш юнәлеше (төп, кайтым, төшем, уртаклык, йөкләтү), җиде төре (хикәя, боерык, сыйфат, шарт, хәл, исем фигыльләр, инфинитив) бар. Шулай ук кайбер фигыль төркемчәләрендә заман категориясе дә очрый. Фигыльләрнең бүленеше кытай телендә дә бик үзенчәлекле. Алар *тулы мәгънәле* һәм *ярдәмче* була. Тулы мәгънәле фигыльләр *нәтиҗәсез* һәм *нәтиҗәле*гә бүленә. Тулы мәгънәле фигыльләр үзләре гади хәбәр булып килә. Нәтиҗәсез фигыльләр бер иҗекле сүз белән бирелә, алар тулы эш-хәрәкәтне белдерә: 活, 看, 做 Нәтиҗәле фигыльләр өстәмә мәгънә бирә. Нәтиҗәле фигыльләр гади нәтиҗәле һәм юнәлешле-нәтиҗәле була. Гади нәтиҗәле фигыльләр ике иҗектән тора. Беренче өлешендә төп фигыль бирелә, ә икенче өлешендә башкару сыйфаты яки төгәлләштерүче нәтиҗәне күрсәтә (做完 – эш башкарылып бетте). Гади нәтиҗәле фигыльләрнең икенче өлешендәге фигыль күптөрле мәгънәдә килә (таб 2.4).

Таблица 2.4. Кытай телендә гади нәтиҗәле фигыльләрнең мәгънәләре

| иероглиф | мәгънә |
|---|---|
| 到 | эш-хәрәкәтнең бетү точкасына килү |
| 着 | эш-хәрәктәнең дәвамлылы булу |
| 住 | ирешелгән нәтиҗәне ныгыту |
| 见 | сизү-тою органнары белән тасвирлану |
| 好 | яхшы нәтиҗәне булдыру |
| 成 | уңышлы нәтиҗә булдыру |
| 完 | эш-хәрәкәтнең тулысынча тәмамлануы |
| 了 | эшнең тәмамлануы |
| 掉 | нәтиҗәнең юкка чыгуы |

Юнәлешле-нәтиҗәле фигыль шулай ук ике өлештән тора: беренче өлешендә төп фигыль, ә икенче өлешендә юнәлеш бирелә (坐下-аска утыру). Әлеге фигыльләрнең шулай ук икенче өлеше күптөрле була ала (таб 2.5).

Таблица 2.5. Кытай телендә юнәлешле-нәтиҗәле фигыльләрнең мәгънәләре

| иероглиф | мәгънә |
|---|---|
| 上 | эш-хәрәкәтнең өскә юнәлгәнен белдерә |

| | |
|---|---|
| 下 | эш-хәрәктәнең аска юнәлгәнен белдерә |
| 进 | эш-хәрәкәтнең эчкә таба юнәлгәне |
| 出 | эш-хәрәкәтнең тышка таба юнәлгәне |
| 过 | эш-хәрәкәтнең нәрсәдер аша үткәнен күрсәтә |
| 起 | эш-хәрәкәтнең өскә күтәрелешен белдерә |
| 回 | эш-хәрәкәтнең кире кайтуын белдерә |
| 开 | эш-хәрәкәтнең кайсыдыр якка юнәлгәнен белдерә |

Ярдәмче фигыль үзләре генә тулы эш-хәрәкәтне белдерә алмый. Ул үз эчендә тагын берничә төргә бүленә: модаль, боеру, эш дәрәҗәсен күрсәтүче һәм юнәлешне күрсәтүче фигыльләр. Модаль фигыльләр эш башкару мөмкинлеген, кирәклеген белдерә (能, 应, 得, 要, 敢). Боеру фигыльләре эш башкарырга боера (使, 叫, 教, 迫使). Эш дәрәҗәсен күрсәтүче фигыльләр эшнең башлануын, дәвам итүен, тәмамланганын күрсәтә (开始, 继续, 停止). Ә юнәлешне күрсәтүче фигыльләр эш-хәрәкәтнең кемнән һәм кемгә караганын әйтә (来, 去). Кытай телендә фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше юк. Заман күрсәткечен шулай ук контекст ярдәмендә аңлап була (房子里走进一个人来了-Бүлмәгә бер кеше керде.), әмма кайбер күрсәткечләр дә бар:

1) 了 эшнең үткәндә булганын күрсәтә, ләкин 了...了 эшнең әле дә дәвам ителгәнен билгели (我学汉语学了三年了- Мин кытай телен өч ел дәвамында өйрәнәм);

2) 过 эшнең билгесез үткән заманда берничә тапкыр үтәлгәнен аңлата (你到过我家手里没有?- Синең минем өйгә килгәнең бармы?);

3) 着 эшнең хәзерге вакытта барганын күрсәтә (我等着他，他快要来的 – Мин аны көтәм, ул тиздән килергә тиеш);

4) 在 эшнең хәзерге вакытта һәм бу эшнең берникадәр вакыт барганын белдерә (我再走我的路- Мин үз юлымда барам);

5) 要 эшнең киләчәктә эшләнергә уйланганы турында әйтә (我要去喀山 – Мин Казанга барачакмын).

**Әдәбият**

1. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

2. Горелов В.И. Грамматика китайского языка: для 8-10 классов средней школы с преподаванием ряда предметов на китайском языке. – М.: Просвящение, 2016. – 280 с.

## ОБУЧЕНИЕ ЯЗЫКОВЫМ ЛАКУНАМ НА ОСНОВЕ ТЕКСТОВОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ

*Мухаметзянова Л., КФУ, студент V курса*
*Науч. рук. – канд. пед. наук, доц. Л.О. Свирина*

В современной методике преподавания иностранному языку признается необходимость введения национально-культурного компонента как одного

из важнейших элементов при формировании коммуникативной компетенции обучающихся. В процессе обучения иностранному языку культурные реалии данного языка передаются непосредственно через сам изучаемый язык. Таким образом, язык выступает в качестве инструмента формирования языковой картины мира. Такой процесс нашел отражение в понятиях лингвокультурологии и лингвокультурологического подхода в преподавании.

Каждый этнос характеризуется своей уникальной языковой картиной мира, построенной из национально-специфических концептов. Некоторые лингвистические понятия можно понять посредством сопоставительного метода, то есть с помощью перевода, нахождения эквивалентных единиц. Однако культурные концепты могут реализовываться в тексте и в виде языковых лакун или безэквивалентной лексики, что значительно усложняет процесс понимания. Е.М. Верещагин и В.Г. Костомаров определяют безэквивалентную лексику как слова, план содержания которых невозможно сопоставить с какими-либо иноязычными лексическими понятиями. Другими словами, они непереводимы [1: 387]. З.Д. Попова и И.А. Стернин обозначают лакуну как отсутствие единицы в одном языке при ее наличии в другом. Эти авторы подчеркивают, что «главной особенностью лакун является то, что они возникают в процессе общения, в ситуации контакта двух культур» [3: 205-223].

Существует и другой термин для обозначения понятия «лакуна» – лингвокультурема. Во время интерпретации текста, основной задачей которого становится адекватное понимание мысли автора, структурная организация текстов отходит на второй план. Мыслительная деятельность более всего связывается с лексической составляющей, которая носит содержательный план, и которая чаще всего, выражается лингвокультуремами. На этом этапе текстовая деятельность, по большей части чтение текста и его лексико-грамматический анализ, становится тем необходимым элементом, который помогает раскрыть значение лингвокультуремы исходя из контекстуальной ситуации. Здесь основное внимание должно отводиться совершенствованию лексического навыка – научить обучающихся использовать в своей речи не просто лексические единицы, а полноценные лингвокультуремы, включая лакуны, а также уметь обнаруживать их в речи другого говорящего и правильно реагировать на них.

Текст раскрывает объем семантики лексических единиц. *They have made a mistake. There was an error in their calculations – Они сделали ошибку. В их вычислениях была ошибка*. *Ошибка* в русском языке имеет гораздо больший объем значения, этим словом характеризуются любые ошибки. *Error* и *mistake*, несмотря на одинаковый перевод, отличаются по смыслу, их дефиниции имеют ограниченное толкование: в первом случае, это ошибка именно в расчетах, в документах, характеризуется наличием семантики «техническая» в слове, используется чаще всего в текстах официальных, в то время как слово *mistake* более нейтрально. Часто контекст помогает понять, о каких ошибках идет речь. Слово *they* (они – кто-то) показывает, что ошибка сделана непосредственно людьми, доказывает использование *mistake*; in calculations – отражает серьезность ситуации, научность – *error* вполне соответствует смыслу предложения.

Однако, даже если возможна замена слов друг с другом, хотя и со значительными потерями точного смысла или же приобретением новой коннотации, есть устойчивые словосочетания, в которых подобная замена невозможна. Например, *If I'm not mistaken, you called me for help* (не *If I'm not erred*). – *Если я не ошибаюсь, ты позвонил за помощью.*

В текстах часто встречаются и языковые лакуны, реалии которых в родном языке либо не обозначены, либо не существуют. Возникает проблема не столько перевода, сколько осознания и принятия несоответствия образа жизни и наличия некоторых физических объектов в окружении разных народов. Например, в предложении *The ad, which will run during prime time on NY1 today, begins by highlighting de Blasio's campaign commitment to end economic inequality in New York City* к слову *prime time* невозможно подобрать русскоязычный эквивалент [5]. В США данное словосочетание обозначает отрезок времени с 18:00 до 20:00, когда наблюдается самая большая активность телезрителей. Вероятно, в русском языке реалия есть,

но по тем или иным причинам, данному явлению не дано названия. Подсказки в тексте, такие как *the ad, during* и *on NY1*, в какой-то степени раскрывают значение лакуны: реклама позволяет понять, что речь идет о канале NY1, языковая догадка срабатывает при контакте слова *during* с *prime time* – то есть отрезок времени. Остается лишь добавить смысловой оттенок данному отрезку времени.

Другая лакуна в предложениях: *Uriel lives on the outskirts, somewhere near the old drive-in* или *You guys have your own drive-in?* Обратимся к первому предложению, где *drive-in* переводится как закусочная, причем закусочная, где еду подают прямо в автомобиль, или во втором предложении, где имеется ввиду «*автокино*» (фильм смотрят из автомобилей на открытом воздухе). В русском языке нет лексемы, соответств ующей английскому *drive-in*, так как нет подобного явления. Это примеры ситуации, когда контекст не помогает понять значение, есть лишь смутная догадка о связи с автомобилем из-за лексической составляющей *drive* и послелога *in*.

Таким образом, при интерпретации текста с лакунами контекст может подсказать значение безэквивалентной лексики путем перераспределения ее значения по лексическим единицам в предложении, как в сл учае с *prime time*. В иных случаях, когда языковая догадка не срабатывает при отсутствии опорных смыслообразующих слов, раскрытие значения лакуны происходит с помощью развернутого описания на основе словаря, лексико-грамматического анализа и фоновых знаний, главной составляющей социокультурной компетенции.

**Литература**

1. Верещагин Е.М., Костомаров В.Г. Язык и культура. – М.: Русский язык, 1990. – 387 с.

2. Виссон Л. Синхронный перевод с русского на английский: приемы, навыки, пособия. – Изд.-во: Р. Валент. – 2007. – 318 с.

3. Стернин И.А., Попова З.Д., Стернина М.А. Лакуны и концепты. – Благовещенск: Изд-во БГПУ, 2003. – С. 205–223.

4. Shanahan D. Culture, culture and "culture" in Foreign Language Teaching // Foreign Language Annals. – 1998. – Vol.31, №3. – P.451-457. – URL https://doi.org/10.1111/j.1944-9720.1998.tb00588.x (дата обращения: 01.10.2018).

5. LINGUAZZA.COM // URL: https://linguazza.com/sentences-with/campaign+commitment (дата обращения: 25.01.2020).

## ОСОБЕННОСТИ ИЗУЧЕНИЯ РЕЛИГИОЗНОЙ ЛЕКСИКИ В СОВРЕМЕННОМ ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

*Мухаметова И., КФУ, аспирант II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. А.Ф. Юсупов*

В сегодняшнее время в современном обществе интерес к религии, в частности к религиозной лексике остается очень важным и необходимым для науки. Изучение в татарском языке религиозной лексики явля-

ется очевидным, и количество его исследований в разных областях гуманитарной науки продолжают расти. Исследование татарской религиозной лексики является интересным, и в то же время сложным и познавательным процессом научного поиска, который обосновывается длинной историей созвучия разных культур (мусульманской и тюркской), арабской графикой старотатарского языка с невыработанными и неизведанными языковыми нормами, неоднократной сменой алфавита, которая привела к отрыву от литературного прошлого следующие поколения. Преобразования, происходящие в обществе, предопределили необходимость его углубленного и досконального изучения.

Национальный рост самосознания, борьба за сохранение родного языка, развитие национальной и духовной культуры, потребность возрождения и расширения сферы применения татарского языка не только в одной отрасли, а также применения в других научных направлениях. Религиозно-правовая литература сконцентрировала в себе философскую мысль, художественное сознание, нравственно–психологическое мировоззрение народа Волго-Уральского региона и оставила огромное количество, как рукописных, так и переведенных с восточных языков источников. В настоящее время не до конца выявлен круг источников мусульманской культуры у татар, не исследованы ее истоки и языковые традиции. [1: 57]. По мере реализации татарского языка как государственного активизируется роль возвращенной лексики, которая черпает свои возможности из ресурсов религиозной лексики татарского языка до национальной эпохи. На сегодняшний день назрела необходимость научного исследования богатейшего и глубокого репертуара религиозной лексики в плане выявления их лингвистических особенностей. Татарская религиозная лексикология прошла многовековой и сложный путь развития. Усилиями нескольких поколений татарских ученых-востоковедов происходило становление ее лексики. К сегодняшнему дню происходят существенные и явные изменения в изучении филологического и лингвистического аспекта этой области. Новые современные тенденции в общественно–культурной жизни народа, пробуждение интереса к своим историческим корням, к духовным и культурным традициям ставят перед филологами новые задачи, выявляют объекты анализа, ядром которых становится религиозная лексика современного татарского языка. Поэтому изучение языка мусульманской литературы в контексте осмысления необходимости изучения ее роли в национальной культуре и истории является актуальным. В татарском языке неоднократно предпринимались попытки анализа лексико-семантического и фонетико-грамматического освоения арабских заимствований в татарском литературном языке в работах М.И. Махмутова, Ю.А. Валитовой, Ф. Фасеева, Ш. Рамазанова,

Г. Шарафа, К. Сабирова, М.З. Закиева и др. Д.Г. Зайнуллин в своей монографии впервые сделал попытку дать анализ историко-лингвистического плана татарской духовной литературы. В толковом словаре татарского языка обнаружены около пятисот лексических единиц, имеющих отношение к религиозным представлениям. Из них около четырехсот – имена существительные. Отобранные путем сплошной выборки лексические единицы объединяются втематические группы, которые определены нами в предыдущих исследованиях следующим образом:

- понятия, связанные с верой в загробную жизнь: *ахирәт 'загробная жизнь, потусторонний мир', ахыр заман 'конец света / мира', кабер газабы 'мучения, наказания в могиле.*

- наименования религиозных праздников: *гашурә 'религиозный праздник, празднуемый на десятый день месяца мухharам в день мученической смерти внука пророка Хусейна* [5].

- названия строений: *Алла йорты 'храм божий', госел бүлмәсе / госелханә 'комната для омовения', гыйбадәт йорты / ханә 'храм богослужения', Кәгъбә 'Кааба (мечеть в городе Мекка).*

Таким образом, религиозная лексика татарского языка формировалась разными путями:

а) средствами собственного словарного фонда);

б) заимствованием лексем из других языков и семантической трансформацией уже существующих слов (мусульманская и христианская лексика). В будущей перспективе данная работа предполагает дальнейшее изучение и более подробную семантическую классификацию религиозных лексем в татарском языке.

**Литература**


1. Зайнуллин Г.Г. Татарская богословская литература XVIII-XX веков и ее стилеязыковые особенности. – Казань, 1999. – 107 с.
2. Саттарова М.Р. Теолексика в татарском языке: материальное и духовное содержание // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства. – Казань: Отечество, 2012. – 267 с.
3. Сафиуллина Р.Р. Арабская книга в духовной культуре татарского народа. – Казань, 2003. – 212 с.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.
5. Толковый словарь арабского языка. – М., 1980. – 678 с.


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ РИЗЫК АТАМАЛАРЫ СИСТЕМАСЫ ФОРМАЛАШУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


*Насыйбуллина К., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Р.С. Нурмөхәммәтова*


Кешенең бөтен тормышы тел белән бәйле. Тел – халыкның яшәү асылын, гореф-гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын күп гасырлар буена үзенә сеңдерә барып, аны

безнең заманнарга кадәр китереп җиткерүче зур хәзинә. Тел барлыкка килгәннән алып яшәешенең бөтен этапларында да җәмгыять, аның мәдәнияты белән аерылгысыз бәйләнештә булган.

Тел белән мәдәниятнең бәйләнеше турында төрле фикерләр йөри: берәүләр телне бөтеннең өлеше буларак мәдәниятка бәйле дип, икенчеләр аны мәдәниятнең чагылыш формасы итеп, өченчеләр тел мәдәниятнең формасы да, элементы да түгел дип саныйлар.

Шул ук вакытта мәдәният телнең үсешенә һәм яшәешенә зур тәэсир ясый. Мәдәниятның телдә чагылышын өйрәнү белән шөгыльләнә торган фәнне лингвокультурология (лат. lingua – тел, cultura-мәдәният, logos – өйрәнү) диеп атыйлар. Ул бер сүз эчендә тел һәм мәдәниятны бербөтен буларак тикшерә. Бу шулай ук «ризык» лексик-семантик кырына караучы берәмлекләргә дә хас күренеш.

Һәрбер милләтнең үз ризык атамалары бар. Алар халыкның гореф-гадәте, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре белән турыдан-туры бәйләнгән. Татар халкының милли ашлары үз этник традицияләре нигезендә генә үсмәгән, аңа күрше халыкларның – руслар, мари, удмурт һ.б., шулай ук Урта Азия халыкларының, аеруча үзбәк һәм таҗикларның ашлары йогынты ясаган. Татар халкы ашларына пылау, хәлвә, ширбәт кебек ашамлыклар, шулай ук рус милли ашамлыклары бик күптән килеп кергән. Шул ук вакытта башка халыкларга хас ашларны әзерләү, азыкларның төрләрен ишәйтү татар ашларының төп этник үзенчәлекләрен үзгәртмәгәннәр.

Ризык атамалары телебезнең үз сүзләре белән дә, алынма лексика белән дә бирелергә мөмкин. Мәсәлән, бүгенге көндә актив кулланылышта булган *желе, котлет, мармелад, лимонад* сүзләре XVIII гасырда рус теле йогынтысы аша француз теленнән керә. Нәкъ шул рәвешле татар теленең сүзлек составын алман теленнән күчкән *торт, паштет, бисквит, бутерброд* һ.б. шундый лексик берәмлекләр баета.

Татар халкында элек-электән камыр ризыкларына өстенлек бирелә. Бу-аның яшәү рәвеше, утрак тормыш алып бару үзенчәлекләренә бәйле дип санала. Шуларның берничәсенә күзәтү ясыйк.

Татар халкында камыр эченә төрле ризыклар салып пешергән ашамлыклар үзенчәлекле һәм күптөрле. **Кыстыбый** шундый иң борынгы һәм гади ашамлыклардан санала, кайбер якта аны *күзикмәк, якмыш* дип тә атыйлар. Элек аны төче камырдан әзерләгән юка җәймә эченә бары тары боткасы гына салып ясаганнар. XIX гасыр азакларыннан кыстыбый эченә бәрәңге боламыгы сала башлаганнар. Бүгенге көндә кыстыбый нәкъ менә шул вариантта татар халкының милли ризыгы буларак күзаллана. Сүзнең этимологиясенә килгәндә, төрле диалектларда ул *кыстымбый, кыстымбай, кыстырымбай* формаларында яши. Төрки телләрдә, мәсәлән, чуваш телендә *кăстăмпи*, мариларда *кыстывий*, удмурт телендә исә *кыстыбей* ке-

бек охшаш яңгырашка ия [1: 525]. Шул ук вакытта безнең белән тыгыз бәйләнештә булган рус милләтендә әлеге ризыкның аналоглары юк.

Татар халкының яраткан борынгы ашларыннан берсе – төче яисә әче камырдан эченә симез ит (сарык, сыер, каз, үрдәк һ.б. ите) һәм ярма яки бәрәңге салып пешергән **бәлеш**. Сүзнең килеп чыгышына күз салсак, әлеге лексик берәмлеккә татар этимологиясендә конкрет аңлатма юк. Кайберәүләр борынгы төрки, монгол теленнән *бариш*, ягъни “бик зур акча берәмлеге” сүзе белән чагыштыралар. Рус теленә әлеге сүз “пирог с мясом и картошкой” буларак тәрҗемә ителә. Чуваш телендә *пĕлĕш*, мариларда *палыш, пдлыш* удмурт телендә *бальыш* буларак яңгырый [1: 174]. Шулай ук кайбер чыганакларда һәм сүзлекләрдә исә бәлешнең русчага *беляш* формасында тәрҗемә ителүен дә күрергә мөмкин, тик бу дөреслеккә туры килми. Беляш рецептлар китабында эченә тарткан ит салынып, майда кыздырылган пәрәмәч буларак тәкъдим ителә.

Татарларның чәй өстәленә әзерли торган традицион камыр ризыгы – **гөбәдия**. Ул эченә корт, дөге, йомырка, йөзем җимеше, май, шикәр кушып, зур бәлеш кебек ясала. Гөбәдияне башта бары шәһәрдә, бай йортларында гына пешерәләр. Бүгенге көндә исә, әлеге татлы камыр ризыгыннан башка бер генә бәйрәм дә узмый. Гөбәдия рус теленә “пирог со сложной начинкой” буларак тәрҗемә ителә. Шулай ук рус халык ашларында әлеге ризыкның аналоглары очрамый. Фарсы телендә ул – *гүлибддид* [1: 234]. Әлеге телдә ашамлык атамаларында еш кына гүл, ягъни гөл сүзе очрый (мәсәлән, гөлбәнәк, гүл бдндак – роза формасындагы печенье, гүли рабиййа – катлы камырдан ясала торган печенье һ.б.).

Татар ашлары күптөрле. Аларны бездә генә түгел, чит илләрдә дә яратып ашыйлар. Аш-су әзерләүдә кулланылучы продуктларның күптөрле булуы татар милли ашларының үзенчәлеге булып тора. Милләтебезнең киләчәген күрергә телибез икән, мәдәни үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен, милли ризыкларын, телен саклап, аны киләсе буынга тапшыру – безнең иң төп бурычыбыз.

**Әдәбият**


1. Татарская кухня – 120 домашних вкусных рецептов приготовления. URL: https://1000.menu/catalog/tatarskaya-kuxnya (дата обращения:19.01.2020).
2. Гастрономъ. URL: https://www.gastronom.ru/recipe/group/2644/tatarskaya-kuhnya (дата обращения: 19.01.2020).
3. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том. – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2015. – 543 б.
4. Татар теленең этномәдәният сүзлеге. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2015. – 280 б.

# Р. ШӘЙДУЛЛИНАНЫҢ «ЯЛАНТАУГА АЙ КУНГАН» ӘСӘРЕНДӘ ТАБИГАТЬНЕ САКЛАУ ҺӘМ КЕШЕ БӘХЕТЕ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Низамиев Н., Саба р-ны Шәмәрдән лицее, Х сыйныф*

*Җит. – А.В. Әүхәдиева*

Равилә Шәйдуллина – киң кырлы шәхес.“Ялантауга ай кунган” дигән шигъри исеме белән ук ымсындырып торган китабында янә әсәрләрендә теленең сыгылмалылыгы, байлыгы, образлылыгы белән сокландыра ул.

Табигатьне саклау, кеше бәхете бүгенге көндә дә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Әйләнә-тирәлекне, зарарланудан без туктатмасак, ни булыр соң? Уйлавы да куркыныч. Экологик проблемалар элек-электән әдипләребез тарафыннан күп әсәрләрдә күтәрелгән.

Фәнни-эзләнү эшемнең максаты: “Ялантауга ай кунган” әсәре белән танышып, нинди проблемалар сурәтләнгәнен ачыклау.Тормышка дөрес караш, табигатькә сакчыл мөнәсәбәтне үстерү.

Бурычлар: әсәрне уку һәм экология, кеше бәхете проблемаларын табу, бирелгән проблемаларның хәл ителү юлларын ачыклау.

Табигатьне саклау һәм әхлак проблемасын 19 нчы йөз язучылары да күтәргәннәр. “Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә, гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия- и кирәкле бер эш булачактыр”, – дип язган Р.Фәхретдин [2: 92]. Бу мәсьәлә хәзерге көн язучысы Р. Шәйдуллина әсәрендә дә чагылыш таба. “Үзеңнән соң тәүфыйксыз бала калдырсаң, яшәп тә торасы юк. Чөнки яшәү мәгънәсе – нәсел калдыру. Нәсел агачының тамыры черек булса, нинди кәүсә, нинди яфрак, нинди чәчәк, нинди җимеш инде ул?! Нәсел тамырлары нык булырга тиеш!” [3: 207]. Шулай ук “Ялантауга ай кунган” повестенда табигатьне саклау иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. “Менә шул химиягез белән бөтен табигатьне агулап бетердегез инде сез! Әнә, Мишәдә балыклар бетә бара. Басуларны яраплан белән агулыйлар да, яңгырлар ишле булса, шул агу Мишәгә агып төшә. Караширмә авылында көчле яңгыр булган. Шул яктан, корсакларын ялтыратып, күпме үле балык акты, су өсте ап-ак булып торды.[3: 194]. Әсәренең герое Инсаф та улы Сәетне табигатьне химия белән агулап бетерүдә гаепли.

Әлбәттә, бу инде Сәеткә карата гына әйтелгән сүзләр түгел. Чыннан да, химияне күп куллану кешеләргә, табигатькә күпме зыян сала!

“Ялантауга ай кунган” китабы сугыштан соңгы авыл тормышын чагылдыра. Сюжет, композиция, образларның бирелеше – барысы да халыкчан. Анда тормыш кына түгел, мәхәббәт мизгелләре дә урын алган. “Мин дә йолдызга “Зәйтүнә!” дип дәшәрмен. Һәр кич саен мин синең белән шул йолдыз аша сөйләшермен. Синнән башка саргаеплар үләрмен мин. Моңарчы синсез ничек яшәлгән-белмим” [3: 40]. Автор повестенда

мәхәббәтнең мәңгелек булуын, яшьли туган хисләрнең олыгайгач та сүрелмәвен күрсәтергә теләгән.

“Ялантауга ай кунган” повесте – гаҗәеп якты, эчке тирән сагышлы әсәр. Монда дингә кайту, катнаш никахлар проблемасы күтәрелә. “Безнең бабай әйтә: кайчан да булса яңа мәчетләр салырлар әле,ди. Авылга дин кайтыр, кешеләргә иман кайтыр, ди” [3: 33]. Язучы әсәрендә кешенең эчке дөньясын, рухын тирәнтен сурәтләргә омтыла. Татар укучысына якын сыйфатлар булган әдәплелек үрнәге Нуранияләр, Фатыймалар, Хәятләр үрнәк итеп күрсәтелә. “Бәлки, Хәниянең сөю тулы карашы Сәеткә гарип вакытында кирәк булгандыр. Үзәкләре өзелеп, тәмам өметсезлеккә төшеп, үз уйларыннан уелып торган чагында. Ул вакытта егеткә әтисе, Фатыйма һәм Нурания апалары, “Сак-Сок” бәетен, “Йосыф-Зөләйха” кыйссасын көйгә салып укыган Каракай әбисе терәк булды. Бу миһербанлы кешеләрнең яхшылыкларын ул мәңге онытмас!” [3: 87]. Милләтебезнең Зариф кебек аксакаллары, Сәет кебек асыл уллары әле дә барлыгы сөендерә.

Әсәрдә шулай ук кеше бәхете мәсьәләсе күтәрелә. Без моны бик күп образлар аша күрә алабыз. Мәсәлән, Сәет, Зәйтүнә, Хәния, Мәрьям үз бәхетләре өчен көрәшәләр, тормышның сикәлтәле юлларыннан чыгу юлын эзлиләр. “Сәет Хәнияне рәнҗетте. Әгәр бу ялгышын төзәтә калса, Мәрьям туачак улы яки кызы рәнҗеп калачаклар. Туачак баласын рәнҗетсә, үз намусына хыянәт итеп, гомере буе үкенеп яшәячәк” [3: 148]. “Сәет белән Зәйтүнә, озак итеп, бер сүз сөйләшмичә, аккан суга карап тордылар. Икесе дә бер үк уйда иделәр бугай. Курыкма, Зәйтүнә, мин сиңа булышырмын. Без ул тауның башына менеп җитә алырбыз әле. Моның өчен безнең вакытыбыз да бар, көч-куәт тә җитәрлек” [3: 252].

Повестьта гаилә мөнәсәбәтләре, әти-әни, балалар, дин һәм милләт мәсьәләләре дә күтәрелгән. “Василий – әйбәт кеше, мине бик ярата, ләкин урыс. Әнием минем башка милләт кешесенә кияүгә чыгуыма катгый каршы килгән булыр иде, ләкин ул хәзер үз акылында түгел” [3: 71].

Гомумән, фәнни-эзләнү эше әсәрне өйрәнүгә, вакыйгалар бирелешен, истәлекләрне барлауга корылды. Кеше язмышының бирелеше үзәк урынны алып тора. “Нишләсен ул яшь кыз, көтмәгәндә шундый авыр хәлдә калгач? Зәйтүнәгә бик авырдыр дип уйлап та карамады бит Сәет! Үз кайгысы кайгы булды. Ә Василий исемле урыс егете Зәйтүнәгә таяныч була алган. Ул таяныч Сәет булырга тиеш түгел идемени? Хәзер соң инде...” [3: 87]. Чыннан да, әсәрләр аша тормышны, чынбарлыкны тулырак күз алдына китерә башлыйсың.

Кеше табигать белән бербөтен. “Болын гөж килә-төрле күбәләкләр оча, кошлар сайрый, чәчәкләр хуш исле таҗларын кояшка таба ачалар. Әле бер тапкыр да үбешү тәмен татымаган кызлар ирене кебек кызыллары, кызлар күзләредәй зәңгәрләре, шәмәхәләре бар. Сәет чәчәкләрне кызларга

охшата. Аңа бүген әллә нәрсә булган...” [3: 7]. Якташ язучыларыбыз да әлеге теманы читләтеп узмаган. Ф. Хөсни, С .Зыялы, Н. Хәсәнов, Д. Гайнетдинова, Р. Низамиев, Р. Шәйдуллина әсәрләрендә табигатьне саклау проблемасы турында укып уйланырга җирлек бар.

Шулай итеп, табигать һәм кеше бер-берсе белән бәйле. Тормышта һәрберсе бәхет өчен көрәшә, никадәр авыр сынаулар үтә, үз юлын таба. Ләкин кешелек дөньясы никадәр бәхетле булырга теләсә дә, табигатьтән башка бәхетле була алмый. Шуның өчен тормышта кеше бәхете белән бергә табигатебезнең байлыгын саклау – иң зур бурыч.

**Әдәбият**

1. Зыялы С. Ачылмаган бөре: Повестьлар һәм хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 191 б.

2. Фәхретдин Р.Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Р. Фәхреддиннең мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. VI кисәк. – Казан: ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы нәшрият үзәге, 2010. – 152 б.

3. Шәйдуллина Р. Ялантауга ай кунган: повестьлар. – Казан: Ак Бүре, 2016. – 335 б.

## ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЙ КОМПОНЕНТ В ПРЕПОДАВАНИИ ИНОСТРАННОГО ЯЗЫКА С ПОМОЩЬЮ ПОДКАСТОВ (на примере немецкого языка)

*Низамутдинова Э., КФУ, студент III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, ст. преп. А.Ф. Мухамадьярова*

Знание культуры изучаемого языка имеет особое значение в современном мире, в котором коммуникация на иностранном языке может проходить беспрепятственно благодаря интернет-технологиям и процессу глобализации. Изучение иностранного языка невозможно представить без представления о духовных и материальных ценностях народа, о его мировоззрении, жизненных ориентирах, религии. Культурный компонент отражается в языке в системе базовых убеждений, норм поведения, нравственности. Язык представляет собой не только средство коммуникации, но и транслятор культурных ценностей. Поэтому обучение иностранному языку следует понимать, как непрерывный процесс познания истории и культуры страны изучаемого языка.

Особая роль в формировании знаний о культуре страны изучаемого языка и указанных компетенций принадлежит интернет-ресурсам, ориентированным на знакомство с различными аспектами жизни. Нами рассмотрен социальный сервис сети Интернет – подкасты. Подкасты – это вид социального сервиса Веб 2.0, который создается в соответствии с языковым и тематическим содержанием учебной программы и позволяет пользователям сети Интернет просматривать, прослушивать, создавать и распространять аудио- и видеозаписи (подкасты) во всемирной сети [2: 3]. Первым средством массовой информации, предоставляющим передачи в виде подкастов, была «Немецкая волна», но на данный момент есть множество сайтов, в которых можно прослушать или просмотреть подкасты.

К дидактическим свойствам подкастов относят: звуковую природу, мультимедийность, организацию учебного процесса и времени, интерактивность. Подкасты также улучшают и упрощают организацию учебного процесса, повышая её эффективность. Они развивают самостоятельность и критическое мышление у обучающихся благодаря чему реализуют стандарты современного образования [1: 2-3].

Существует большое количество сайтов, на которых размещены подкасты, содержащие лингвокультурологическую информацию и представляющие особую ценность для изучающих немецкий язык. Некоторые из них предоставляют не только аудио или видео материал, но и задания к подкастам. Ниже приведём основные платформы, которые можно использовать на уроках немецкого языка при формировании и развитии лингвокультурологической компетенции:

1. https://www.dw.com/de/deutsch-lernen/podcasts-newsletter/s-11696

Deutsche Welle – сайт, на котором можно не только читать новости и узнавать последние события, происходящие в мире, но и изучать язык. На платформе предоставлено большое количество как аудио, так и видео подкастов, а также задания к ним. Удобным является то, что они разделены на различные уровни, что облегчает выбор для изучающих немецкий язык. Стоит обратить внимание на серию подкастов *«Das sagt man so!»* на сайте Deutsche Welle. В данных подкастах разбираются наиболее часто используемые немцами фразеологические и паремиологические единицы, даётся краткое объяснение, ситуация, в которой те или иные фразеологизмы и пословицы могут быть применимы, и задания. Весь представленный материал является аутентичным и актуальным, в подкастах не используются выражения, которые невозможно услышать в немецкоговорящей стране. Именно в данных устойчивых сочетаниях наиболее ярко проявляется национально-культурная специфика языка.

2. https://www.deutsch-perfekt.com

Аудиотексты, предоставленные на данном сайте, разработаны журналистами и экспертами по немецкому языку как иностранному и проверены носителями языка. Таким образом, содержание является аутентичным и в то же время легко понимаемым для изучающих немецкий язык. Здесь можно найти интересные статьи для прослушивания и практические упражнения, например, на грамматику или на усвоение пословиц, разработанные для трёх различных уровней. Для каждого текста есть аудиофайл для прослушивания и транскрипты.

3. https://www.duden.de/digitales/podcast

Подкасты представлены на сайте Дуден и находятся во вкладке Sprachwissen. Авторами являются Анетте Ауберле и Евелин Кнерр. На данный момент на сайте размещено 127 аудиоподкастов, посвященных

актуальным темам фразеологии, этимологии, лексикологии, топонимики. Для анализа лингвокультурологического материала выбраны подкасты «Auf den Hund gekommen», «Kleider machen Leute», «Immer auf die FьЯe fallen», «Mit Hand und FuЯ», «Wo sich Fische tummeln», в которых представлена информация о происхождении и значении наиболее известных фразеологических единиц, включающих такие компоненты, как зоонимы, соматизмы, элементы одежды, а также о сфере их употребления.

Все представленные сайты можно использовать на уроках немецкого языка для формирования и развития лингвокультурологической компетенции у обучающихся. Таким образом, введение подкастов в образовательный процесс положительно сказывается на изучение культуры страны изучаемого языка, так как ученики слушают и смотрят аутентичный материал, что позволяет полное погружение в языковую среду.

**Литература**

1. Авраменко А.П. Подкасты и видеоподкасты мобильного формата в преподавании иностранных языков // Вісник Чернігівського національного педагогічного університету (Серія: Педагогічні науки). – 2012. – С. 7–9.

2. Соломатина А.Г. Методика развития умений говорения и аудирования посредством учебных подкастов (английский язык, базовый уровень): дис. … канд. пед. наук. – Тамбов, 2011. – 157 с.

## О ФУНКЦИОНАЛЬНОМ АСПЕКТЕ МЕТАФОРЫ

*Оспанова Ж., ЕНУ им. Л.Н. Гумилева, докторант PhD*

*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. К.К. Дуйсекова*

В настоящее время отмечается новая волна научного интереса к такому традиционному предмету как метафора, взгляд на которую меняется в соответствии с развитием общенаучных парадигм. В античные времена, согласно аристотелевской теории сходства, когда метафора рассматривалась в рамках риторики, считалось, что метафора, как вид тропа и украшение речи, выполняет риторическую и орнаментальную функции. Позже функцию метафоры стали исследовать с позиции мировосприятия. Метафора начинает изучаться в концептуально-логическом (Дж. Вико), психологическом и национально-культурном аспектах (В. Гумбольдт, А. А. Потебня, Г. Штейнталь и др.). Начиная с XX века, когда метафора начинает осмысливаться как один из важных элементов языка и речи, исследования метафоры стали основываться на таких направлениях, как аналитическое (Б. Рассел, Л. Витгенштейн и др.) и прагматическое (Дж. Серль) направления, сравнительная теория (Э. Ортони), концепция сходства (Дж. Миллер), интеракционализм (М. Блэк, А. Ричардс), теория языковых оппозиций (М. Бирдсли) и когнитивизм (Дж. Лакофф, М. Джонсон, Э. Маккормак и др.). Последнее направление способствовало дальнейшему развитию теории концептуальной метафоры, согласно которой метафоре, как феномену мышления, отводится особая роль в формировании мировосприятия [4].

Учеными неоднократно предпринимались попытки классифицировать функции метафоры (Н.Д. Арутюнова, В.Н. Телия, В.Г. Гак, Ю.И. Левин, В.К. Харченко, Г.Н. Скляревская, С.А. Хахалова и др.), выделяя при этом номинативную, экспрессивно-образную, экспрессивно-оценочную и орнаментально-художественную. Представить все классификации в полном объеме не представляется возможным в рамках настоящей статьи.

В связи с «когнитивным поворотом» в языкознании, современными лингвистами все чаще признается когнитивная (познавательная) функция, что связано с анализом мыслительных процессов, логикой восприятия реальности, процессом познания и построения картины мира (Ж. Фоконье, Дж. Лакофф, М. Джонсон, А.Н. Баранов, Ю.Н. Караулов, Е.О. Опарина, А.П. Чудинов, Р.Д. Керимов и др.). Наряду с этим, в ракурсе теории миромоделирования исследователями выделяется миромоделирующая функция метафоры (В.И. Резанова, В.Ю. Пановица, Ю.Б. Феденева, В.В. Кашпур, А.П. Чудинов, Е.А. Юрина, Б.Д. Ныгметова, К.К. Дуйсекова и др.), при реализации которой метафора отражает культурно-исторический опыт того или иного этноса. Под миромоделирующей функцией метафоры учеными понимается способность (пере)конструировать отдельный фрагмент картины мира через язык с использованием реалий определенной лингвокультуры, что способствует созданию языковой картины мира [2: 4], [3: 50], являющейся результатом отражения мира языковым сознанием того или иного культурного языкового сообщества.

Мы, в свою очередь, рассматриваем миромоделирующую функцию метафоры как способность метафоры концептуализировать представления человека об одном фрагменте картины мира на основе аналогии нетождественного объекта или явления; способность создавать новую модель мира, опираясь на имеющийся ранее концептуальный образ с уяснением взаимосвязи между определенными связующими элементами. При этом следует отметить неразрывную связь данной функции метафоры с языковой картиной мира, что наглядно можно подтвердить на примере концепта ДАУ ‘спор’ в казахском языковом сознании.

Концепт ДАУ в казахском языке вербализуется следующими лексемами: *дау* ‘спор, тяжба, иск, претензия, раздоры’, дау-шар ‘споры, раздоры’, *егес* ‘конфронтация’, *ерегіс* ‘пререкание, спор’, *пікірталас* ‘диспут, обмен мнениями’, *пікірсайыс* ‘дискуссия’, талас ‘спор, борьба мнений, диспут’, айғай ‘крик’, айтыс ‘импровизированное песенно-поэтическое состязание поэтов, сопровождаемое игрой на домбре’, бәс ‘пари, спор, соперничество, соревнование’. В отличии от американской культуры, для которой свойственна концептуальная метафора ARGUMENT IS WAR (‘спор – это война’), где спор структурирован в терминах войны, в которой одна сторона, используя стратегии, пытается атаковать и

победить противника, в казахской культуре больше доминирует концептуальная метафора ДАУ – ШЕБЕРЛІК (‘спор – это искусство’, нежели ДАУ – ҚАҚТЫҒЫС (‘спор – это война (сражение)’. Для казахов спор – это изощренность в искусстве аргументации, в словесной перепалке, что наблюдается в содержании *шешендік сөздер* ‘ораторская речь’, *билер туралы аңыздар* ‘легенды о биях (судьях), разбиравших спорные вопросы’, в выступлениях на *айтысах*, когда поэты-импровизаторы состязались друг с другом в словесном искусстве. Так, спорные вопросы могли решаться и несколько дней, чтобы прийти к какому-либо решению: «*Міне, осы дау Арғын, Қыпшақ арасында үш күн сөз болған»* ‘Вот, этот словесный спор между Аргынами и Кипчаками длился три дня’ [1]. В народе также высоко ценится немногословность: *«Жол қуған қазынаға жолығады, сөз қуған бәлеге жолығады»* ‘тот, кто в путь соберется – найдет сокровища, тот, кто сплетничает – попадет в беду’.

В заключение хотелось бы отметить, что метафора, являясь многоаспектным феноменом, представляет собой сложный механизм постижения и переосмысления объективной реальности, создавая новое выводное знание, что указывает на когнитивную природу и миромоделирующую функцию метафоры. Идиоэтнический характер данной функции указывает на национально-специфическое видение мира носителей определенной лингвокультуры.

**Литература**

1. Алматинский корпус казахского языка. URL: http://web-corpora.net/KazakhCorpus (дата обращения: 11.01.2020).

2. Кашпур В.В. Миромоделирующая функция жанров российского политического дискурса. Автореф. дисс. канд. филол. наук. – Томск, 2011. – 24 с.

3. Чудинов А.П. Россия в метафорическом зеркале: когнитивное исследование политической метафоры. – Екатеринбург, 2001. – 238 с.

4. Lakoff G., Johnson M. Metaphors we live by. University of Chicago Press, 1980. – 276 p.

## ТЕЛ – МИЛЛӘТНЕҢ КЫЙММӘТЛЕ ЯДКЯРЕ

*Павлова З., Саба р-ны, Шәмәрдән лицее, Х сыйныф*

*Җит. – Г.Г. Мулласалихова*

Татар теле – дәресләре мәктәптә өйрәнелә торган төп фәннәрнең берсе. Телебез – иң бай, иң матур телләрнең берсе. Татар теле – үзе бер тылсымлы дөнья. Туган телне белү – ул үзеңнең рухи дөньяңны баету, халкыңның үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген таныш-белү.

Соңгы берничә дистә ел эчендә тормышыбызда, яшәешебездә бара торган үзгәрешләрнең берсе – туган телгә, халыкның милли үз аңы дәрәҗәсенә игътибар көчәйде. Дүрт-биш ел эчендә татар теле һәм әдәбият буенча заман таләпләренә туры килерлек дәреслекләр чыгарылды.

Уку-укыту процессында төп ресурсларның яки чараларның берсе булып, һичшиксез, дәреслек тора. Дәреслек – ул төп гомуми белем

программаларын үзләштерүнең предмет буенча нәтиҗәләргә ирешүдә төп чараларның берсе. Татар теле буенча төзелгән дәреслекләр лингвистик компетенцияләр булдыруга хезмәт итә.

Мин рус сыйныфында укыйм. Без Р.К. Сәгъдиева, Э.Х. Кадирова авторлыгында төзелгән дәреслекләр буенча укыйбыз. Кагыйдәләрне өйрәнгәннән соң, күнегүләр эшлибез. Дәреслектә бирелгән текстлар аңлаешлы, теманы аңларга, истә калдырырга ярдәм итәләр. Төрле жанрга караган әсәрләр сөйләшергә, аралашырга өйрәтә. Матур әдәбият әсәрләреннән алынган өзекләрдә һәрберебез проблеманы билгеләп, аны чишәргә тырышабыз. Мондый дәресләр безне алдагы тормышка әзерли. Татар теле дәреслекләрендәге текстлар дөньяның матурлыгын күрергә, әхлаклы булырга, гыйбрәт алырга, өлкәннәргә ярдәм итәргә, табигатьне сакларга, һөнәр сайларга, тормыш юлыннан дөрес барырга өйрәтә. Һәр дәрес нинди дә булса бер тәрбияви максатны үз эченә ала, мәсәлән, ата-анага мәхәббәт, өлкәннәргә хөрмәт, туган илне ярату, хайваннарны рәнҗетмәү, дуслык хисләре булдыру, мөмкинлекләре чикле кешеләргә ярдәм итү, сәламәт яшәү рәвеше булдыру һ.б.

Дәреслектә бирелгән шигырьләрне ятлап, хәтер диктанты язабыз. Болай эшләү орфография, пунктуация кагыйдәләрен истә калдыру белән бергә, шигырьдәге төп идеяне дә аңларга ярдәм итә. Дәреслекләр авторы Р.К. Сәгъдиева фикеренчә: «Рус мәктәбендә укучы татар балалары өчен төзелгән дәреслекләр төп өч максатны күз алдында тота: сөйләм телен үстерү, укучыларны тәрбияләү һәм татар теленең тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәтү. Әлеге өч максат һәрвакыт бер-берсенә үрелеп бара. Бер дәрескә 5-6 күнегү каралса, аларның һәммәсе шул бер максатка юнәлдерелгән текстлардан гыйбарәт».

Дәреслекләрдә халык авыз иҗаты әсәрләреннән мисаллар күп бирелгән. Бу үз чиратында, татар теле һәм әдәбияты фәненең бер-берсеннән аерылгысыз булуын күрсәтә. Мәкальләр, сынамышлар, әйтемнәр, әкиятләр, мәсәлләр һәм табышмаклар татар теле һәм әдәбиятының аерылгысыз булуын күрсәтә. Мондый эш төрләре безне ялыктырмый, киресенчә, кызыксындыра. Халык авыз иҗатыннан китерелгән әсәрләр грамматик тема белән бәйле эш башкару өчен бирелгән. Мәсәлән, мәкальләрне укыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз: 1) Дөньяны яуларга омтылма, аның гыйлемен яуларга омтыл; 2) Дөнья тулы гыйлем, башыңда калганы – белем [1: 18] Шулай ук исем темасын өйрәнгәндә дә, морфологик анализ ясау, икенче бер күнегүдә мәкальләрнең беренче өлеше белән икенче өлешен туры китереп уку өчен мәкальләр бирелгән: 1) Авызындагы тешенә карама, белмәгән бармагын тешләр; 2)Тырышлык бәхет китерер, кулыннан килер эшенә кара; 3) Белгән белгәнен эшләр, ялкаулык ачтан үтерер һ.б. [4: 6]. Алга таба мәкальләр

белән бәйле биремнәр катлаулана. Мәкальләрдәге сүзләргә тиешле сузык хәрефләрне куеп уку һәм күчереп язу кебек эш төрләре башваткыч формасында тәкъдим ителә: «Баал чаатк аганл беемл таакш яагзн сзү беәнл бре» [5: 140]. Бу күнегүләрне без яратып башкарабыз.

Җөмлә синтаксисын өйрәнгәндә, Р. Миңнуллинның «Кураем» шигыре бирелгән. Сыйныфташларым арасында, кызганычка каршы, курайның ни икәнлеген аңламаучылар да табылды. Бердән, халык уен коралы турында мәгълүмат бирелә, шигырьдән аныклагычны табып, аның янында нинди тыныш билгесе куелуын аңлап калдык, раслау һәм инкарь җөмләләрне кабатладык. Текстлар яңа дәрес материалын гына аңлатып калмый, алдагы дәресләрне ныгытып барырга да ярдәм итә.

Кушымчаларны өйрәнгәндә, мисалга сынамышлар бирелгән. Алар уйланырга, ниндидер тәҗрибәләр ясарга, халык сүзенә колак салырга ярдәм итәләр. Мәсәлән, 1) Сентябрь яшен яшьнәсә, көз җылы килер; 2) Урман.. миләш күп булса, көз яңгырлы килер; 3)Төш.. соң яңгыр башланса, ул озак явар [2: 53]. Дәреслекләрдә бирелгән юраулар да дәресне кызыклы һәм файдалы итеп үткәрергә ярдәм итә: 1) Кисеп куйган икмәк ишелеп төшсә, кунак килә; 2) Колак кычытса, кар ява [3: 79].

Кыйссалар фикерләргә, нәтиҗә ясарга өйрәтәләр. Безнең һәрберебезнең кимчелекләре бар. Мәсәлән, «Ике чүлмәк» дип аталган кыйссада кешене ул ничек бар, шулай кабул итәргә һәм аның яхшы якларын күрә белергә кирәк, дигән фикер үткәрелә.

Мәдәниятне, халык тарихын, әдәбиятны яхшы белгән очракта гына телнең нечкәлекләрен тоярга мөмкин. Татар теле дәресләрендә бирелгән күнегүләр, текстлар ярдәмендә без куелган бурычны үтәргә омтылабыз.

**Әдәбият**

1. Сәгъдиева Р.К., Гарәпшина Р.М., Хәйруллина Г.И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 6 нчы с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015. – 191 б.

2. Сәгъдиева Р. К., Кадирова Э. Х. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 9 нчы с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2017. – 143 б.

3. Сәгъдиева Р. К., Хәйруллина Г. И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 8 нче с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2016. – 223 б.

4. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 7 нче с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015. – 215 б.

5. Сәгъдиева Р. К. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 10 нчы с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2017. – 167 б.

# НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ – ДРАМАТУРГ

*Пазюкова И., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Л.Ф. Җамалиева*

Нәкый Исәнбәт – татар драматургиясенең төрлелеген, үсеш-үзгәрешен, тема һәм жанр байлыгын, заман проблемаларын чагылдырган авторларның берсе. Ул әдәбиятта үз йөзе, үз урыны булган, театр сәхнәләрендәәсәрләре зур уңыш белән барган каләм иясе."Үзе бер фәннәр академиясе", "аяклы энциклопедия", "барлык хезмәтләрен бергә җыеп бастырсаң, егерме томлы китап чыгар иде" – әлеге эпитетлар бөек галим, драматург, шагыйрь Нәкый Исәнбәт хакында [1: 19].

Бер гасыр диярлек озын гомер яшәп тә, әллә ничә юнәлештә берьюлы искитмәле эшләп тә, Нәкый ага үз зурлыгына лаек олылау ишеткән шәхес түгел. Әйе, ул мактаулы исемнәр дә, Тукай бүләге дә алган. Ярый әле, Камал театрыбыз бар, аның милләт хадимнәренә һәрдаим игътибарлы җитәкчелеге бар. Һәм ярый әле, шушы театрыбыз Нәкый Исәнбәт иҗатына, драматургиясенә әледән-әле мөрәҗәгать итеп тора. Заманында (инде ничә куелышта!) Исәнбәтнең "Хуҗа Насретдин"ы шаулап барган[2: 40]. Шамуков, Халитов, Надрюков, Хәким Сәлимҗанов чорына өлгермәсәм дә, Равил Шәрәфи, Ренат Таҗи, Дания Нурлы, Хәлим Җәләй, Ирек Баһман һәм башкалар уйнаган спектакльләр халык хәтерендә калырлык булган, шөкер.

Камал театрының 112 нче сезонының төп премьерасы –Нәкый Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу» 5 пәрдәлек трагедиясенең сәхнәгә куелышы булды! Моны халык зарыгып көтте дияргә була.

Бик бәхетле булып яшәү турында кемнәр генә хыялланмый икән?! Сөйгән ярый янәшәсендә булуны кем генә теләми икән?! Миркәй белән Айсылу да мәхәббәтләре тамырына балта чабуны теләмәгән, ләбаса!

Спектакль Гофрай белән Ләйлинең кызы Айсылуның сөйгәне Миркәй кайту белән башланып китә. Айсылу, үз чиратында, сөйгәненә дип куъяулык чигеп куган ә Миркәй исә Айсылу белән кавышып, аны үзе эшли торган Урал якларына алып китәргә дип кайткан.

Бөтен халык алдында “тотылдылар” дип яла ягу – Зәмир Дәүлие, ат карагы Әхтәрҗан, бөкре Гариф өчен үч алырга менә диән сәбәп була. Күптән Айсылуны үзенеке итәргә йөргән Зәмир Дәүлие үч ачу планына әкренләп ирешүе була бу. Муллалар да бай малае Зәмир Дәүлинетыңлый, гади эшче егет Миркәйнең “Алдыйлар, дөрес түгел”дигән сүзләрен колакка да салмый. Хәтта Айсылуның этисе дә, кеше сүзенә ышанып, кызына таяк белән кизәнә. Айсылу да, Миркәй дә күп мыскыллаулар, җәберләүләр аша уза. Соңыннан Айсылу хәтта кешене кешене танымаслык хәлгә җитә, аның күзенә гел Миркәй күренә, акылдан яза...

Автор әсәрен трагедия дип бирсә дә, спектакль программасында ул «2 пәрдәлек драма» итеп куела. 1935 нче елда иҗат ителгән пьеса, 82 ел узса да, актуальлеген югалтмаган. Көнчелек, яла ягу, үз фикереңнән куркып, күпчелек артыннан иярү; байлар һәм ярлылар темасы бүгенге көндә дә актуаль.

1936 елда әлеге әсәр беренче тапкыр сәхнәгә куела. Бу әсәр 1966-1974 елларда Марсель Сәлимҗанов куелышында зур аншлаг белән барган. Камаллыларның яңа сезонда, М.Сәлимҗановның туган көне алдыннан, шушы пьесага алынулары да юкка гына түгелдер бәлки.Бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгын каршылау уңаеннан, РСФСР күләмендә үткәрелгән смотрда бу спектакль өчен театрга икенче дәрәҗәле диплом да тапшырылган.

112 нче сезонда бу әсәрне драматург Илгиз Зәйниев сәхнәләштерде.

Әсәрнең тексты белән чагыштыранда үзгәрешләрне дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, Айсылуның апасы Вәрәкыяның ире Җаннур, Сафия дигән геройлар спектакльдә очрамый. Режиссер спектакльдә төп игътибарны төп геройларга юнәлтә. Аеруча Миркәй белән Айсылуны җәберләгән күренешләр, аларның кулларын бау белән бәйләп куюлар, Миркәйне кыйнаулары.

Һәрбер әсәрдә явыз кешене уйнаган геройлар була.Бөкре Гариф (Алмаз Гәрәев), мәкерле җанны гәүдәләндергән тагын бер образ – Зәмир Дәүлие (Артур Шәйдуллин).

«Сабыр төбе – сары алтын» дигән девиз белән яшәгәнзирәк, акыллы Әһли карт (Хәлим Җәләлов) “Яулык бирешкән өчен кыз өстенә сөйлиләрмени?”ди зирәк карт. Тик берүзе илгә каршы чыга алмый.

Тамаша башлану белән, сәхнә буйлап тезелгән, бауга асылган чиләкләргә игътибар итмичә калып булмый. Иң беренче пәрдәдәге чиләкләрнең саны 20гә җитә. Әдәбиятта «чиләк» сүзе коры, аяз һава торышын аңлата. Авыл халкының үз борчуы, ул яңгыр яумавына, игеннәр көячәгенә борчыла. Драма геройларының киемнәренә дә игътибар итмичә булмый. Геройларның барысы да диярлек күзгә ташланмый торган киемнәрдән. Миркәй белән Айсылу гына ак төстән киенгән. Бу үзе үк егет белән кызның гөнаһсызлыгы турында сөйли түгелме?! Шул ук вакытта аларның эчкерсез мәхәббәте турында әйтеп тора диярга урын бар. Миркәй белән Айсылуның да сөюләре ак сөлге кебек чиста.

Кызның бирнәсе дә әзер: озын ап-ак сөлгене ул үзе җәеп карый. Гадәттә, сөлге дә бит тормыш юлын, озын юлны аңлата. Тик яшьләрнең юлы гына трагедиягә әйләнә.Миркәйнең Айсылуга бүләк иткән шәле дә символик мәгънәгә ия.Мондый шәлне бүләк итү купшылыкны аңлата. Егетнең кызга тагын бер бүләге бар: шомырт чәчәге исле сабын.Шомырт агачы элек-электән үк яшьлек, сафлык, мәхәббәт символы булган [3: 51].

**Әдәбият**

1. Миңнуллина Ф.Х. Н. Исәнбәт драматургиясендә шәхес иреге // Фәнни Татарстан, 2017. – №4. – 67 б.
2. Галимуллин Ф. Эзләнү вакыты. – Казан: Мәгариф, 2005. – 247 б.
3. Шәрәфиева Ә. Миркәйнең дә, Айсылуның да икесе бергә үлүе яхшырак әле... // Шәһри Казан. – 2017, 10 ноябрь.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «КАЗАКЪ КЫЗЫ» РОМАНЫНДАГЫ ЭТНОЛЕКСИКА

*Рамазанова А., М. Акмулла ис. БДПУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. И.С. Насипов*

Г. Ибраһимов гаҗәеп бай әдәби һәм фәнни мирас калдырган шәхесләрнең берсе. Утыз еллык иҗат гомерендә ул егермеләп хикәя, өч повесть, дүрт роман, бер пьеса, аерым китап булып чыккан унике фәнни хезмәт, биш йөзгә якын тәнкыйди һәм публицистик мәкалә, тел һәм әдәбият буенча уннан артык дәреслек бастырып чыгара.

XX йөз башында әдәби телне демократлаштыруда һәм аны бердәм нормаларга китерүдә, башка язучылар белән беррәттән, Г. Ибраһимовның да лаеклы өлеше бар. Башка әдипләрдән аермалы буларак, Г. Ибраһимов үзенең эшчәнлеген төп ике юнәлештә алып бара. Беренчедән, ул, күренекле тел галиме буларак, әдәби телнең фонетик, орфографик, лексик, грамматик нормаларын чагылдырган тел белеменә караган хезмәтләр яза, шул рәвешчә, татар тел гыйлеменә үзеннән зур өлеш кертә. Икенчедән, Г. Ибраһимов телнең эчке мөмкинлекләреннән, халыкның җанлы сөйләменнән файдаланып, әдәби тел нормаларын киң халык массасына җиткерүдә зур эш алып бара һәм күп әсәрләр иҗат итә [4: 66]. Ул үзенең иҗатында бер татар тормышы белән генә чикләнеп калмады, башка халыклар тормышына да үтеп керде, алар турында гүзәл әсәрләр иҗат итте. 1924 нчы елда Мәскәүдә СССР халыклары үзәк нәшриятында басылып чыккан “Казакъ кызы” романы әнә шуның мисалы иде. Бу әсәр 1923 елның көзендә төгәлләнгән булса да, языла башлау тарихы әле революциягә кадәрге үк чорга карый. Г. Ибраһимов аны 1909 нчы елның җәендә Уралда Миас заводы поселогында яшәгән чагында яза башлап, 1911 нче елда Казанда тәмамлый.

Г. Ибраһимов “Казакъ кызы” әсәрендә казакъ кызы язмышы мисалында инкыйлабларга кадәрге казакъ тормышын сурәтләүне максат итеп куя. Анда сурәтләнгән вакыйгалар, романда китерелгән кайбер тарихи мәгълүматлардан аңлашылганча, XIX гасыр ахыры-XX гасыр башларындагы чорга карыйлар: капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керә башлый, ыруглар арасында тарткалаш китә. Чөнки җир казакъ халкы өчен иң кирәк нәрсә, иң зур байлык булып санала [1: 11].

Без бу кечкенә хезмәттә “Казакъ кызы” романындагы этнолексикага игътибар юнәлтергә булдык. Г. Ибраһимовның “Казакъ кызы” романындагы этнолексиканы төркемләү өчен Ф. Фасеевның “Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сораулык” файдаланылды. Сораулык татар теленең сүз байлыгын тормышның, чынбарлыкның барлык өлкәләре буенча мөмкин кадәр тулырак итеп җыеп алуны тәэмин итәргә омтыла. Шул максаттан чыгып ул дүрт зур бүлектән торган тематик күрсәткеч рәвешендә эшләнгән. Һәрбер бүлек – бүлекчеләргә, бүлекчәләр – темаларга бүленәләр [5: 4].

Тел ул кешеләрнең иҗтимагый тәҗрибәсен саклаучы чара, үзенең эченә халыкның тарихи тәҗрибәсен кертә, үзенчәлекле менталитетын һәм эчке дөньясын чагылдыра. Һәр халыкның телендә кешеләрнең көндәлек сөйләшүендә лексик системалар урын алып тора [3: 43]. Г. Ибраһимовның “Казакъ кызы” романын анализлау нигезендә түбәндәге этнолексик составны бүлеп чыгарырга мөмкин:

1) ТАБИГАТЬ:

– табигатьнең сыйфатламалары, урын (пространство): *кыйбла, җот, куй, колын, айгыр, бия,бүлтерек, тулпар, кола;*

2) КЕШЕ:

– тән төзелеше**:** *куен, яңак, кодалык;*

– кешенең көнкүреше, авыл көнкүреше, кием-салымнар һ.б.ш. тегелгән әйберләр: *кәләпүш, казаки, постау, кәмәр, бишмәт, чалма, көпе;*

– кеше һәм җәмгыять, кешеләрнең төрле иҗтимагый формацияләрдәге бергәлекләре: *кәрван, кабилә, ыруг;*

– кешенең көнкүреше, йорт хуҗалагы, көндәлек көнкүреш эшләре: *киез;*

– кешенең көнкүреше, авыл көнкүреше, савыт-сабалар һәм гомүмән кухня кирәк-яраклары: *комган, пешкәк, саба, ләгән, турсык;*

– кешенең көнкүреше, авыл көнкүреше, ашамлык-эчемлек исемнәре һәм аларны хәзерләүгә караган атамалар: *күҗә,куырдак, локма, җәймә, эремчек, кымыз, казылык;*

– кешенең көнкүреше, авыл көнкүреше, каралты тирәсе әйберләр, хуҗалык корылмалары: *колга, пәке;*

– кешенең көнкүреше, өйнең эчке төзелеше: *әрҗә, ятак;*

– кешенең яшәвендә төрле чорлар: *ләхет;*

– кешенең көнкүреше, авыл көнкүреше, авыл һәм аның төзелеше: *җәйләү;*

– кешенең көнкүреше, авыл көнкүреше, йорт һәм аның тышкы һәм эчке төзелеше, бизәлеш: *тирмә;*

– җәмгыять, экономика, авыл хуҗалыгы, ат җигү: *камчы, камыт;*

– экономика, авыл хуҗалыгы, утырыш: *мәҗлес;*

– авыл хуҗалыгы, кыр-басу эшләре, печән чабу*: кибән.*

Мондый сүзләрне өйрәнүнең әһәмияте бик зур. Этномәдәни сүзләр халыкның тормышын, характерын, яшәү тәҗрибәсен, аралашуын, хезмәтен чагылдыралар. Этнокультур сүзләр безнең тормышыбызда бик зур роль уйный, һәм аларны төркемләү, ачыклау эше дәвам итә.

**Әдәбият**


1. Ибрагимов Г. Г. Казакъ кызы.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 191 б.
2. Ибраһимов Г. Казакъ кызы: хикәяләр, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 384 б.
3. Жамалетдинов Р. Р., Нурмухаметова Р. С. Татар теленең этнокультура сүзлеге: матди мәдәният лексикасы (сүзлек-белешмәлек). – Казан: Отечество, 2012. – 146 б.
4. Поварисов С. Ш. Особенности стиля Г. Ибрагимова и изучение их в школе. – Уфа: БашГУ, 1974. – 200 с.
5. Фасеев Ф. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сораулык. – Казан.: Академия наук СССР, 1958. – 105 б.


## Ф. ЯРУЛЛИННЫҢ ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ ХЫЯЛ ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫКНЫ БИРҮДӘ ТЫЛСЫМ ЭЛЕМЕНТЛАРЫ


*Рамазанова Г., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., доц. Л.И. Минһаҗева*


Ф. Яруллин әкиятләре балаларның хыялын кузгата, аларның серле күңел сандыгына ачкыч таба. Чөнки алар балалар рухына, аларның табигатенә туры килердәй итеп язылган, балаларга таныш тормыштан алынган, халык иҗатындагыча гади, җыйнак, поэтик бизәкләргә бай. Әдип үзенең "Алабай белән Сары", "Кызыл алма", "Пеппи", "Кара бәхет", "Ак каз" һ.б. әкияти әсәрләре белән балаларны гына түгел, өлкәннәрне дә игътибарлы булырга, әйбәт гамәлләр кылырга чакыра.

Фәнис Яруллин әкиятләрендә телгә сак мөнәсәбәт, шигъриятлелек чагыла, хәтта кайбер әкиятләрен ул телнең бөтен мөмкинлекләрен ачар өчен яза кебек. Автор үз әкиятләрендә иң мөһим нәрсә итеп физик көчне түгел, әхлакый сафлыкны, намусны һәм вөҗданлылыкны куя.

Ф. Яруллин әкиятләренең тормышка якын булуын әйтеп үтәргә кирәк. Хәтта аларны әкият белән хикәя арасында торучы бер жанр дип тә карарга мөмкин. тузга язмаган куркыныч фантастика телевизор экраннарын яулаган чорда мөхтәрәм авторыбызның тормышчан әкиятләр язуы, бала күңеленә явызлык, кансызлык үтеп кермәсен дип тырышуы, явызлыкка яхшылыкны каршы куеп көрәшүе күңелдә якты хисләр уята.

Хыял һәм чынбарлык чагылышына килгәндә, Ф. Яруллиның тылсымлы әкиятләрендә хыял һәм чынбарлык чагылышы тылсым элементлары аша бирелә. Тылсымлы әкиятләргә "Йолдыз тапкан кыз", "Тылсымлы ачкыч", "Яралы торна", "Хәким аланы", "Зәңгәр күлдә ай коена" һ.б. әкиятләре керә.

"Тылсымлы ачкыч" исеменнән күренгәчә, тылсымлы әкият биредә тылсым мотивы өч ачкыч белән ачыла: бакыр ачкыч, көмеш ачкыч, алтын ачкыч.

Әкият мифологик мотивларга нигезләнгән, ул үзенең идея-эстетик өлгергәнлеге, тәрбиви максатларны тормышка ашыруы белән аерылып тора. Әсәрнең төп герое – Ибрай – бәхет эзләп өеннән чыгып китә: *“Дөнья гизәрмен, зиһенемне чарлармын, акыл җыярмын. Күңелемнең каен тузыдай ап-ак чагы, анда берни язылмаган. Күргәннәремне шул хәтер дәфтәремә теркәрмен...* [7: 46].

Ибрайның юлында хикмәтле бер карт очрый, ул бер көнбагышны ашый, берсен җиргә бәрә. Әкиятнең төп идеясе шушы карт сүзләреннән әйттерелә: *“Кешеләр дөньяда нәрсә дә булса калдырырга тиешләр. Ичмаса, үзем үлгәч шулар үссен”* [7: 47].

Ибрай үз юлында төрле сынауларга юлыга: аңа өч төрле сарайга керергә кирәк. Әмма бакыр сарайга керү өчен – өч яңа табышмак, көмеш сарайга керү өчен – өч мәгънәле сүз һәм алтын сарайга керү өчен китаплар укырга, белем алып керергә кирәк була. Әсәрнең төп идеясе – уйла, фикер йөрт һәм алтын ачкычны яңа буынга биреп калдыр. Шулай итеп, автор укучыларны яхшылык эшләргә, яңалыклар ачарга чакыра.

Чынбарлык белән хыялны бирүдә автор ачкыч мотивын куллана дидек. Биредә ачкыч символ буларак бирелә. Бу белемгә юл дигәнне аңлата. Эмоциональлекне арттыру өчен автор өчле санына мөрәҗәгать итә. Белгәнебезчә, өчле саны әкиятләрдә еш очрый. Шулай итеп, “Тылсым ачкыч” әсәрендә төрле халыкларның әкиятләрендәгечә зирәклекне, тапкырлыкны мактау өстенлек ителә.

“Хәким урманы” әкияте дә уйдырмага корылган. Биредәге аждаһалар, хайваннарның сөйләшүе, каеннарның кешеләрнең дәвалавы – барсы да мифологиядән. “Аждаһа – геройның дошманы. Ул күбесенчә берничә башлы итеп сурәтләнә (ике, өч, дүрт, алты, җиде, тугыз, унике башлылары очрый)”[4: 22]. Әмма биредә ул җиде койрыклы итеп сурәтләнә.

Әкияттә тылсым мотивы – каеннарда бирелә. Белгәнебезчә, каен агачы – татар халкының символы. Әсәрдә автор каеннарны болай сурәтли: *“Каеннарның бик зур сергә, сихри көчкә ия булулары. Әйе, бу каенлыкка картлар килсә – яшәрә, авырулар килсә – савыга, сукырлар – күрә, чукраклар ишетә башлый икән”* [5: 62].

Әлеге каеннарны авыл батырлары түгел, ә авылның акыллы карты коткара. Ул аждаһага ияреп китә, аларга урман утырта. Әмма, кызганыч, ул Хәким карт аждаһалар илендә картаеп үлеп тә кала. Патшалыктагы җәнлекләр өч көн буе ашамаганнар, көне-төне елашканнар, улашканнар. Моннан соң кеше затына зыян китермәскә ант та иткәннәр. Күргәнебезчә, автор бирдә акыл көченең физик көчкә, мускул көченә кааганда күпкә көчлерәк, файдалырак булуын искәртә.

Ф. Яруллинны хыялны тылсымлы, әкияти мотивлар белән бирә. Мәсәлән, тылсымлы каеннар, аждаһалар, урман утыртучы җәнлекләр.

Әкияттә чынбарлыкка да урын бар. Каеннарны саклый алмаучы батырлар качу юлын сайлыйлар. Әмма качып кына каенлыкны саклый алмыйлар. Чынбарлык белән тылсым үзара үрелеп барып, сюжетны кызыклы итә, укучыны үзенә җәлеп итеп тора.

Ф. Яруллин әкиятләрен укыганда шуны күрәсең: һәр вакыйга баланың үсү процессын күз алдында тотып, күзгә күренмәслек, ләкин сизгер йөрәк тоярлык итеп катламнарга бүленеп бирелә. Әйтик, бала кечкенәрәк чакта әкиятнең мавыктыргыч сюжетын, әкият геройларының явыз көчләрне җиңүен хәтеренә сеңдереп калса, тора-бара, үзенең аң үсешенә карап, әсәрнең эчке фәлсәфәсенә, фикер тирәнлегенә төшенә башлый.

Ф. Яруллин әкиятләре – безнең татар әдәбиятында яңа күренеш. Аның әкиятләрен укыганда шуны күрәсең: һәр вакыйга баланың үсү процессын күз алдында тотып, күзгә күренмәслек, ләкин сизгер йөрәк тоярлык итеп катламнарга бүленеп бирелә. Әйтик, бала кечкенәрәк чакта әкиятнең мавыктыргыч сюжетын, әкият геройларының явыз көчләрне җиңүен хәтеренә сеңдереп калса, тора-бара, үзенең аң үсешенә карап, әсәрнең эчке фәлсәфәсенә, фикер тирәнлегенә төшенә башлый.

**Әдәбият**

1. Сверигин Р. Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. – 1999. – №6. – Б. 126–128.

2. Хәкимова С.Г. Фәнис Яруллин: Тормыш һәм иҗат батырлыгы. – Казан: “Идел-Пресс”, 2007. – 192 б.

3. Хуҗиәхмәтов Ә., Хәкимова С. Фәнис Яруллин – шәхес, шагыйрь, тәрбияче // Яруллин Ф. Сайланма әсәрләр. – Казан.: Хәтер, 2002. – Б. 3–16.

4. Яруллин Ф. Зәңгәр күлдә Ай коена: әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 272 б.

5. Яруллин Ф. Серле дөнья: әкиятләр, хикәяләр һәм повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 464 б.

## Ф. ЯРУЛЛИН ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ ТЕЛ-СТИЛЬ ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ АЛАР АША ДӨНЬЯНЫ СУРӘТЛӘҮ

*Рамазанова Г., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., доц. Л.И. Минһаҗева*

Ф. Яруллин әкиятләрендә хыял һәм чынбарлык берләштерелеп тә бирелә, кайвакыт алар кисешәләр, кайбер әсәрләрендә бары тик уйдырма гына урын ала. Шуларга карамастан, Ф. Яруллин әкиятләре тәрбияви моментларны истә тотып язылган, аларның теле матур, төрле стилистик фигураларга, лексик чараларга бай.

Хыял һәм чынбарлыкны бирүдә чагыштырулар зур урын алып тора. Һәр язучы да чагыштыруларны яратып куллана. Ф.Яруллин әсәрләрендә аларның шактый үзенчәлекелләрен очратырга була, чөнки чагыштырулар вакыйгаларны җанлырак итеп сурәтләргә мөмкинлек бирәләр. Мәсәлән, “Хәким урманы” әкиятендә мондый җөмлә бар: “Хәтта күзләре фонарь кебек янарга тотынган” [5: 71]. Биредә язучы аждаһа күзләрен фонарь белән

чагыштыра, чөнки әлеге күзләрдә ачулану, ярсу чагыла. Әлбәттә, әлеге чагыштыру чынбарлыктан ерак, әмма карашны фонарь яктылыгы белән чагыштыру Баш Аждаһаның ни кичергәнен укучыларга җиткерүдә ярдәм итә.

“Әгәр минем сүзләремә генә ышанмасагыз, кемгә дә булса яхшылык эшләп карагыз, шунда сез Айның тылсымлы нурларында коенгандай матурланып китүегезне күрерсез” [5: 84] (“Зәңгәр күлдә ай коена” әкияте). Биредә автор матурлануны – тылсымлы ай нурларында коену белән чагыштыра. Айны коткарган Айсылуның матурлану гаҗәп күренеш түгел, кешегә яхшылык эшләсәң, эчеңдә матурлык булса, ул тышкы кыяфәттә дә, йөз дә чагыла. Әкияттә Ай әлеге процессны тизләтеп кенә җибәргән. Шулай итеп, аның матурлыгы Айсылуга да күчкән.

Кайвакыт чагыштыру болай караганда логик чагыштыру гына кебек: гадәттәгечә зурлыкны, күләмне, төсне һ. б. белдерә, ләкин бер үк вакытта ул ике әйбер арасындагы охшашлыкның кайсыдыр аерым үзенчәлекле ягын да тотып ала. Менә шул үзенчәлекле як чагыштыруга гадәттәгечә булмаган яңгыраш бирә, ягъни билгеле бер әйберне башка шундый әйберләрдән аерып торырлык итеп күз алдына бастыра. Бу чыннан да сурәтле чагыштыру яки, башкача әйткәндә, метафорик чагыштыру булып чыга. Мәсәлән: “Кеше аяк басмаган әлеге утрауда, мин сиңа әйтим, һәртөрле җимеш агачлары сыгылып утыралар, кавын-карбыз таудагы ташлар кебек кояшта кызынып яталар” [5: 41] (“Яз кайда кышлый”). Кавын-карбыз таудагы ташлар кебек кояшта кызынып яталар – метафорик чагыштыру. Биредә бер караганда кавын-карбыз турында гына сүз бара кебек. Ләкин бөтен хикмәт – нәрсә белән чагыштыруда. Биредә автор кавын-карбызның кояшта билгеле бер төскә кереп, формага кереп ятуын сурәтли, чагыштыруның көче менә шул үзенчәлекнең сүз белән әйтелмичә, аны укучының фантазиясенә калдыруда, укучының аны үзе бик тиз төшенеп алуында, күз алдына китерүендә.

Әдәбиятта тормыш күренешләрен, кешенең эш-гамәлен арттырып сурәтләүгә гипербола диләр. Әкиятләрдә гипербола аеруча яратып кулланыла. Алар хыялларны бирүдә актив сурәтләү чарасы булып торалар. Мәсәлән: “Ай чыкмаган, ә йолдызлар йоклаган, ди” [5: 76] (“Ак каз” әкияте). Биредә автор йолдызларны йоклаган ди. Әлбәттә, бу арттыру, алар болыт аркасында күренмиләр генә.

“Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шулвакыт кояштагы караңгылык кими башлаган” [5: 86] (“Кояштагы тап”). Әсәрдә малайның алдавыннан кояш кинәт кенә карала башлый. Әлбәттә, әлеге юллар гипербола, күчерелмә мәгънәле сүзләр. Әмма шулай да биредә чынбарлык сурәтләнеше дә бар дип әйтә алабыз. Әнине алдау – аның күзләрендә кешелеклегеңне югалту белән бер, димәк, синең яхшы якларың юкка чыга, карала башлый. Ә әнинең гафу итүе, шул караңгылыктан котылу чарасы ул. Шулай итеп,

кояштагы караңгылыкның әни кочагыннан кимүен гипербола итеп карасак та, тормыш шартларында ул бер дә арттыру түгел дия алабыз.

“Бер якта тешләрне сындырырлык салкын сулы чишмә ага икән” [5: 104] (“Акайкүз” әкияте”). Тешләрне сындырырлык салкын сулы чишмә – гипербола. Бик салкын суны арттырып тешләрне сындырырлык дип атыйлар.

Тел-стиль чараларыннан автор эпитет һәм метафораларга актив мөрәҗәгать итә. Мәсәлән: “Ә исенә килеп кайтырга чыкканда төн үзенең кара җәймәсен күктән җиргә кадәр җәеп куйган булган” [5: 20].

Ф. Яруллин гиперболаны тасвирлау чарасы итеп кенә түгел, ә сюжет эченә дә кертеп җибәрә. Мәсәлән: “Йокымсырап киткән чакларында үз канатыннан үсеп чыккан кызыл чәчәкләр әллә нинди матур кошларга әверелеп һавага очканнар. Әгәр ул кошлар кешеләрнең иҗнәренә килеп кунса, иң ямьсез кешеләр дә матураеп китә икән. Бөкреләр – турая, күзсезләрнең күзе ачыла, телсезләр телгә килә, боеклар – елмая, авырулар – терелә, картлар яшәреп китә икән” [5: 31].

Кара җәймә – метафора. “Метафора – бер әйбер, эш яки хәл үзара охшашлыгы нигезендә икенче бер әйбер, эш яки хәл исеме белән алыштырып әйтелсә, метафора хасил була. Метафора – шул ук чагыштыру, ләкин кыскартылган яки яшертен чагыштыру; чагыштыруда ике мөстәкыйль сүз булса, метафорада бер генә сүз, – шул бер сүз охшаш күренешне дә, исеме шул сүзгә күчерелгән әйберне (күренешне, эш яки хәлне) белдерә [2: 83]. Автор төн җитүен кара җәймә белән чагыштыра, әмма ул турыда конкрет әйтми, яшерен чагыштыру, ягъни метафора хасил була.

Алдагы мисалда автор күпләп эпитетлар куллана: “Баш калкытырга вакыт тапмый җирдә нидер казынучы кешеләр торналарның сагышлы-моңлы җырын ишетеп башларын калкытып күккә караган. Торналарның шундый матур очулары, ак каурыйларын җиргә сибә-сибә туган яклары белән саубуллашып йөрүләре һәркемнең күңелендә матур истәлекләр уяткан” [5: 27]. Әлеге җөмләләрдә автор эпитетлар ярдәмендә чынбарлыкны шундый итеп сурәтли, хыял дөньясына эләккән кебек буласың.

Шулай итеп, Ф.Яруллин әкиятләрендә эпитет, метафора, чагыштыру, гипербола кебек стилистик фигуралар очрый. Алар образларны, күренешләрне сурәтләү буларак кулланылган. Икенчедән, автор әлеге сурәтләү чаралары аша укучыларга хыял һәм чынбарлыкны тасвирлый.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

2. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

3. Минһаҗева Л.И. XX гасыр татар балалар әдәбиятының үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре. – Казан: Хәтер, 2011. – 312 б.

4. Татар әдәбияты. Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

5. Яруллин Ф. Серле дөнья: әкиятләр, хикәяләр һәм повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 464 б.

ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ РЕЧЕВОГО АКТА «ОБЕЩАНИЕ»

*Рахматуллина Ф., КФУ, магистрант 1 курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Г.А. Набиуллина*

Исследования национально-культурной специфики того или иного этноса на основе анализа литературной картины приобретают особую актуальность когнитивной лингвистике. В данной статье ставится задача рассмотреть лингвокультурологические особенности речевого акта «обещание» на материале татарского художественного дискурса.

Обещание (ст. слав. – договор) – обязательство кому-то что-то выполнить, даваемое по собственной инициативе и добровольно. Обещать – это давать заверение, уверять кого-то в чем-то, подавать надежды, внушать ожидания. Обещание требует последующего непременного выполнения, его суть и состоит в том, что невыполнение считается нравственным грехом перед Богом и самим собой прежде всего, а не только перед тем, перед кем оно не выполнено. Дети часто пользуются этой формой взаимоотношений, на чем учатся быть верными своему слову, воспитывают волю. [1: 273–275]. Данный лексикон имеет несколько значений, которые используются в разных контекстах: завет, зарок, клятва, носовожденье, обет, обетование, обнадеживание, обязательство, подписка, поллицитация, посул, присяга, расписка, слово.

В татарском синонимическом словаре даются следующие варианты слова «обещание»: *ант* (клятва, зарок, обет, присяга), *вәгъдә, ямин, гаһет; ант итү* – клясться, давать клятву (обет), клятвенно обещать, присягать, дать присягу; *ант бирү (эчү), сүз бирү; вәгъдә бирү* (итү, кую); *ямин итү; гаһет бирү; вәгъдә бирү* – (обещать, сулить) – *вәгъдә итү; вәгъдә кую; вәгъдәләшү; сүз бирү; ышандыру; вәгъдәләшү*- (помолвка) – *кыз ярәшү; аклашу* (*диал.*) [2: 46].

При поиске примеров мы использовали письменный корпус современного татарского языка. Корпус представляет современный письменный татарский язык в электронной форме. Объем корпуса татарского языка в настоящее время составляет более 500 миллонов слов, число различных словоформ – около 5 миллионов. Это позволило нам найти самый интересные примеры.

Как показывает наши исследования, в татарском художественном дискурсе концепт “вәгъдә” имеет следующие значения:

1) добровольно взяться за какую то работу: *Катяга ул һәр дәрескә бер җыр ятлап килергә сүз бирде һәм вәгъдәсен бик төгәл үтәде. (Г. Әпсәләмов*);

2) обещание: *Вәгъдә булсын...Авылым мине ташламаса, мин аны ташламам! (М.Фәйзи*);

3) заранее договориться о какой либо сделке или о запрете какого-либо дела: *Сажидә белән Ильдарның вәгъдәләре бар икән, Үзләре дә бик пар килгән, уйлары әда пар икән. (М. Җәлил*)

4) заранее согласованный срок: *Туйны хәзер кылмагыз, бер ел да бер көн куеп, шул вәгъдә үткәч кылырсыз. (Әкият*).

Обычно слово “вәгъдә” в контексте используется со следующими словами, например:

1. вәгъдә алу (өйләнешү алдыннан икенче яктан ризалык алу);
2. вәгъдә бирнәсе (башкода килеп сөйләшкәндә, кыз ягыннан, ризалык билгесе итеп, егет ягына бирелә торган бүләк);
3. вәгъдә бирү, вәгъдә кую (берәр нәрсә эшләргә яки эшләмәскә сүз бирү, ант итү; ышандыру);
4. вәгъдә бүләге ( кыз белән егетне өйләндерү турында беренче килешү булгач ике яктан да бирелә торган бүләк);
5. вәгъдә итү, вәгъдә кылу ( берәр нәрсә эшләргә сүз бирү, үз өстенә йөкләмә алу);
6. вәгъдәдә тору (биргән вәгъдәсен үтәү).

Обстановка и место использования этого слова зависит от ситуации и цели собеседника:

- влюбленные дают обещание друг-другу: *Үткән вакыттагы аулак өйләр, кунарга кертүләре, ташлашмаска вәгъдә бирешүләр – барысы да хәтердән уздылар (А. Абдулла “Яңа килен”);*

- перед публикой, гордо крича, рассказывают о светлом будущем и обещают золотые горы, много денег, нормализование положения: *Бер бүлмәле квартира вәгъдә иттеләр, менә паспорт күтәреп баргач, ордер бирәчәкләр (А. Тимергалин. “Игезәкләр”);*

- на вокзале при отправлении возлюбленного на военную службу девушки дают обещание, что дождутся их, несмотря ни на что: *Күпме җиткән кызлар сөйгән егетләрен көтәргә вәгъдә биреп, аларның кайтуын гомер буе көтеп, кыз - әби булып бакыйлыкка күчте (Безнең гәҗит);*

- на рабочем месте работодатели обещают своим подчиненным много денег или выполнения какой-нибудь их просьбы: *Аңлавымча, аның беренче карашка гап-гади бу җайланмасын баш механик белән бергәләп рационализаторлык тәкъдиме итеп рәсмиләштергәннәр, хәтта премия дә вәгъдә иткәннәр (А. Тимергалин “Игезәкләр”*);

- обещают вознаграждение за какое-нибудь «черное» дело либо за находку человека, предмета: *Ул Пугачевның башы өчен 500 сум акча вәгъдә итә, татар-башкорт старшиналарына фетнәчеләрдән талап алынган байлыкны үзләштерергә рөхсәт итә. (В. Имамов “Татар яугирләре: Татарлар Пугачев явында»)* [3, 245–246].

По исполнению обещания бывают:

- пустые обещания – буш вәгъдә: *Күз буу, алдау өчен бирелгән буш вәгъдә, вакытлы бер тозак кына ул. (Р. Мөхәммәдиев “Сират күпере”);*

- ложные обещания – ялган вәгъдә: *Ул Вена янәшәсендәге Гюнс кирмәнен атналар буена яклаган Николай Юрисичны да, ялган вәгъдә белән кул күтәртеп, дарга асып куйды (В. Имамов “Сөләйман солтан”);*

- неоправданные обещания – үтәлмәгән вәгъдә: (*С. Билалова “Үтәлмәгән вәгъдә”);*

- оправданные обещания – үтәлгән вәгъдә: (*Үтәлгән вәгъдә, үстергән гөлләр. "Матбугат.ру" порталы*).

Можем сделать вывод из анализированного материала, что обещание дается разными людьми и с разными целями. Так же можем сказать, что татарский народ ответственно относится к тому, что говорят и стараются выполнять обещанное им слово. В рассмотренных примерах встречались случаи, когда люди не сдерживали своего слова по разным причинам.

**Литература**

1. Частникова С.А. Когнитивные основания речевого акта обещания // Культура народов Причерноморья. – 2007. – № 110, Т. 2. – С. 273–275.

2. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф. С. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 263 с.

3. Махмутова Л.Т., Мөхәммәдиев М.Г. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Татар. кит. нәшр., 1997. 1 том.

4. Письменный корпус современного татарского языка (URL: https://www.corpus.tatar) (дата обращения: 25.01.2020).

## «МӘДӘНИ ҖОМГА» ГАЗЕТАСЫНДА ТЕРКӘЛГӘН КЕШЕ ШӘХЕСЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ АТАМАЛАР

*Сабирова Н., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Ф.Ш. Нуриева*

Хәзерге вакытта мәгълүмат мәйданы искиткеч зур һәм бай. Һәр елны әлеге мәйданда берсеннән берсе яңа газеталар һәм журналлар, электрон мәгълүмат чаралары: аудио, видео язмалар пәйда булып тора.

Матбугат теле, билгеле булганча, әдәби телнең аерым бер кулланылыш шәкелләреннән булган публицистика стиленә карый. Әдәби тел – эшкәртелгән, тел белеме фәне нигезендә нормаларга салынган, нормалашкан тел кулланышы.

Публицистик стиль аралашу һәм тәэсир итү функцияләренә ия булуы белән аерылып тора. Публицистик текстлар халыкка язма яки сөйләмә формадагы мәгълүмат чаралары аша җиткерелә, аларның язма формалары гадәттә мәкалә, очерк, репортаж, фельетон, интервью жанрларында чагылыш таба. Функциональ-стилистик күзлектән чыгып караганда, үзенең күпкырлы максат-бурычларына бәйле рәвештә, публицистик стиль иң катлаулы стильләрдән санала. [Гомуммилли

телнең яшәеш формасы буларак әдәби тел һәм аның функциональ стильләре // Фәнни Татарстан. – 2017. – №2].

Тикшерү күрсәткәнчә публицистикада кеше шәхесе белән бәйле атамалар кешенең яшәү урыны белән, икенче бер кешегә нинди мөнәсәбәттә килүе, нинди диннән яки милләттән һәм башка билгеләре буенча аерылып билгеләнергә мөмкин.

Татар матбугатында кеше эшчәнлеге белән бәйле атамалар аеруча зур урынны алып тора. Бу аларның кешенең дөньядагы тоткан урынын күрсәтү белән бәйле булудан килә. Әлеге эшебезне дә нәкъ менә шушы юнәлештә башкардык. Анализ ясау өчен без “Мәдәни җомга” газетасының 2019 елның декабрь аендагы чыгарылышларына мөрәҗәгать иттек, андагы күпсанлы мәкаләләрдә урын алган лексик берәмлекләргә күзәтү бирелде.

Газета санындагы вакыйгаларны яктыртканда һәр язма артында билгеле бер шәхес тора. Һәрбер журналист теге яки бу вакыйгага бәйле аларга мөрәҗәгать итә. Тикшерүләрдән күренгәнчә, кеше шәхесе белән бәйле атамалардан башка кулланылган бер генә мәкалә дә юк. Беренче урында, кеше атамалары, ягъни кеше исемнәре тора. Мәсәлән: ***Җырчыларыбыз Филүс Каһиров, Рәсим Низамов, Резидә Галимова, Энҗе Шәймурзина*** *моңнар белән күмде* [Остаз әдип бәйрәме // Мәдәни Җомга. – 2019. – 19 декабрь].

Кеше шәхесе атамалары арасында иҗат белән бәйле атамаларның да бик еш кулланулы күзәтелде. Аеруча еш кулланыла торган сүзләр исемлегендә: артист, шәхес, халык язучысы, әдәбият галиме, тамашачы, остаз, әдип җырчы кебек берәмлекләр теркәлгән. Мәсәлән: *Габдулла Шамуков кебек бөек* ***артисттан*** *– даһи* ***шәхестән*** *кайчандыр белем алуым, сәнгать серләренә өйрәнүем, аны сәхнәдә генә түгел, көн дә тормышта күреп аралашуым – зур горурлык булып күңелдә саклана* [Кабатланмас, самими зат // Мәдәни Җомга. – 2019. – 24 декабрь]. Әлеге җөмләдә артист һәм шәхес кебек атамалары Габдулла Шамуковны ачу, аның бөеклегенә ишарә ясау, игътибар юнәлттерү өчен кулланыла. *16 декабрьдә* ***К. Тинчурин*** *исемендәге театр залында Татарстанның* ***халык язучысы, әдәбият галиме Мөхәммәт ага Мәһдиевне****, тууына 90 ел тулу уңаеннан, искә алу кичәсе булды. Залны тутырып килгән һәрбер тамашачы өчен* ***Мөхәммәт ага*** *йә университеттагы кабатланмас лекцияләре, йә үлемсез әсәрләре буенча зур* ***остаз*** *бит, шуңадырмы экранда бөек* ***әдип*** *үзе исән чакта төшкән документаль фильм пәйда булуга ук, ул безне үткән яшьлегебезгә, татар әдәбиятының гүзәл елларына кайтаргандай итте* [Остаз әдип бәйрәме // Мәдәни Җомга. – 2019. – 19 декабрь]. Китерелгән мисалларда күренгәнчә, кеше шөгыле белән белән бәйле атамалар белән беррәттән аларның исемнәре дә атала.

*Бәйгенең башлангычында торган* ***продюсер Рифат Фәттахов*** *яңа җырны булдыру өчен* ***композитор, шагыйрь, продюсер,*** *аранжировщиклар чакырылганын әйтте* [Милләткә яңа җыр, "Яңа татар җыры" кирәк // Мәдәни Җомга. – 2019. – 16 декабрь].

Еш кулланыла торган атамалардан һөнәрчелек терминологиясе белән бәйле сүзләрнең дә актив булуы ачыкланды. Мәсәлән: *Туган авылы Алма-Ата күген иңләп узган самолет тавышын ишетеп үскәч, сугыш чоры баласы Миргазиян Шириазданов* ***очучы*** *булырга хыяллана.*

*Фронтта соңгы сулышын алган әтисен –* ***балта остасы, мебельчы, мичче*** *Закирҗанны күрмичә ятимлектә үскән малай, үз көче белән максатына ирешү өчен, Урал – җидееллык, Кәрәкәшле унъеллык мәктәпләрен тәмамлап, 1962 елда Иркутск хәрби авиация техник училищесына имтихан тапшыра.*

***Шәфкать туташы*** *булып эшләгән хатыным минем аркада Монтаһа тынычлыгын бозды.*

*Анда ул сүзләрне хохол-****прапорщик*** *таккан икән* [Җир әйләнгән очучы // Мәдәни Җомга. – 2019. – 18 декабрь].

Тикшерү өчен алынган материал чикле булганлыктан барлык һөнәргә бәйле атамалар күрсәтелмәде. Теркәлгән мисаллардан күренгәнчә һөнәр атамалары сүз ясагыч чы/че кушымчалары белән ясалган: *очучы*. Кушма сүзләрдән икенче төр изафә, ягъни исем+исем, өченче зат тартым моделендә ясалган атамалар еш теркәлгән: *балта остасы, шәфкать туташы.*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, “Мәдәни Җомга” газетасында 2019 елның ахырында чыккан саннарында кеше шәхесе белән бәйле атамаларны күзәтүебез кызыклы нәтиҗәләр бирде. Һәр мәкаләдә кеше белән бәйле атама, профессия исемнәре һәм бигрәк тә мәдәният белән бәйле шәхес атамаларының актив булуы күренде.

**Әдәбият**

1. Гафарова В.Р. Текстка грамматик анализ ясау. – Казан, 2016. – 85 б.
2. Миңнуллин Б.К. Гомуммилли телнең яшәеш формасы буларак әдәби тел һәм аның функциональ стильләре. – Фәнни Татарстан, 2017. – 31 б.
3. Низамов И.М. Уем – тел очында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 287 б.
4. Хәмзә Бәдретдинов. Җир әйләнгән очучы // Мәдәни Җомга. – 2019. – № 51. – Б. 3

## Ә. ЕНИКИНЕҢ «МАТУРЛЫК» ХИКӘЯСЕНДӘГЕ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫ ТӨРЕК ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

(Фатыйх Котлының «Güzellik» тәрҗемәсе нигезендә)

*Сабитова Л., Бөгелмә р-ны М. Өнҗәл ис. лицей-интернат, XI сыйныф*

*Җит. – Д.И. Доган*

Әмирхан Еникинең «Матурлык» хикәясе күпсанлы укучыларның иң яраткан әсәренә әверелде. Кешенең күңел байлыгына дан җырлаган, ана

һәм бала арасында булган саф хисләрне зур осталык белән җиткәрә алган бөек әдибебез. Әмирхан Еникинең иҗаты чит ил халыкларын да кызыксындыра. Төп сәбәбе: иҗатында һәркемнең күңеленә якын булган хәлләр, мәңгелек темаларның оста сурәтләнүе. Нәкъ бу үзенчәлек төрек тәрҗемәчесе Фатыйх Котлының (Татарстан язучылар берлегенә кабул ителгән беренче төрек теле тәрҗемәчесе, филология фәннәре кандидаты) игътибарын җәлеп иткәндер дип уйлыйм. Бу әсәр 2005 елда Төркиядә "Васыять" дигән җыентыкта басылып чыкты.

Әмирхан Еникинең иҗаты сурәтләү чараларына бай, теле халыкчан. Әдип фразеологизмнардан да бик оста файлана. Без Әмирхан Еникенең «Матурлык» әсәрендә кулланылган фразеологизмнарның төрек теленә тәрҗемәсендә үзенчәлекләрен ачыклауны үзебезгә максат итеп куйдык.

Телдәге төшенчәләр бер сүз белән генә түгел, ә үзгәртелми, таркалмый торган тотрыклы сүзтезмәләр белән дә белдереләләр. Алар телнең үз байлыгы нигезендә барлыкка киләләр. Фразеологизмнарны телнең җәүһәрләре дип йөртәләр. Алар телнең милли калоритын, үзенчәлеген билгелиләр. Фразеологик берәмлекләр сөйләмне образлы, бизәкле, тәэсирле итә, шуңа күрә тел осталары аларны матур әдәбиятта яратып һәм мул кулланалар.Фразеологизмны тәрҗемә итү зур осталык һәм чыганак телне яхшы белүне таләп итә. Тәрҗемәнең төп принциплары барлык телләр, тәрҗемә ителә торган барлык материал өчен уртак. Иң мөһиме: сүзнең эчтәлеген мөмкин кадәр тулырак саклау.

В.В. Виноградов лексик фразеологизмнарны тәрҗемә итүнең өч төрле юлын күрсәтә:

1. Фразеологик эквивалент–икенче телдә шундый ук фразеологик әйтелмәне табу. Биредә оригиналдагы кебек шул ук мәгънә, стильара билгеләр үзгәрми һәм эчке форма төгәллеге саклана.

2. Тулы булмаган фразеологик эквивалент – һәрбер мәгънәдә дә тулы булмаган фразеологизм белән тәрҗемә итү. Ягъни телдә икенче мәгънәсе булу шарт булып тора, ләкин бу юл телдә сирәк күренеш булып тора.

3. Бер сүздән торган өлешчә эквивалент.

Татар һәм төрек телләре–тугандаш телләр, аларның охшаш һәм аермалы яклары бар. Без әсәрне уку дәвамында фразеологизнарны таптык, төрек телендә тәрҗемәләре белән чагыштырдык, эквивалентларның төрләрен билгеләдек.

**1.** Кешегә йөк булу–yьk olmak (фразеологизм: быть в тя́гость, быть обу́зой) – фразеологик эквивалент. Бәдретдин **кешегә** бер дә **йөк булырга** ятмый иде. Bedretdin insanlara **yük olmayı** hiѕ sevmezdi.

2. Үзеңнән өзү–yediğinden arttırmak (фразеологизм: лишать себя чего-либо)–тулы булмаган фразеологик эквивалент. Әнкәйгә әйтегез, мин

ач түгел **үзеннән өзеп** җибәрмәсен. Anneme söyleyin; ben aç değilim, **yediğinden arttırıp** bana göndermesin!

3. Туң күчән–cahil bile olsa (тәрҗемәсе: даже если будет глупцом). Бай шәкерт, әйтик, **туң күчән** булса да, мәдрәсәдә күпме ята ала, ә ярлы шәкерт, начар укыдымы, беренче кыштан ук мәдрәсәдән очарга мәҗбүр була. Zengin єakirt **cahil bile olsa** medresede istediği kadar kalabilir fakat fakir şakirt kötü okudu mu, ilk kışta medreseden uçmaya mecbur olur.

4. Зар елау–ağlamaklı sızlakmaklı (тәрҗемәсе: жалобный) тулы булмаган фразеологик эквивалент. Инде укый калса, аның әйберсе башкаларныкы төсле **зар еламыйча** гына язылган, ... Yazdığı şeyler diğerlerindeki gibi **ağlamaklı sızlamaklı** değildi/

5. Тел бармау–dilim varmıyor (фразеологизм: язык не поварачивается) фразеологик эквивалент. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер **тел бармый**, ...Bu durumu tasvir etmeye **dilim varmıyor**;

6. Кул тимәү – el değmemek (фразеологизм:руки не доходят) фразеологик эквивалент. Ул айлар буе **кул тимичә** якан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде. Bedretdin aylardır **el değmemiş** kemanı uzun süre uğraştıtan sonar akort edebildi.

7. Бәгырьгә төшү – derin bir sevgiyle (тәрҗемәсе:с сильной любовью). Ана үзенең шәкерт улына шундый бер **бәгырьгә төшәрлек т**ирән мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөккибән китеп карап утыра иде ки, Annesi oğluna öylesine yürekten, **derin bir sevgiyle** bakıyordu ki mutluluktan büyülenmiş, kendinden geçmişti.

8. Сөлек кебек егет – babayiğit delikanlı (фразеологизм: мужественный па́рень, юне́ц, ю́ноша.) Тулы булмаган фразеологик эквивалент. Ул **шушы сөлек кебек егетнең** әнисе бит! Bцyle bir **babayiğit delikanlının** annesiydi o.

Димәк, без шундый нәтиҗәгә килә алабыз: тәрҗемәче фразеологик эквивалентларны, тулы булмаган фразеологик эквивалентларны һәм тәрҗемәләрне кулланды. Шулай ук әсәрдә мәкаль очрый: «Илдә чыпчык үлми» мәкале тулысынча тәрҗемә ителеп бирелгән «Ülkedeki serçe ölmez». Бу алым әсәрне тагын да бизи, укучыларны милли фикерләү үзенчәлекләре белән таныштыра. Безнең фикеребезчә,төрле халыкларның әдәби мирасын тәрҗемә итү – халыклар дуслыгына күпер салу дигән сүз. Халыкның тарихи, мәдәни, әдәби мирасын, халыкның күңелен аңларга ярдәм итә.

**Әдәбият**

1 . Еники Ә. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер (ТаРИХ), 2002. – 416 б.

2. Сафиуллина Ф.С. Татарско-русский фразеологический словарь. – Казан: Магариф, 2001. – 335 с.

## ХАЛЫҚ АУЫЗ ӘДЕБИЕТІНІҢ ӘЛЕУМЕТТІК МАҢЫЗЫ

*Сағызбаева А., Ғалымжанова А., Батыс Қазақстан инновациялық-технологиялық университетінің I курс студенттері*

*Ғыл. жет. – филол. ғыл. магистрі С.А. Бекетаева*

Фольклор – қазіргі тілмен айтқанда «әмбебап», яғни синкретикалық өнер түрі. Онда өнердің әр түрі – сөз, музыка, хореография және театр өнері шоғырланған. Қазақ халқының мұндай сөз өнерін ғалымдар ауыз әдебиеті деп атаған. Сонымен бірге ғылым мен мәдениетте "халық шығармашылығы", "халық поэзиясы", "халықтың ауызша сөз өнері" дейтін атаулар да осыған жақын мағынада қолданылады [1: 4]. 1846 жылы ағылшын Вильям Томс ұсынған "фольклор" (ағылшынша фолк – халық, лоре – білім, даналық) сөзі де ауыз әдебиеті атауы үшін халықаралық ғылым атау ретінде орныққан [2: 10]. Бұлардың қай-қайсысы да бірінің орнына бірі қолданыла береді.

Халық жыраулары, жыршылары, ертекшілері осы сонау ықылым заманнан рухани асыл қазына ретінде сақтап, ұрпақтан-ұрпаққа мұра етіп, бүгінгі біздің дәуірімізге жеткізген. Адамзат өзінің сонау балаң кезінде, табиғаттың жұмбақ, тұңғиық сырына ойы жете алмаған кезінде сол табиғаттың сиқырлы алуан жұмбағын шешсем, оны өз игілігіме жаратсам, бағындырсам деген арманын өзінің ауыз әдебиетімен бейнелеген. Адамның табиғаттың дүлей, мылқау күшімен арпалысы да сол ауыз әдебиетінде өрнектелген. Қоғамдық, әлеуметтік, экономикалық өмірдің ілгерілеуіне, адамның ой-санасының өсуіне, өзін қоршаған табиғаттың сырына терең болауына байланысты ауыз әдебиеті де мазмұны, формасы жағынан байып, дамып отырған. Қазақ халқының ауыз әдебиетінің сонау көне дәуірден келе жатқан рухани мұра екені «Құламерген», «Ер Төстік» ертегілерінен айқын танылады. Әлеуметтік жікке бөлінген қоғамдық өмірдегі қайшылықтар, байлар мен соған тәуелділер, кедей-кепшіктер арасындағы күрес, тартыс ауыз әдебиетінің мұнан былайғы даму өрісінде кең қамтылған. Халық ауыз әдебиетінің өлең-жыр, ертегі, мақал мәтелдері, лиро-эпостық жырларында қарапайым адамдардың, еңбек адамдарының жасампаз күшіне, ақыл-парасатпен сенген, соларды мадақтаған. Сондықтан, ауыз әдебиетіндегі бұқара өкілдері тек жақсы жағынан ғана суреттеледі, олар тамаша қасиеттері арқылы оқушыны өзіне еліктіре біледі.

Халық ауыз әдебиеті әр салада, әр түрлі жанрда дамыған. Тұрмыс-салт жырларынан бастап, эпостық жырларға дейінгі бай мұра халық ауыз әдебиетінің жанрлы өрісін танытады. Халық ауыз әдебиеті халықпен тығыз қарым-қатынаста. Себебі, ауыз әдебиеті ауыздан ауызға тарап ұрпаққа жетіп отырған. Жалпы, халық ауыз әдебиетіне мақал-мәтел, жұмбақ, айтыс, өтірік өлең, ертегілер, аңыз әңгімелер және жырлар жатады. Бұлардың барлығы қазақ халқының әлеуетінен және тұрмыс-тіршілігінен пайда

болған. Негізгі мазмұны тіл, дін, салт-дәстүр,халықтың мұң-мұқтажы туралы болған. Тек қана аңыз әңгімелер емес жырларда ауыз әдебиетінің құрамына кіреді. Мысалы, ел басына күн туғанда қолына қару алып,атқа мініп ел үшін, жер үшін соғысқан батырларды дәріптеу мақсатында жырлар жазылды. Қобыланды батыр, Алпамыс батыр, Ер Тарғын жырлары сөздеріміздің дәлелі [3: 6]. Одан басқа лиро-эпостық жырларда жазылған. Олар: Қозы Көрпеш-Баян сұлу, Қыз Жібек, Айман-Шолпан, Еңлік-Кебек жырларында сол уақыттағы әлеуметтік жағдайды, ер мен әйел арасындағы теңсіздікті, салт-дәстүрді жырлаған.

Қорыта келе, халық ауыз әдебиеті халықтың негізгі тірегі. Қазіргі кезде де тәуелсіздік жылдарында қазақтың рухани көре мұрамы зерттеліп келеді. Зерттеуге зор үлес қосып жүрген Алматыдағы Әдебиет және өнер институтының және фольклортанушы ғалымдарымыздың ықпалы мол. Халықтың ең асыл бай өнері - халық ауыз әдебиеті арқылы өзінің тарихын, әдебиетін, мәдениетін, халықтың рухын бейнелеген.

**Әдебиет**


1. Жұмалиев Қ. Әдебиет теориясы. – Алматы: «Мектеп» баспасы, 1969. – 142 б.
2. Омаров І. Әдебиет жайлы ойлар. – Алматы, 1961. – 100 б.
3. Мақпыров С. Әдебиеттануға кіріспе. – Алматы, 1991. – 266 б.


# МОРФОЛОГИЧЕСКИЕ И СИНТАКСИЧЕСКИЕ ХАРАКТЕРИСТИКИ ТЕКСТА КУЛИНАРНОГО РЕЦЕПТА

(на материале поваренной книги Е. Молоховец)


*Саетгараева Л., КФУ, магистрант II курса*

*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. Г.Х. Гилазетдинова*


Кулинарный рецепт – это особый тип текста. Его языковой строй складывался на протяжении нескольких столетий. Кулинарный рецепт как тип текста характеризуется адресностью, наличием социальных отношений, безэмоциональностью, строгостью и формальностью языка, четкой структурой, сложностью процедуры приготовления блюда [2: 79].

Объектом данного исследования выступает сборник кулинарных рецептов второй половины XIX века – «Подарок молодым хозяйкам или средство к уменьшению расходов в домашнем хозяйстве» Елены Ивановны Молоховец. Данная книга является наипопулярнейшей среди поваренных книг в российской истории и не утратила своей значимости до сих пор: она многократно переиздается, на просторах Интернета обсуждаются ее рецепты, к тому же, существует заведение, где блюда готовятся по поваренной книге Е.И. Молоховец.

Для кулинарного рецепта свойственен предписательный, инструктивный характер, он представляет собой алгоритм действий, конечной целью которого является достижение результата – приготовление блюда.

Отметим, что в рецептах «Подарка…» обязательными структурными компонентами являются: заголовок, способ приготовления блюда, список ингредиентов.

При цитировании сохранилась стилистика текста, однако некоторые буквы заменены на современный вариант: «ѣ» заменено на «е», «і» заменено на «и».

Заголовок – обязательная часть кулинарного рецепта. Именно он в концентрированном виде передает содержание текста основной части. Заголовки рецептов в поваренной книге Е.И. Молоховец зачастую представляют собой словосочетание следующих типов связи: согласование (1) Бульон чистый, 110) Оливки фаршированныя, 345) Язык бычачий), управление (168) Соус из шампиньонов, 214) Морковь с горохом, 441) Цыплята под соусом с крыжовником) и примыкание (706) Блины по-английски). В некоторых заголовках можно встретить словосочетания с несколькими типами связи, например, 303) Говядина разварная с итальянскими макаронами (согласование и управление), 543) Соус из раков иначе (управление и примыкание), 1032) Мазурек очень вкусный (согласование и примыкание), 1403) Лук сохранять на зиму (управление и примыкание) и т.п. Наблюдаются однословные заголовки: 118) Вермишель, 211) Клярь, 257) Артишоки; а также заголовки, по форме схожие с вопросительным предложением: 1433) Как сохранять огурцы свежими до глубокой осени, 1439) Как заготовлять свекольник на зиму. Здесь широко употребление получило имя существительное, так как информативный характер заголовка требует номинации предмета.

Следующий по структуре рецепта пункт – способ приготовления блюда. Здесь отметим широкое употребление сложных и осложненных простых предложений, т.е. это простые предложения с однородными членами и сложноподчиненные предложения с придаточными времени, условия, образа действия, цели и пр. К тому же, для синтаксиса текста кулинарных рецептов Елены Молоховец характерно осложнение деепричастиями и деепричастными оборотами. Рассмотрим следующий пример из рецепта 314) Говядина жареная по-французски:

Кусок мягкой говядины выбить хорошенько, посолить, посыпать перцом. – Свернуть в трубку, а потом в бумагу, обвязать, жарить на вертеле или противне, поливая маслом, смотреть, чтобы не пережарить и чтобы сок не вышел из говядины. Положить на блюдо, разрезать, оганировать жареным картофелем [3: 152].

Первое и третье предложения рецепта представляют собой простое предложение с однородными сказуемыми, выраженными инфинитивами совершенного вида. Второе предложение является сложным с однородным видом подчинения придаточных предложений цели. Главное предложение осложнено однородными обстоятельствами и деепричастным оборотом.

Форма предиката в рецептах поваренной книги представляется инфинитивами. Именно благодаря глаголам, описывающим алгоритм и способ действий, достигается результат – приготовление блюда. Вследствие употребления начальной формы глагола как основной лексемы для инструктирования предложение приобретает побудительный оттенок.

Реализуя страннический мотив в своей прозе, автор реабилитирует национальный дискурс, определяя в нем место «писателя-личности» как центральное, более того, наделяя фигуру писателя аскетическими и мессианскими качествами.

**Әдәбият**


1. Галиуллин Т.Н. Яктылык: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 319 б.
2. Ганиева Р. К. Шагыйрьнең рухи дөньясы. – Казан, 2002. – 7 б.
3. Гачев Г.Д. Национальные образы мира. Евразия – комос кочевника, земледельца и горца. – М.: Институт ДИДИК, 1999. – 368 с.
4. Загидуллина Д.Ф. Современная татарская проза. – Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. – 246 с.
5. Йосыпова Н.М. XX гасыр татар шигъриятендә символлар. – Казан: Казан университеты, 2011. – 120 б.
6. Папилова Е.В. Имагология как гуманитарная дисциплина // Электронный ресурс. Режим доступа: https://cyberleninka.ru/article/n/imagologiya-kak-gumanitarnaya-distsiplina 23.02.2019 (дата обращения: 24.02.2019).
7. Тимофеев М.Ю. Нациосфера: Опыт анализа семиосферы наций. – Иваново: Иван. гос. ун-т, 2005. – 279 с.
8. Фаленкова Е.В. Феномен странничества в русской культуре // http://www.dissercat.com/content/fenomen-strannichestva-v-russkoi-kulture#ixzz5gMoAd3Th (дата обращения: 28.02.2019).
9. Юныс М.З. Дөнья гизү: трилогия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 576 б.
10. Юныс М.З. Кыпчак кызы: проза, публицистика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 479 б.


## КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ ГАСТРОНОМИК ТУРИЗМ ПОТЕНЦИАЛЫ


*Фазылҗанова Г., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит.– филол. фән. канд., доц. Р.С. Нурмөхәммәтова*


Хәзерге җәмгыятьтә көндәлек туклану өлкәсенә кызыксыну арту күзәтелә. Ризык темасы массакүләм мәдәниятнең барлык өлкәләренә дә диярлек үтеп керә: кулинар тематикага караган күпсанлы китаплар һәм вакытлы басмалар чыгарыла; кулинария сәнгате күргәзмәләре һәм конкурслары уза; җәмәгать туклануы системасы актив үсә; телевидениедә ризык әзерләү нечкәлекләренә багышланган программалар барлыкка килә һ.б.

Бүгенге туризмның да популяр төрләреннән берсе – кулинария туризмы, аның максаты – төрле халыкларның аш-су үзенчәлекләре белән танышу. Шул ук вакытта ризыкны әзерләү генә түгел, ә аны куллану процессы да кызыксыну уята. Болар барысы хәзерге заман кешесенең көндәлек тормышының мөһим бер өлешенә әверелә. Бүгенге көндә бу мәсьәләләр культурологик белем күзлегеннән караганда актуаль булып санала һәм теоретик өйрәнүне таләп итә [2].

Ашау – кешенең биологик ихтыяҗын канәгатьләндерү чарасы гына түгел, ә мәдәният феномены да. Кешенең тәрбиясе, цивилизацияле булуы, мөгаен, аның үз ихтыяҗларын ничек канәгатьләндерүендә аеруча тулы чагыладыр. Кешенең иң алга киткән табигый ихтыяҗларыннан берсе – азыкка ихтыяҗ. Ризык кабул итү – кешеләрнең үз-үзләрен тотышының социаль-мәдәни формалары (йолалар, ритуаллар, тантаналар һ.б.) белән бәйле процедура [1: 167]. Ул кеше тормышының төрле вакыйгаларын – шатлыклы, бәйрәм (туй өстәлләре, туган көннәр һ.б.), кайгылы, фаҗигале (искә алу йолалары һ.б.) вакыйгаларының аерылгысыз бер өлеше. Бер табын артына утырып ризык кабул итү – ул ачлыкны канәгатьләндерү генә түгел, кешеләрнең аралашуы да, ә ризык бу очракта аерым бер символик билге булып та тора.

Хәзерге көндә кулинар сәяхәтләр белән кызыксыну артканнан арта бара. Мавыктыргыч кулинария маршрутлары оештырылган илләр саны елдан-ел үсә [3]. Гастрономик турлар белән кызыксыну кешеләрнең гадәти туризмнан туюы белән генә аңлатылмый. Кешеләр бу ял төренә үзенчәлекле ризыктан авыз итәсе килү сәбәпле өстенлек бирә.

Россиядә, һәм гомумән дөньяда, гастрономия туризмы күптән түгел генә үсеш ала. Күпмилләтле, бай тарихы булган Россиядә гастрономик туризмны үстерүнең зур потенциалы бар [5]. Әлеге рәттә Татарстан Республикасы, Әстерхан өлкәсе, Алтай, Алтын боҗра районнары, Төньяк Русия, Кавказ районнары, шулай ук Себернең һәм Ерак Көнчыгышның гаҗәеп милли-мәдәни һәм табигый матур урыннары аерым урын алып тора.

Туризм төбәкнең икътисадын үстерүдә мөһим роль уйный, шулай ук транспорт, төзелеш, элемтә, авыл хуҗалыгы, көндәлек куллану товарларын җитештерү белән бәйле тармакларны үстерүгә этәргеч бирә.

Татарстан Республикасы территориясендә милли кухня тәкъдим итүче кафе һәм рестораннар бик аз очрый, алар нигездә Казан, Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләре чикләрендә тупланган [4].

Казан шәһәренең милли кухнясы картасына күз салсак, шуны әйтергә була: милли ризыклар һәм татар мәдәниятен тәкъдим иткән кафе һәм рестораннар алай ук күп түгел һәм алар, нигездә, шәһәрнең

Вахитов районында тупланган. Мондый географик урнашу бер яктан караганда туристлар өчен уңайлы дип табыла, чөнки барлык аш-су йортлары да бер тирәдә урнашкан. Әмма Казанның башка районнарында тукталган туристларга берникадәр кыенлыклар тудырырга мөмкин. Шулай ук күпчелек рестораннарда милли ризыкларның төрлелеге аз булуын, интерьерның һәм хезмәт күрсәтүче персоналның милли колорит стандартларына туры килмәвен билгеләп үтәргә мөмкин. Рестораннарда төп милли ризыклар исемлеге 29% күләмендә тәкъдим ителгән, кафеларда бу сан нибары 12%.

Хәзерге вакытта, дәүләттән тыш, гастрономия туризмын актив үстерүгә бизнесның барлык формалары кызыксындыру белдерә. Эре бизнесның төп игътибары кунакханә бизнесын, мәдәни-күңел ачу үзәкләрен үстерүгә бирелә. Урта һәм кече бизнес, нигездә, сувенир кибетләр һәм рестораннар үсешенә, шулай ук милли-мәдәни чаралар уздыруга игътибарын юнәлтә, аны оештыруда дәүләт һәм эре бизнес ярдәм күрсәтә [1: 56-58]. Татарстан Республикасында, аерым алганда Казан шәһәрендә, милли-мәдәни чаралар шактый күп һәм еш үткәрелә, алар, тулаем алганда, гастрономия туризмын да үстерүгә бик зур этәргеч ясыйлар.

Татарстан Республикасы һәм Казан шәһәренең кулинар гореф-гадәтләре кызыклы. Монда гастрономия туризмы республика халкының мәдәниятен чагылдырган күп кенә юнәлешләре тәкъдим ителгән.

Соңгы елларда гастрономия туризмын барлыкка китерү һәм үстерүгә күп факторлар йогынты ясый [3]. Гастрономия туризмын «зәвык белән сәяхәт» дип атыйлар, ә яхшы зәвыклы сәяхәтче, һичшиксез, Татарстан Республикасын сайлаячак. Татарстан Республикасында гастрономия туризмын үстерү – төбәк икътисадына тагын бер өстәмә, ул эш урыннарын, керемне һәм мәдәният объектларын үстерүне стимуллаштырудан тыш, Россиядә һәм дөньяда билгеле бер уңай образ тудырырга сәләтле.

**Әдәбият**

1. Андерсон Б. Воображаемые сообщества. Размышления об истоках и распространении национализма. – М.: КАНОН-пресс-Ц, Кучково поле, 2001. – 288 с.

2. Арутюнов С.А. Основные пищевые модели и их локальные варианты у народов России // Традиционная пища как выражение этнического самосознания. – М., 2001. – 264 с.

3. Гастрономический туризм. Туризм и путешествия как отдых. URL: http://tyrrizm.ru (дата обращения: 10.01.2020).

4. Карабаева А.З., Лукьянченко А.Д. Исторические этапы развития мировой гастрономии / Географические науки и образование: мат. VI Всеросс. науч.-практич. конф. – Астрахань: Астраханский университет, 2013. – С. 103–107.

5. Мударисов Р.Г. Организация безопасного пребывания туристов на территории Республики Татарстан с помощью универсального «Туристического атласа Республики Татарстан» // Вестник Национальной академии туризма. – 2013. – № 4 (28). – С. 25–27.

## ПСИХОЛОГИК АЛЫМ БУЛАРАК ТАВЫШ
(Шәриф Камалның «Курай тавышы» хикәясе мисалында)

*Фатыйхова И., КФУның Алабуга институты, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Ф.И. Габидуллина*

Шәриф Камал әсәрләрен психологик алымнар белән бизәгән, тулыландырган. Алар исә, үз чиратында, укучының күңелендә тирән эмоциональ фикерләр уяталар, тормышның теге яисә бу вакыйгасын башка күзлектән чыгып күзалларга этәрәләр.

Ш. Камалның «Курай тавышы» хикәясендә курай моңы ятим балага эти-әнисе үлеме булып ишетелә. Әсәрнең беренче абзацында ук баланың курку хисләре тасвирлана. Курай тавышы аның иң якын кешеләрен якты дөньядан алып китүче бер образ буларак күз алдына килеп баса: «Мин ата-анамны белмим. Аларны бик шәп киенгән сурәттә фараз кыла идем. Гүя алар бик шәфкатьле, бик матурлар... Тик икесе дә хәлсезләр... Әллә нинди, караңгылы-яктылы бүлмәдә бик әкрен, бик көчкә генә сөйләшәләр, сүзләре аңлашылмый... Морҗада җил сызгырып тора, һәм куркынычлы, һәм моңлы курай уйнаган тавыш ишетелә... Яисә алар әллә кайда кырда, бер-берләреннән ерак яталар. Тагын ук хәлсезләр... Өсләренә нечкә чаршаулар ябылган, күтәрелеп, өрелеп торалар... Чаршауларны җил селкетә, җил сызгыра... Караңгы... Курай тавышы ишетелә, кем уйнаганы күренми... Үлем миңа шулай тоела иде» [2: 56]. Беренче карашка бу абзац баланың ата-атасыннан аерылырга теләмәү уйларының монолог рәвешендәге бирелеше. Икенче карашка исә автор баланың эчке хис-кичерешләрен чагылдыру өчен күпнокталардан оста файдалана. Өченчедән, кеше психологиясен ачуда Ш. Камал курай моңын бик үтемле куллана. Нәкъ менә шушы алымнар бергәлеге укучы күңелендә реаль хисләр уянуга этәргеч бирә.

Әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр тавышлар билгеле бер чылбыр рәвешендә биреләләр. Беренче абзацта сүз курай тавышы турында барса, әсәрнең киләсе өлешендә сүз ятим баланың җиңгәсе тавышы турында бара. Аның тыныч, ипле, аһәңле тавышы егеткә уңай таэсир итә: «Мин аны сөядер идем; күзләремне көчкә булса да ачып, тизрәк торырга тырыша идем» [2: 58]. Йокысы туймаса да, иртән уянуы авыр булса да – бала тырыша. Җиңгәсенең ачуланмыйча гына "тор, балакаем, тор" сүзләренә бала үзе дә сизмәстән тиз арада ятагыннан тора. Бу очракта психологик алым булган тавышның кешегә нинди тон белән әйтелүеннән чыгып нинди нәтиҗәләргә ирешеп булуы ачыклана.

«Берсенең камыты бик нечкә ыңгырашкан төсле тавыш бирә, шыгырдый... » – дип, автор камыт образын эшкә җигә [2: 58]. Ш. Камал, үз чиратында, бик отышлы сәнгатьчә деталь куллана. Камыт – элек-электән татар халкында җигү өчен кулланыла торган ат җиһазы. Бу очракта автор

символдан файдалана. Символ – ассоциатив сыйфатларны берләштерүче образ[1: 89]. Камыт – тырышлык, хезмәт сөючәнлекне чагылдыра.

Автор эш тавышларын да атап китә. Бу тавышлар баланың ачуын да китерми, күңеленә дә тими, чөнки болар ризык табырга мөмкинлек бирәләр. Баһадирдай ир-егетләрнең җир эшкәртүләре, ат кешнәүләре – болар барысы да балада хезмәткә карата мәхәббәт хисләре уята, баланың күңелен иркәли, аның өмет тулы күзләренә ышаныч сала һәм яшәргә көч бирә! Әлеге моментта аның күңел ачу, урамда балалар белән уйнау теләге юкка чыга, чөнки ул тормышка икенче күзлектән, зурлар күзлегеннән карарга өйрәнә. Каргаларның ачы, ямьсез тавышы да балада курку хисләре уята. Агаеның аңа карата яхшы мөгәмәләдә булмавына карамастан, ул аның исәнлеге өчен борчыла, аның тормышы өчен үзендә дә җаваплылык хисләре тоя. Ала каргаларның сөйкемсез ачы тавышлары балада гына түгел, атларда да сискәнү, курку тудыралар. Ә «төрле сандугачлар, Гөлниса белән Фатыйманың мин кырдан кайткач ашыгып-ашыгып хәбәр сөйләгәннәре кебек, әллә ничәсе бердән сайрый, иң нечкә кылдан алып төрле көй, төрле тавыштан гаҗәепле бер матур гөрелте чыга: әллә кайларда чылтырап аккан елга тавышлары, әллә нинди хатын-кызның бик нечкә, бик матур каһкаһәләре, бишек тирбәткән көйләр, әллә кайлардан ишетелгән көтүче кычкырыклары, күктә уйналган әллә нинди шатлык көйләре, курай тавышлары, чиксез-кырыйсыз матурлык, сафлык, югарылык көйләре... » кебек юллар хыял белән хакыйкать бәрелеше итеп аңлашыла [2: 59]. Әйтерсең, шушы матур мизгелдә, матур һәм тәмле хыял-өметләр бергә җыелган чакта соңгы нәтиҗә ясалып, хикәя уңай ягы белән тәмамланыр кебек. Ләкин хыял белән чынбарлык чәлпәрәмә килә, алар урынын күңелне сыкраткыч кичерешләр тулыландыра. Баланың күңелендә әсәр ахырында яңадан курку пәйдә була. Янәдән курай тавышы аның нәни, саф йөрәгенә урын бирми, аны соңгы бушлыгына кадәр тутыра.

Шәриф Камал, үткен, актуаль, тирән эчтәлекле идеяләрен мәгънәле сүз гыйбарәләр белән үреп, иҗтимагый фикергә, иҗат үсешенә нык тәэсир иткән язучы. Танылган тәнкыйть осталары Ш. Камал иҗаты белән кызыксыналар, аңа югары бәя бирәләр һәм аның психологик алымнарны кеше хис-кичерешләрен ачуда бик оста файдалануын ассызыклыйлар. А. Әхмәдуллин әдипнең кеше психологиясен оста сурәтләвенә игътибар итә: «Ш. Камал кеше рухының нечкә күчешләрен, психологик кичерешләрне оста сурәтли. Кешенең үкенү, соклану, явызлану, аптырау, шатлану, кайгыру, үрсәләнү, елау моментларын төгәл гәүдәләндерерлек ситуацияләр таба, шуңа кулай җөмләләр һәм сүзләр, сурәтләүләр куллана». Тәнкыйтьченең бу фикере «Курай тавышы» әсәрендә психологик алым булган тавышка туры килә. Кайсы төр тавышны гына алып карасак та,

ятим баланың хис-кичерешләре тулы яссылыкта ачыла, укучы аны борчыган мәсьәләләрне аңлый һәм үз чиратында бала өчен кайгыра да.

Шәриф Камалның хикәяләренә музыкальлек хас. Музыкаль аһәң аның кыска хикәяләрен тулыландыра, әсәр эчтәлеге белән бергә үрелеп бара һәм бу алым аның һәрбер әсәренең югары дәрәҗәдә эшләнгән булуын исбатлый, аңа көчле эмоциональ тон өсти. “Курай тавышы” хикәясендәге һәрбер тавыш баланың билгеле бер хис-кичерешен җиткерә, нинди дә булса вакыйгага яисә кешегә карата фикерен чагылдыра. Ш. Камалның кыска гына хикәяләре дә укучыда күпме кызыксыну уятырга сәләтле!

**Әдәбият**


1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Камал Ш. Бәхет эзләгәндә: хикәяләр, повесть. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1989. – 160 б.


## БҮГЕНГЕ КӨН ТАТАР ЯШЬЛӘРЕНЕҢ РУХИ-ӘХЛАКЫЙ КЫЙММӘТЛӘРЕ
(ассоциатив экспериментлар материалында)


*Фәсхетдинова А., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Э.А. Исламова*


Бүгенге көндә лингвистикада актуаль юнәлешләрнең берсе булып кешенең тел аңын өйрәнү санала. Тел аңын тикшерү методлары арасында ассоциатив эксперимент тора. Әлеге эксперимент информантларның билгеле бер стимулга ассоциацияләр, ягъни реакцияләр бирүдән гыйбарәт.

Фәнни эшнең төп максаты – хәзерге татар яшьләренең ассоциатив экспериментлар материалында кыйммәтле өстенлекләрен өйрәнү.

Татар тел гыйлемендә Р. Р. Җамалетдинов, Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәммәтова, З.А. Мотыйгуллина, Р.Р. Данилова, А.Ш. Васильева, Р.Р. Закирова, Ф.Р. Сибгаева, Ф.Х. Габдрахманова кебек күренекле галимнәр тарафыннан рухи дөнья концепцияләре, кыйммәтле өстенлекләр темасына багышланган хезмәтләр башкарылган.

Әхлакый кыйммәтләр астында кешеләргә аеруча кыйммәт һәм тормыш өчен кирәк булган бөтен нәрсәне күз алдында тоталар. Асылда, әхлакый кыйммәтләр ул – караш, хисләр, мәнфәгатьләр, идеяләр, фикер һәм күренешләр.

Фәнни әдәбиятта информантлар реакцияләренең төрле классификацияләре карала. Ч. Осгуд классификациясе буенча без информантларның реакцияләрен 7 төркемгә берләштердек: 1) фонетик: экология – биология; 2) сүз ясый торган: сәләт – сәләтле, рухлану – рух, илһам – илһамлану; 3) парадигматик: эти – әни, җәннәт – җәһәннәм, рухлану – иһамлану; 4) синтагматик: эти – көчле, әни – назлы, дога – изге; 5) тематик: спорт – баскетбол, туй – никах, ислам – дин; 6) өземтәле: әсәр – «Тапшырылмаган хатлар»; 7) грамматик: туй – туйлар.

Анкета ярдәмендә яшьләр өчен мөһим булган «гаилә», «сәламәтлек», «дин», «сәнгать» һәм «әйләнә-тирә мохит» кебек

кыйммәтләр билгеләнде. Аннан соң һәр кыйммәткә тематик сүзләр төркеме сайланды. Алар Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының 2, 3, 4 курс студентлары белән үткәрелгән ассоциатив эксперимент анкеталарына кертелделәр.

Ассоциатив эксперимент нәтиҗәләре күрсәткәнчә, безнең студентларның танып белүләрендә **гаилә** буларак әхлакый кыйммәт иң беренче чиратта **нәсел, киләчәк, шәҗәрә, туганнар, дәвамчы, бала, туган нигез, ыру, эти, яшь пар, шатлык, тормыш, саулык, өй, мәхәббәт** һ. б. сүзләр белән ассоциацияләнә. Сораштырылучыларның күпчелеге ата-аналар, туганнары, йорт белән бәйле реакцияләр биргән. Шатлык, бәхет, мәхәббәт, күңел җылысы һ.б. кебек реакцияләр күп булды. Татар халкы элек электән гаиләнең кеше тормышында иң мөһим вазифа башкарганын аңлап килде.

Әхлакый кыйммәт – **сәламәтлек** – студентларда төрле реакцияләр тудырды. Яшьләрнең күпчелеге сәламәтлеккә омтыла, аны бәхет һәм яшәү чыганагы дип саный: **ял итү, саулык, тазару, исәнлек, бәхет, омтылу** һ.б. Бүгенге яшьләрнең спортның сәламәтлек чыганагы булуын яхшы белүе, күпләрнең спортның нинди дә булса төре белән шөгыльләнергә яратуы, моның ни дәрәҗәдә мөһим булуын аңлавы сөендерә. Мәсәлән, **сәламәт, яшәү, йөгерү, баскетбол, туп, бокс, яшәү рәвеше, шөгыйль, сәламәтлек, футбол, исәнлек, спортзал, бассейн, регби, туп.**

**Дин** стимулына китерелгән эксперимент нәтиҗәләре күрсәтүенчә, яшьләр Аллаһка, аның берлегенә ышаналар, хәтта башкаларны да аңа якынрак булырга чакыралар. **Дога** стимулына түбәндәге реакцияләр китерелде: **кылу, кылыйк, уку.** Информантларның барысының да диннәре ислам. Күбрәк ислам сүзенә **чисталык, яхшылык, мәрхәмәт, яшел төс** дигән җаваплар бирелгән. Шулай ук ислам сүзе белән бергә яшел сүзе бара. Чөнки бу төс татар халкы өчен бик мөһим, бу төс җәннәт бакчалары, яшьлек һәм муллык символы булып тора.

Эксперимент күрсәткәнчә, студентларның күбесе сәнгатькә уңай карый, һәркем нинди дә булса сәнгать төре белән шөгыльләнә. Иң күп очраган реакцияләр: **шигырь иҗат итү, язу, сәнгатьле уку, рәсем ясау, буяу**. Студентлар үз эшләре белән шөгыльләнергә яраталар, аларга үзләренең сәнгать эшләре ошый. Мәсәлән, **җан рәхәте, ял итү, яратам, дәрт, хис, канәгатьләнү, яхшы кәеф, ләззәтләнү, хисләр белән бәйле әйбер, җиңеллек алу** һ.б. Яшьләрнең күбесенең үз идеаллары, үрнәк итеп куючы шәхесләре бар: Әмирхан Еники, Габдулла Тукай, Илһам Шакиров, Салих Сәйдәшев, Илназ Сафиуллин, Салават Фәтхетдинов, Муса Җәлил.

Кызыклы җаваплар **әйләнә-тирә мохит** стимулына да күзәтелде. Яшьләрнең әйләнә-тирә мохитне сакларга омтылуларын, табигатьнең кеше тормышы өчен мөһимлеген аңлавын һәм башкаларны аңа сакчыл карарга чакыруларын күрү сөендерде. Мәсәлән, **саклау, мөһим, киләчәк, бурыч,**

**тормыш, тирәлек, кайгырту** һ.б. Әмма шул ук вакытта, сораштырылучылар бүгенге көндә әйләнә-тирә мохит проблемасы ни дәрәҗәдә зур чагылыш табуын аңлый. Кешеләр ничек кенә экология проблемаларыннан качарга тырышмасын, алар барыбер бар һәм үзләрен күрсәтәчәкләр. Мәсәлән, **начар, пластик, авыр, кара, проблема** һ.б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, безнең эш барышында татар телендәге түбәндәге сүзләрнең ассоциатив кырларына анализ ясалды: «гаилә», «сәламәтлек», «дин», «сәнгать» һәм «әйләнә-тирә мохит». Студентларның җавапларында күп кенә актуаль темалар күтәрелде: гаилә әгъзалары, дуслар арасында мөнәсәбәтләр, студентлар эшчәнлеге, аларның бүгенге дөньяга карашлары, экология проблемалары.

## Ф. ӘМИРХАН ИҖАТЫНДА МУЗЫКА ТӘНКЫЙТЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

*Фәттахова А., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит.– филол. фән. канд., доц. – Т.Ш. Гыйлаҗев*

XX гасыр башында дөньяга аваз салган татар публицистикасы, әдәби тәныйть кенә түгел, ә театр, музыка тәнкыйтьләре, аларның олы юл башында халык мәнфәгатьләре белән яшәгән бөек шәхесләребез торуы сәбәпле, бик тиз арада зур үсешкә ирешә. Шуларның берсе – Фатих Әмирхан. “Ф.Әмирхан публицистика арсеналындагы күп төрле формалардан файдаланган, иң катлаулы саналган очерк, фельетон жанрларында эшләгән, бөтенләй сирәк кулланыла торган рецензия-памфлет, интервью, фельетон, физиологик очерк кебекләрен дә язган. Аның публицистикасының палитрасы киң: бу өлкәдә ул – зур колачлы фикер иясе, үткен сатирик, нечкә хисле лирик” [2: 32].

Әдипнең замандашлары үзләренең истәлекләрендә язучының музыка белән кызыксынуын хәбәр итәләр. Ф. Әмирхан Казан һәм Уфада концертларны, опера спектакльләрен бер дә калдырмаган. Өйләрендә иске пианино торган. Яраткан опера арияләреннән өзекләрне ул “Кадерле минутлар”, “Хәзрәт үгетләргә килде” әсәрләренә дә кертеп җибәрә. Ф. Әмирхан музыкантлар арасында билгеле бер дәрәҗә яулый, чөнки әлеге сәнгать өлкәсе белән чын күңелдән кызыксына һәм кайбер белемнәргә дә ия була. Шуңа күрәдерме 1925 елда Ф. Әмирханны “Сания” операсын әзерләү комиссиясенең рәисе итеп куялар [4: 283].

Ф. Әмирхан үзе эшләгән матбугат битләрендә музыкага еш мөрәҗәгать итә. Публицист музыка, җыр өлкәсенә караган фикерләрен “Әдәбият кичәсе” (1907 һәм 1908), “Җырчыларымыз” (1915), “Театр һәм музыка” (1916), “Беренче татар операсы язылып бетү мөнәсәбәте белән” (1925) язмаларында белдерә.

“Әдәбият кичәсе” (1907) язмасында Ф. Әмирхан: “Кичә”нең программасын алып карап, өч-дүрт мәртәбә хор белән җырлау да булачагыны белеп, бер җәһәттән гаҗәпләнәм вә бер җәһәттән дә йөрәгем

курку хис итеп тора башлады” [1: 7], – дип яза. Публицист кичәдән канәгатьсезлек кичерешләре белән кайта: “Хор башлагач та, минем хәтеремә гарәп шагыйрьләреннән берсенең “кад кянә әлләзи ма хифте ән якүнә” дигән сүзе төште. Хор зәгыйфь, тавышлар бер тәртипкә китерелмәгән һәм җырлаучыларның җырның музыкасы белмәгәнене күрсәтерлек дәрәҗәдә тигезсез иде. Җырлаучылар арасында яхшы тавышлы егетләрнең дә барлыгыны колак махсус бер ләззәт белән сизсә дә, татарларның табигать аларга биргән ул хосусиятләрне тәрбия белән тәкмил итеп эшкә ярарлык һәйәткә китерер дәрәҗәгә җитмәгән икәнлекләрене уйлап, күңел әрәм булган вә булачак талантлар өчен хәсрәт кенә чикте” [1: 9]. Күргәнебезчә, Ф. Әмирханны, яхшы тавышлы, талантлы егетләр булып та, аларны һөнәри югарылыкта җырларлык итеп әзерләрлек махсус белемле җитәкче, хормейстер булмау борчый.

Кичәнең дәвамы төсендә “Ашказар көе” скрипкада уйнала. Ф. Әмирхан әлеге көйне татар халкының тарихы белән сәбәпле бәйләнештә карый: “Бөтен рухны татар халкының башыннан уздырган вә уздыра торган, хафа вә хәсрәтләре белән тутыра торган бу көй бөтен хазир булган татарларның йөрәкләрен бер ләхза эчендә әллә нинди иске, иске вә күптән узган хиссиятләр белән тутырган шикелле күренә иде” [1: 9]. Мәкалә авторы татар халкының икенче бөек улы Г. Тукайның халык җырлары хакындагы фикерләренә аваздаш караш уздыра: “ Белергә кирәк ки, халык җырлары – халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеседер. Бу – бертөрле сихерле көзгедер.Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр” [3: 168].

“Җырчыларымыз” (1915) мәкаләсендә язучы-публицист дүрт җырчы: Камил әл-Мотыйгый, Фәттах Латыйпов, Фатыйма Ихсанова, Сатирә Әхмәдиеваләрнең башкару осталыгына бәя бирә. Автор сүзне Камил әл-Мотыйгыйдан башлап, аның тавышының тәрбиясезлегенә тискәре мөнәсәбәт белдерә: “Камил әфәндененң үзенә күрә куәтле генә баритоны бар, ләкин эшләгәндә тагы да куәтле була алуы тәэмин ителә алырлык бу тавышта бер самимият вә рух юк; моның өстенә ул тавышның мусикави тәрбиядән камил мәхрүм икәнлеген өстәргә тиеш ки, безнең алда тупас, нәфасәт хисенә бернәрсә бирә алмый торган “кычкыру” торадыр” [1: 143]. Мәкалә авторын К. Мотыйгыйның “татар көйләрен бозып, иң мөбтәзил рус көйләре калыбына кертергә тырышуы” аеруча борчый [1: 143]. Шулай да артистның “Кара урман” җырын “европалаштырмыйча”, милли рухта башкаруы уңай тәэсир калдыра.

Фәттах Латыйпов турында да башлап уңай фикер әйтмәсә дә, соңыннан аның башкару осталыгын ассызыклый: “Фәттах әфәндедә тавыш

көчсез, аның салоннар өчен генә таман булырлык, ләкин рухлы, самимиятле вә ишетер өчен бик яхшы теноры бар”[1: 144]. Тәнкыйтьче Ф. Латыйпов җырлавын рәхәтләнеп, ләззәтләнеп тыңлый, чөнки ул татар көйләрен бозмый, аларга ялган катыштырып җырламый. Шулай ук тәнкыйтьче җырчы репертуарны да зәвык белән сайланган дип саный.

Хатын-кыз җырчылардан Ф. Ихсанованы тәнкыйтьтән түбән дәрәҗәдә начар җырчы дип әйтә: “Моның өстенә әле ул шундый бер цекелдәп тора торган мишәр тәләффызы белән сәхнәгә чыга ки, аның бер-ике сүзе ишетелү белән бөтен залда бер хәрәкәтле елмаю хөкем сөрә башлый”[1: 145]. Ф. Әмирхан сәләтсез, профессиональ әзерлексез җырчыларның сәхнәгә чыгуларын, халык зәвыгын җимерүен истә тотып, җинаять дип саный; аның карашынча, бу сәхнәне таптау, аны тәхкыйрь итү [1: 45].

Ф. Әмирхан, гәрчә музыкаль белемгә ия булмаса да, мәкаләләрендә музыка сәнгатенә караган терминнарны, төшенчәләрне урынлы файдалана. Димәк, әдип XX гасыр башыда үзенең беренче адымнарын ясый башлаган музыка сәнгате һәм аның тәныйтен формалаштыруга зур өлеш керткән. Аның бу тармактагы мирасы татар халкының мәдәниләштереүгә, аны рухи азатлыкка алып чыгуга, дөньяның алдынгы милләтләреннән берсенә әверелдерүгә хезмәт итә.

**Әдәбият**

1. Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда, 4 т.: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 390 б.

2. Нуруллина Р.М. Бөек язучы һәм бөек журналист // Тарих яза каләмем. – Казан: КДУ, 2009. – Б. 231–251.

3.Тукай Г.М. Әсәрләр. 6 томда: 4 т.: проза һәм публицистика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 431 б.

4. Юнусова Г.Ф. Фатих Амирхан и музыка // Духовное наследие: поиски и открытия. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – Вып. 2. – С. 282–289.

# НАЦИОНАЛЬНАЯ СПЕЦИФИКА ОБРАЗНЫХ СРАВНЕНИЙ
## (на материале повести А.И. Куприна «Поединок»)

*Фэн Юньхэ, КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук Р.М. Болгарова*

Изучение сравнений в разных языках позволяет обнаружить сходства в сознании, мышлении представителей различных национальностей, а также помогает выявить специфичность, своеобразность мировоззрений, менталитетов.

Известно, что стиль А.И. Куприна отличается такой особенностью, как частое употребление сравнений, за счет чего наиболее яркое раскрывается образ.

Методом сплошной выборки нами было отобрано более двухсот сравнительных конструкций из повести А.И. Куприна «Поединок». Проанализировав данные сравнения, мы разделили их на несколько основных семантических групп, в зависимости от образа, с которым идет сравнение.

Группа сравнений с названиями животных и птиц – одна из наиболее ярко выраженных и самых больших по количеству сравнений в исследуемых текстах групп компаративных конструкций.

Человек тесно связан с миром животных. Он познает себя через познание зверей, их поведения, повадок, а нередко и сравнивает себя с животными. У носителей русского языка существует большое количество сравнений с животными, многие из которых на сегодняшний день перешли в ряды устойчивых сравнительных конструкций.

Компаративная конструкция *«как собака»* устоялась в русском языке уже давно. Например, в повести «Поединок» присутствует такое сравнение: «А *он говорит*: «*Это мы, вроде собак, на луну воем»* [1]. Образ собаки имеет несколько значений, в зависимости от контекста. Чаще всего сравнение с собакой приобретает негативный, отрицательный оттенок, тогда как сама собака считается животным преданным, верным, отважным. И в данном примере образ собаки применяется для того, чтобы передать бесполезность тех действий, которые заставляют совершать военных в казарме.

В следующем примере сравнение с собакой имеет несколько другой смысл: *«Если бы от меня зависело, я бы этаких людей стреляла, как бешеных собак»* [1]. Здесь в основе лежит значение «убить безжалостно, как что-то совершенно ненужное, мешающее, причиняющее беспокойство и вред».

Еще одно животное, с которым нередко сравнивается человек – это лев или тигр: *«Солдаты дерутся, как львы, они ни разу не поколебались, хотя ряды их с каждой секундой тают под градом вражеских выстрелов»; «Лют! Аки тигра!»* [1].

Одним из образов со значением храбрости, мужественности является орел. В приведенном ниже примере в основе лежит иной смысл, сравнение с данной птицей вносит оттенок молодцеватости, задора и веселья: *«Солдат должен иметь в себе веселость, как орел»* [1].

Бытует мнение, что орел храбр и бесстрашен, он способен на самые отважные и дерзкие поступки, именно поэтому в представлениях русских эта храбрая птица является символом молодости и энергичности. Эта птица наделена царственностью, величием, достоинством, ясностью ума и мудростью. Кроме того, в России орел является символом государственности.

Если орел придает положительный оттенок лицу, которое является субъектом сравнения, то ворона чаще всего используется для раскрытия чьих-либо недостатков: «*Из его раскрытого рта вырывается, точно у осипшей вороны, одинокий шипящий звук»* [1]. Автор применил данный образ для передачи того, как герой не в состоянии проговорить ни слова, скорее из-за своей скованности, стеснительности, и издает лишь слабые звуки, а не отдельные слова, что несет в себе отрицательную оценку происходящего.

Несомненно, А.И. Куприн является мастером художественного слова. Он умеет подобрать необычные сравнения или использовать уже устоявшиеся таким образом, что они прозвучат по-новому ярко, выразительно. Удачным примером, по нашему мнению, может послужить следующая сравнительная конструкция: «*Сейчас же за окном начинался сад, где во множестве росли черешни, все белые от цветов, круглые и кудрявые, точно стадо белоснежных овец, точно толпа девочек в белых платьях*» [1]. Такое сравнение свидетельствует о любви автора к природе, к каждому ее проявлению, которое для А. Куприна подобно чуду.

Образы барана и овцы в русском языке несколько отличаются друг от друга по значению. С бараном сравнивают глупого, упрямого человека, а с овцой – невинного или притворяющегося невинным. Сравнение с овцой почти всегда имеет негативное значение, а сравнение с бараном может вносить и положительные оттенки в образ, например, «*милый, как барашек*»; «*кудрявый, как барашек*»; «*волосы как у барашка*» (если речь идет о густых, вьющихся волосах). В следующем примере образ барана несет отрицательное значение: «*Только не смейте делать на меня таких бараньих глаз*» [1].

Таким образом, в повести А.И. Куприна «Поединок» самой многочисленной является группа сравнений, где эталоном выступают образы животных и птиц. Связано это с тем, что нередко человек ассоциирует себя с животным или же олицетворяет зверей, наделяя их человеческими качествами. Сравнение, являясь средством познания окружающей действительности, отражает менталитет, определенный склад ума каждого народа. И стоит помнить, что писатель, используя его в своем художественном тексте, обращается как к общим понятиям, свойственным его родной культуре, так и к своим собственным убеждениям, к своему индивидуальному видению мира. Таким образом, национально-культурное смешивается с индивидуальным. В итоге мы иногда получаем совершенно удивительные образы, необычные и красочные сравнения, позволяющие взглянуть на мир с другой точки зрения.

**Литература**

1. Куприн А.И. Поединок. URL: http://az.lib.ru/k/kuprin_a_i/text_0150.shtml (дата обращения 14.01.2020).

## АШ-СУ РЕЦЕПТЛАРЫНЫҢ БАШ ИСЕМНӘРЕН ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Хаерова Л., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол.фән.канд., доц. Р.С. Нурмөхәммәтова*

Аш-су рецептларын тәрҗемә итү аерым бер халык мәдәниятенең үзенчәлекләрен белүне таләп итә. Күпчелек ризык атамалары рецепт контекстында баш исемгә әйләнә. Һәм аларның күбесе инде телдә еш

кулланылышка кергән, халык тарафыннан таныла торган гадәти атама булырга мөмкин. Мәсәлән, окрошка, холодец, безе һ.б. Мондый очракта тәрҗемәче популяр ризык атамалары белән таныш булырга, аларны аңлатып бирә белергә тиеш.

М.В. Ундрицова үз хезмәтләрендә аш-су рецептларының баш исемнәрен тәрҗемә итүне анализлый. "Укучы да, тәрҗемәче дә, иң алдан баш исемгә игътибар итә. Баш исемнәр, аш-су китапларында көндәлек кулланылышта булган ризык атамаларыннан күпкә катлаулырак итеп китерелсәләр дә, аларны халыкның көнкүрешен һәм холкын чагылдыра торган лексемалар һәм реалияләр рәтенә кертеп була. Ризыкка нәкъ менә аларның исемнәре милли колорит өсти" [1: 63].

П.П. Буркова шулай ук аш-су рецептының баш исеменә игътибар итә. Аныңча, баш исемнең роле аш-су рецептының укылышын тәэмин итә, ягъни ул алдан ук укучыга нинди дә булса мәгълүмат биреп куя һәм аны тагын да тирәнәйтер өчен укучы текстны укырга тиеш була. Баш исемдә җыйнак рәвештә текстның төп эчтәлеге бирелә, шул ук вакытта ул символик, тематиклаштыру һәм бәя бирү функцияләренә дә ия. Баш исем текстка каршы куела. Мәсәлән, менюда баш исем астында ниндидер бер текст барлыгы күздә тотыла. Шул рәвешле, баш исем текстның сөземтәсе булып тора, ул – бербөтен һәм чагыштырмача мөстәкыйль [2: 11].

Мисалларга игътибар итик.

*7. Күбек (Безе). ("Инстраграмм").*

Монда күбекнең "безе" икәнлеге татар телендәге аш-су терминологиясе белән таныш булмаган укучылар өчен китерелгән, чөнки йомырка агын шикәр белән кушып ясала торган татлы ризыкның "күбек" икәнлеге Ю. Әхмәтҗановның 1983нче елда чыккан "Табын серләре" китабында ук әйтелә. Күбек соңгы елларда бик популярлашты һәм аның милли атамасын куллану телнең заманча таләпләргә җавап бирә.

*8. Каймаклы пирог "Сметанник" ("Инстраграмм").*

Әлеге мисалда аңлатып бирү ярдәмендә тәрҗемә итү күзәтелә. Тәрҗемә авторы баш исемне татарчалаштырып, "Сметанник" атамасына "каймаклы пирог" дип тә өсти. "Пирог" шул ук вакытта, татар телендә эквиваленты булмаган тагын бер тел берәмлеге. "Сметанник" исә иҗади рәвештә рус теле чаралары ярдәмендә уйлап табылган оригиналь атама, аның, реалияләрнеке кебек, эквиваленты юк.

*9. "Грекча салат" (ВКонтакте).*

Бу очракта баш исемдә ризыкның барлыкка килү урыны аталган. Русча "Греческий салат" дигән исемдә дә салатның кайсы илгә каравына ишарә ителә. Бу турыдан-туры тәрҗемә.

*4. Койка (дерелдек) (Watan.su).*

Әлеге атама рус телендәге “холодец”ка туры килә, бу ике телдә дә бер үк реалия, ике мәдәнияттә дә әзерләнүе буенча охшаш милли ризык. Шуңа күрә, баш исемне татар телендәге сүз белән алмаштырып була.

*5. Куастан салкын аш (Watan.su).*

Бирелгән баш исемдә рус телендәге “квас” сүзе татар теленә эпентеза күрешене һәм “в”авазын дифтонг белән алыштыру ярдәмендә якын китерелә. Әлеге ризыкның төрле рецептлары бар, күпчелек исә, ул рус телендәге “окрошка”га кайтып кала. Димәк, монда баш исем рус телендәге реалияне аңлатып бирү рәвешендә тәрҗемә ителгән.

*6. Күптермә (Watan.su).*

2007 елгы татарча-русча сүзлектә мондый сүзлек мәкаләсе бирелә: “күптермә – сущ. кул. пышка; бодай ~се пышка из пшеничной муки”. Димәк, әлеге баш исемнең һәм сүзнең татар телендә туры эквиваленты бар. Бу очракта баш исем турыдан-туры тәрҗемә ителгән, һәм хәтта әлеге ике сүзнең “пышный” мәгънәләре дә туры килә.

*7. Тәмле чизкейк (“Инстраграмм”).*

Чизкейк – инглиз теленең “cheese cake” сүзтезмәсенә барып тоташа. Ул транскрипция алымы белән бирелгән һәм рус теленә дә, татар теленә дә “чизкейк” рәвешендә кергән. Рус һәм татар мәдәниятендә дә мондый ризык юк, ул инглиз телендәге реалия.

Нәтиҗә ясап, рецептларның баш исемнәрен тәрҗемә иткәндә транскрипция, транслитерация, тасвирлап аңлату һәм калькалаштыру алымнары киң кулланыла. Рецептлар тәрҗемәләрендә оригиналдагы мәгълүматны саклап калу, әгәр дә баш исем иҗади эшләнелешле икән, аңардагы тел сурәтләү чараларын саклау да урын таба. Профессиональ тәрҗемәчеләр тарафыннан эшләнелмәгән рецепт текстларында баш исемнәр әдәби нормаларга туры китереп түгел, ә халык сөйләменә туры китерелеп бирелә.

**Әдәбият**


1. Буркова П.П. Кулинарный рецепт как особый вид текста (на материале русского и немецкого языков): дисс канд. филол. наук: 10.02.19, 10.02.01. – Ставрополь, 2004. – 212 с.
2. Ундрицова М. В. Трансформации при переводе глюттонических текстов (на материале английского, французского, греческого и русского языков) // Вестник Московского университета. – М., 2015. – С. 57–69.


## РЕНАТ ХАРИС ИҖАТЫНДА ТУГАН ТЕЛНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ


*Ханмурзин С., Буа р-ны Зур Фролово мәктәбе, X сыйныф*

*Фән. җит. – Г.Т. Исмәгыйлева*


Туган телнең яшәеше, сафлыгы турында Ренат Харис иҗатында шактый табарга була. Тел турында болганышлар булганда да шагыйрь әдәби тәрҗемә турында скайптан, онлайн форматында бөтен Рәсәйгә

мастер-класс үткәрде. Анда тел мәсьәләсе дә күтәрелде. “Рәсәйдә яшәүче төрле милләт язучылары икетелле, теләсә нинди шагыйрьнең яки язучының әсәрләрен үз телләренә рәхәтләнеп тәрҗемә итә алалар. Аларга тәрҗемәче кирәк түгел. Рус язучыларына һәм шагыйрьләренә башка телләрдән рус теленә тәрҗемә итү өчен тәрҗемәче кирәк. Татар язучысына рус телен белү ярдәм итә, ә рус язучысына татар яки башка телләрне белмәү күп кенә кыенлык тудыра. Күп телләр белү – башка милләтләргә хөрмәт билгесе дә ул. Татарстанда, Мордовиядә, Чувашиядә яки башка регионда яшәүче рус кешесенә үзен бу халыктан ерагаймасын өчен шушы төбәкнең телен аралашу, аңлау дәрәҗәсендә белергә тиеш. Бу кыенмы? Артык тел белү әле беркемгә дә комачауламады”, – ди.

Ренат Харис иҗатында “Туган тел” мәсьәләсенең аз урын алмавын күрдем. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: бары шигырьне тулысы белән караганда гына образлылыкны, матурлыкны күрергә була.

Ренат Харис: “Туган тел һәр кеше өчен кадерле, ул аның байлыгының күрсәткече, дөресрәге халыкның рухи байлыгы. Әсәрләрнең теге яки бу телдә булуы безнең байлыгыбыз, безнең тормышыбыз”, – ди.

Кем язса да – туган телен мактап язар...
Һәм шул телдә кайчак язар сап-сай әсәр...
Төссез әсәр телне хурлар, ямен урлар.
Яхшы әсәр, яхшы улдай, телне зурлар!

Әлеге шигырендә автор телне милләтнең тормышы белән чагыштыра, аның аерылгысыз булуын күрсәтә. Автор өчен туган тел – татар теле. Бу милләт белән бәйле.

Шигырьнең кайбер юлларында татар халкы, милләте кичергән тарихи вакыйгаларны да күздән кичерәбез.

Аерылганны аю ашар, диләр...
Татар телем бик күп гасырлар
Аю-бүреләрдән таланса да,
Исән кала алды асылда («Төрки телләр» шигыре).

Милләт темасы да ачык күренә. Тарихи үткәннәргә дә әйләнеп кайта. Горурлык та бар анда.

Үткәнемнән баш тартмыйча
Яши бирәмен мин –татар...
Беркем дә табалмас миндә
Йөзне кызартырлык таплар. («Татарлар» поэма-монологы)
Урыс белән татар арасын
Бүлми инде низаг ярасы –
Ике халык бүген асылда
Бергә укмашуга хасиллар (“Худяков” поэмасы).

Ренат Харис үзенең теле, халкы белән горурлана.

Халыкара атамалар бирдең
Бик күп рухи, матди халәткә...
Һәр заманга замандашы булып
Яшәрсең син, телем, әлбәттә! («Чехов базары»)

Ренат Харис иҗатында туган телебезнең яшәү дәверендә күп кенә кыенлыклар кичерүен күрдек. Туган телебезгә бетү куркынычы янавын да сизәргә була.

Шундый сүзләр миңа җиткән саен
Сталинны бераз сагынам,
Шундый сүзләр йөрәккә тигәндә
Ачу уты җанда кабына,
Шундый сүзләр җелегемә тия...
Тигез җирдә телем абына...(«Шөкер» шигыре)

Шагыйрь иҗатында горурлык хисе дә, шатлык хисе дә, кайгыру да чагыла.

Югарыда мисалга китерелгән шигырьләрдән нәтиҗә ясарга да мөмкин. Телебезгә “туган телем, “татар телем”, телем”, “үз телем” дип эндәшә.

Ренат Харис халык шагыйре буларак үзенең әсәрләрендә халык акылын, аның теленә булган мөнәсәбәтен бик якын итеп, горурланып күрсәтә. Шигырьләреннән күренгәнчә, якташым нинди генә темага алынса да, аны ныклы өйрәнеп, ягъни үзләрен чолгап алган дөньяны, бигрәк тә табигать күренешләренә мөрәҗәгать итеп, шулар аша кеше күңеле, кичерешләре белән бәйле хәл-вакыйгаларны сурәтләргә, аларга олы мәгънә салырга ярата.

Автор туган тел турында язылган шигырьләренә “Җылылык”, “Матурлык”, “якынлык” төшенчәләрен сала.

Күргәнебезчә, Ренат Харис иҗатында “Туган тел” төрле яклап ачыла. Ул “туган тел”не шагыйрь буларак кына түгел, үз халкының карашыннан чыгып фикер йөртә.

Ренат Харисның күпчелек шигырьләрендә туган телебезгә хөрмәт, ярату чагыла. Автор һәрвакыт: “минем телем”, “телем”, “туган телем” , ”атам-анам теле”, “үз телем”, “әни теле” дип яратып эндәшә. Ул нәкъ шулай булырга тиеш тә. Тел проблемалары килеп чыкканда, Ренат Харис үзенең фикерләре белән уртаклашты. Телнең кирәклегенә басым ясады. Милләтләрнең дус яшәүләрен теләде. Безнең Буа районын мисал итеп китерде.

Ренат Харис халык шагыйре буларак үзенең әсәрләрендә халык уен, халкыбыз зирәклеген һәм аның татар теленә мөнәсәбәтен бик якын итеп, горурлык хисләре белән бирә.

Туган тел турында кайгырту – киләчәгебез турында кайгырту ул. Буалылар үз якларын яраталар, аның тарихы һәм традицияләре белән горурланалар, байлыкларын арттыралар.

## ГӨЛНУР АЙЗАТУЛЛОВА ИҖАТЫНДА СУГЫШ ТЕМАСЫ

*Ханмурзина Н., Буа р-ны Зур Фролово мәктәбе, X сыйныф*
*Җитәкче – Г.Т. Исмәгыйлева*

Бөек Ватан сугышы темасын яктырткан әсәрләрнең әһәмияте бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый. Бу темага кагылган әсәрләрне укып, без шуны аңлыйбыз: безгә бер-беребезгә карата миһербанлырак, шәфкатьлерәк булырга кирәк. Бәлки, кайберәүләр яшәүнең кадерен белеп тә бетермиләрдер. Минемчә, Бөек Ватан сугышы темасына багышланган әсәрләр хәзерге тыныч, матур тормыш өчен гомерләрен дә кызганмаган, фронтта һәлак булган каһарманнарны онытмаска һәм яшәүнең кадерен белергә өйрәтәләр.

Әйе, әдәбиятыбызда сугыш темасына багышланган әсәрләр бүген дә туып тора. Чөнки теләсә нинди сугыш кешенең табигатенә каршы: анда кан коела, анда кеше гомере өзелә. Шуңа күрә язучылар әсәрләрендә явызлык бары тик үзеннән дә зуррак усаллык хисләре генә тудыра дигән фикерне уздырганнар. Бу темага сугыш ачысын күрмәүчеләр дә мөрәҗәгавть иткән. Якташым – Гөлнур Айзат шундыйлардан.

“– Әти сиңа сугыштан хатлар яздымы соң?

– Язмаган кая? Әтиең бит бик матур шигырьләр яза иде, хатларны да күп вакытта шигырьләр, җырлар белән язар иде...

Бервакыт Ржев, Тихвинь, янындагы сугышларда чакта миналар шартлап, куллары, аяклары яралангач, миңа дигән хатын иптәш малаена әйтеп яздырган иде” (“Әтием ядкаре” хикәясеннән).

Аналарның күкрәгендә
Көн тудымы –
Кабат яра.
Сугыш, сугыш!
Бер гөнаһсыз
Сабыйларның җанын ала.
Мин дә – ана,
Йөрәк парәм
Өзгәләнә көннәр туса.
Тормыш матур
Һәркемгә дә –
Иле азат, тыныч булса (Кайда сез, ирләр” шигыре)

Гөлнур Айзатның “Кәшемир яулык” хикәсендә егетнең сугыш афәтләрен очратабыз. “Авылның бер дигән егетләре сугышка китә торды, югала торды... Гәрәйгә дә хәбәр килде. Ул соңгы мәртәбә булса да сөеклесен күреп калыйм дип, Галимәләр бакчасына сикереп төште дә, чолан янындагы тәрәзәгә чиртте. Галимә белән Галиябану шунда йоклыйлар иде. Менә пәрдә күтәрелде, аннан кадерлесенең йөзе күренде. Кыз акрын гына тәрәзәнең бер капкачын ачты:

– Гәрәй, җаным, сине дә сугышка алалармыни?

– Аппагым минем, сине кемнәргә калдырып китәргә язган? Мин сине башка күрә алмасам, бүләгемне минем төсем итеп сакла, дип Галимәгә кәшемир яулыкны сузды да, кызны кысып кочаклаганнан соң, күздән югалды.”

“Каргыш” хикәясендә тылдагы авыр тормышны күрергә була.

“Илдә Бөек Ватан сугышы барган чак иде. Фәгыйлә башта ирен, аннан өч улын бер-бер артлы сугышка озатты. Кул арасына керерлек ун яшьлек кызы, ике яшен яңа тутырган һәм биш айлык уллары белән ялгызы торып калды Фәгыйлә. Иртәдән кичкә кадәр колхоз эшенә дә чапты, йортны да тартты. Сугышка китеп өч ай да үтмәде, өченче улыннан кара пичәтле хат килде, хәбәрсез югалды балакай. Балалары арасында иң күндәме, иң тырышы, әрсезе, иң сабыры да шул Рифхәте иде. Кай җирләрдә генә ятып калгандыр инде башкае балакаеның? Бу хәсрәтен йотарга да өлгермәде, кырдан кайткан төшенә биш яшьлек төпчеге дә җан биргән иде.”

Без, яшьләр, сугыш афәтен, аның бөтен фаҗигасен язучыларыбыз, шагыйрьләребез язган әсәрләр аша, бабаларыбыз сөйләгәнне тыңлап кына күз алдына китерәбез. Әмма теләгебез бер: Бөек Ватан сугышы, Әфган, Чечня сугышлары кебек сугышлар кешелек дөньясындагы иң соңгы сугышлар булсын иде. Үзем иҗат иткән шигыремдә дә бу ачык чагыла.

**Яшик җирдә сугышсыз**

Кызу җәйге иртә, таң беленә,
Кояш чыга тааулар артыннан.
Тик бер хәбәр үзәкләрне өзгеч,
Явыз Гитлер сугыш башлаган.
Сугыш дигәч, күзалдына килә
Кан, хәсрәт, ут, үлем, яралар.
Ачлы-туклы яшәү, күз яшьләре
Тол аналар, ятим балалар.
Бер кешене аямады сугыш
Яше-карты сугыш кырында.
Авыр тормышны тарта изелеп,
Авыл калды кызлар кулында.
Көндезләрен җир сөрделәр алар,
Урак урды бу нәни куллар.
Ничек түзде икән йөрәкләре,
Ач ятканда нәни сабыйлар.
Черек бәрәңге белән кычыткан,
Алабута ашап үстеләр.
Төннәр буе утырып бәйләнгән,
Оекбашлар фронтка киттеләр.

Ятим калды, тол калдылар күпләр,
Кайберәүләр кайтты аяксыз.
Әй, ходаем, үтенепләр сорыйм,
Яшик әле илдә сугышсыз.

## ОСОБЕННОСТИ ПЕРЕВОДА ЭКОНОМИЧЕСКИХ ТЕРМИНОВ С АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА НА РУССКИЙ ЯЗЫК

*Хасанзянова Г., КФУ, аспирант III курса*
*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. Р.Р. Замалетдинов*

В условиях интеграции нашей страны в мировое экономическое сообщество постоянно растет количество текстов на экономическую тематику, представляющих большой интерес русскоязычному читателю. Следовательно, с лингвистической точки зрения, всю большую актуальность представляет собой изучение английского.

Исследования в области перевода специальной экономической терминологии – важная и актуальная задача, направленная на достижение адекватных переводов, способствующая решению многих прикладных задач и ускорению обмена информацией в области новейших достижений экономической науки среди специалистов и ученых разных стран [2: 36].

Актуальность изучения этой темы обусловлена повышением значимости перевода экономического термина в условиях интеграции нашей страны в мировое экономическое сообщество.

Проблема исследования обусловлена трудностями при переводе терминов в текстах экономической тематики. По данному направлению работали многие исследователи, такие как: Авербух К.Я., Александрова Н.Г., Алексеев П.М., Арнольд И.В., Бархударов Л.С., Быкова и другие.

Материалом исследования послужили английские тексты экономической тематики. Термины были выделены посредством сплошной выборки из текста газет FinancialTimes, TheEconomist.

**Цель** исследования – изучить структуру, семантику и перевод английских экономических терминов.

Специфика терминов как особого лексического разряда слов состоит в том, что они создаются в процессе производственной и научной деятельности и поэтому функционируют лишь среди людей, обладающих соответствующими научными и производственными реалиями, то есть макроконтекстом. Поэтому в отличие от обычных слов, однозначность которых в речевой коммуникации обеспечивается ситуацией или лингвистическим контекстом, однозначность термина регламентируется экстралингвистическим макроконтекстом или лингвистическим микроконтекстом.

Термины-словосочетания создаются путем добавления к термину, обозначающему родовое понятие, конкретизирующих признаков с целью получить видовые понятия, непосредственно связанные с исходным. Такие

термины фактически представляют собой свернутые определения, подводящие данное понятие под более общее и одновременно указывающие его специфический признак. Таким образом, образуются своеобразные терминологические гнезда, охватывающие многочисленные разновидности обозначаемого явления [1: 5].

Например, английский термин tax, определяемый как «налог, пошлина, сбор, членские взносы, бремя, гнёт, груз, тяжесть, плата по счёту, цена, неодобрение, порицание; обвинение» используется как основа для ряда терминов, уточняющих характер налогового сбора:

- *incometax* – подоходный налог;
- *expenditure tax* – налог на расходы;
- *land-tax* – налог на землю [4: 32].

Использование терминов-сложных слов. Термин-сложное слово представляет собой чаще всего сочетание двух или больше основ имен существительных, которые совпадают с формами, приводимыми в словарях: distributableitems (нераспределяемая прибыль), bookvalue (балансовая стоимость) и т.д. Терминологическое устойчивое словосочетание обычно образуется сочетанием имени прилагательного с именем существительным, причастия с существительным или нескольких существительных, соединенных предлогами [3: 12]: accountingconvention (метод бухгалтерского учета), buildingofcompetencies (повышение квалификации), utilizationoflooses (погашение убытков) [5: 16].

- value-addedtax – налог на добавленную стоимость [6: 61].

Принадлежность одного из компонентов в структуре терминов ИЯ и ПЯ к различным частям речи может быть обусловлена как различиями в грамматическом строе языков, так и исторически сложившимися особенностями обозначения понятия в каждом языке.

Различия в грамматическом строе языков является основной причиной расхождений в морфосинтаксической структуре английских терминов, состоящих из двух и более имен существительных, и их русских эквивалентов.

В некоторых случаях лексико-грамматическая структура русского составного термина отражает сложный характер английского термина, образованного сложением двух слов: leaseback – возвратный лизинг; на основе составного термина (в результате эллипсиса): rentals: 1) затраты на аренду; 2) арендная плата (от rentalexpenses, rentalpayments); nominee – номинальный акционер (от nomineeshareholder) [4: 44].

Таким образом, термины-словосочетания продуктивно функционируют в деловом английском языке; для перевода терминов-словосочетаний используются следующие структуры: «имя существительное + имя существительное» соответствует конструкция «имя прилагательное + имя существительное», при переводе происходит изменение падежной формы

определяющего существительного и изменение числа одновременно с изменением падежной формы (в том числе с введением предлога). Термины, состоящие из двух имен существительных, связанных предлогом of, переводятся термином со структурой «имя существительное + имя существительное в родительном падеже».

В ходе проведенной работы можно сделать определенные выводы:

1. Исследование понятия, основных положений терминоведения показало, что терминоведение – это наука, изучающая специальную лексику с точки зрения её типологии, происхождения, формы, содержания и функционирования, а также использования, упорядочения и создания [1: 12].

2. Термины являются единицами языкового и профессионального знания, обеспечивающими эффективность межкультурной коммуникации. Экономические термины представляют собой слова и словосочетания специального языка, употребляемые для обозначения логически точно сформулированных понятий данной отрасли знаний и составляют основу экономической теории. Они обладают рядом признаков. С логической точки зрения экономические термины являются смысловой доминантой высказывания. В лингвистическом отношении экономические термины представляют собой лексико-грамматические единицы языка, функционирующие как в системе общелитературного национального языка, так и в системе экономической науки [4: 4]. Как лексико-грамматическая единица языка экономический термин обладает признаками, характерными для лексических единиц общелитературного языка, а именно: семантикой и смыслом. Экономический термин также обладает всеми функциями, присущими слову: номинативной, сигнификативной, коммуникативной и прагматической. Характерными особенностями экономического термина как единицы научного знания являются: однозначность, точность, систематичность, отсутствие синонимов, безэмоциональность, краткость [1: 6].

3. Номинативный характер терминологии: однокомпонентные, двухкомпонентные термины и словосочетания и трехкомпонентные и более термины (полиномы) и словосочетания. Так же экономические термины принято классифицировать по логическому, лингвистическому, науковедческому и прочим принципам. Эти классификации в своей совокупности характеризуют роль и место терминов в экономической, бухгалтерской, финансовой, управленческой и других сферах функционирования современного общества [3: 21].

Таким образом, в период развития экономических отношений особенно важна коммуникация в области экономики и, соответственно, адекватный перевод такого важного пласта языка как экономической терминологии.

**Литература**

1. Авербух К.Я. Терминологическая вариантность и некоторые проблемы прикладной лингвистики // Проблемы перевода научно-технической литературы: Сб. науч. тр. – Саратов: Изд-во Саратовского университета, 1988. – С. 3–8.

2. Бархударов Л. С. Язык и перевод. – М.: МО, 1975.
3. Касьянов В.В. Сопоставительный анализ современной терминологии финансовой деятельности в английском и русском языках: Автореф. дисс. канд. филол. наук. – Москва – 2001. – 29 с.
4. Соколова, Т.В. Особенности перевода английских экономических текстов // Социальные и гуманитарные исследования: традиции и реальности. – Саранск, 2000. – С. 341–342.

## ТРАНСЛИНГВИЗМ В ИЗУЧЕНИИ ЯЗЫКОВ В БИ- И ПОЛИЛИНГВАЛЬНОЙ СРЕДЕ

*Хасбиева А., КФУ, студент V курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. А.Х. Ашрапова*

Взаимодействие языка в речи имеет несколько названий: билингвизм, мультилингвизм, полилингвизм. Одним из наиболее распространенных подходов к изучению контактирующих речевых практик является теория переключения кодов. В дополнение к термину "переключение кода" также используются "смешивание кода" и "слияние кода". Однако существуют языковые явления, которые не вписываются в эту классификацию. Это вызвало появление нового термина – "транслингвизм".

Концепция транслингвальности возникает в лингвистике и лингводидактике в конце 1990-х гг., и одним из ее первых авторов была Вивиан Замэль. Появившийся относительно недавно термин подразумевает не только сравнение нескольких языков и культур и их взаимодействие, но и плавный переход от одной лингвокультуры к другой. В результате говорящий способен использовать весь свой лингвистический и культурный потенциал, обеспеченный всеми языками этого репертуара. Этот процесс вызывает все больший интерес у исследователей, так как транслингвизм способствует созданию и развитию различных направлений в языкознании, педагогике и других сферах.

Большое количество работ, посвященных исследованиям использования транслингвизма в школе, принадлежат Офелии Гарсиа. Она предлагает в билингвальных школах постоянно проводить сопоставление языков, осуществлять переключение с одного языка на другой, больше читать писателей-билингвов, использовать билингвизм творчески в письме. Кроме того, она предлагает использовать следующие коммуникативные стратегии в транслингвальной ситуации общения: заимствования; гибридизация языков, пиджинизация; обращению к интернациональным словам; перифраз; активизации металингвистических знаний и др. Задача преподавателя языка – по возможности максимально использовать потенциал этих стратегий для научения коммуникативной деятельности в условиях трансъязычия [2: 92].

Однако идея использования трансъязычия (языковая практика билингвов) в школе разделила преподавателей на два лагеря: тех, кто поддерживают и активно пользуются этим педагогическим подходом и тех, кто категорически

против такого типа обучения. Преподавателей первого типа крайне мало, но, несмотря на это, они часто работают с несколькими языками и считают, что это положительно влияет на учеников и их успехи. Второй же тип преподавателей воспринимают трансъязычие лишь как преграду.

Как же на самом деле трансъязычие влияет на качество обучения? Jason Anderson и Amy Lightfoot провели исследование, результаты которого показали отношение преподавателей школ Индии к обращению к нескольким языкам при обучении детей. Большинство респондентов сообщили, что они лишь изредка используют другие языки в классах английского языка, чаще всего для сравнения и противопоставления языковых особенностей, а также при объяснении понятий, управлении классом и переводе для учащихся. Лишь малое количество учителей сообщили об активном содействии трансъязычия во время обучения языку, особенно на практических занятиях. Более опытные учителя чаще поддерживали данный подход и сообщали о положительных результатах. Авторы утверждают, что существует необходимость в явном акценте на использовании других языков в педагогическом образовании и предлагают более последовательную поддержку практики перевода на другие языки в рамках всей образовательной системы.

Данное исследование показало, что слишком мало учителей используют трансъязычие на своих уроках и, хотя этот подход получил позитивное научное эхо, его перенос в педагогическую практику был встречен с явным скептицизмом. Как правило, учителя считают, что разрешение языкового многообразия в классе будет иметь негативные последствия для обучения. Помимо их недостаточного владения языками меньшинств, типичными аргументами являются страх разрушения межъязыковой дружбы или утверждение, что снижение уровня владения школьниками семейными языками не позволяет использовать их для обучения. В сумме, заложенная в одноязычную идеологию педагогическая практика часто не признает ценности языков меньшинств для обучения учащихся.

Таким образом, изучение проблемы транслингвизма и его использования в педагогике показывает, что использование нескольких языков при обучении оказывает положительное влияние на учеников. Сравнения и противопоставления языковых особенностей, объяснение понятий, выполнение коммуникативных задач с помощью трансъязычия позволяют детям лучше понять и запомнить материал. Именно поэтому необходимо увеличение количества преподавателей, поддерживающих данный педагогический подход к изучению языков, т.к. его результативность и удобство не раз были доказаны. Однако проблема данного языкового явления была и остается актуальной. Несмотря на многочисленные исследования, многие стороны данного вопроса остаются не раскрытыми, что показывает необходимость дальнейшего изучения данного явления.

**Литература**

1. Anderson J. & Lightfoot A. (2018). Translingual practices in English classrooms in India: current perceptions and future possibilities, International Journal of Bilingual Education and Bilingualism.

2. Garcнa O. and Wei L. Translanguaging: Language, Bilingualism and Education. – Basingstoke, U.K.: Palgrave Macmillan. 2014. –165 pp.

3. Прошина З. Г. Транслингвизм и его прикладное значение, 2016.

## ҖИДЕ САНЫ МИСАЛЫНДА ТЕЛ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ БӘЙЛӘНЕШЕ

*Хасбиуллина Г., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Ф.Ш. Нуриева*

Кеше көненә саннар белән бик еш эш йөртә. Татар телендә саннарны күләм-чаманы белдерүдән тыш куллану да актив күзәтелә. Бу сан сүз төркеменең төрки халыкларның саннар белән бәйле мәдәни үзенчәлекләре белән бәйле. Аеруча, җиде саны мисалында бу ачык күренә. Атнада да көннәр саны җиде. Кайбер төрки телләрдә атна билгеләмәсен җиде саны белән генә атыйлар.

Иң элек төрки телләрдә җиде санының хәрефләр белән бирелешен карап үтик: җиде – татарча, yedi – төрекчә, yeddi – азербәйҗан телендә, жеті – казахча, жети – кыргызча, yetti – үзбәкчә. Бу мисаллар әлеге санның килеп чыгышы гомумтөрки икәненә дәлил булып тора.

Р.Г. Әхмәтҗановның “Татар теленең этимологик сүзлеге”нә мөрәҗәгать итсәк, шушы аңлатмаларга тап булабыз. ҖИДЕ, диал. йӗдӗ, себ. йӗттӗ «семь» (йӗтӗ «неделя») < бор. төрки jetti, рефлекслары барча төрки телләрдә бар, к. ЭСТЯ IV: 167–168 (ышандырырлык этимологиясе юк диелә). Деривациясе (саннар өчен) регуляр. Җидегән [1: 267]. *Җидегән йолдыз* атамасында да кыргыз телендә җиде саны кулланыла – *Жети Аркар*.

Җиде сүзе белән ясалган фразеологизмнар күп. *Җиде бабадан калган* – күптәнге, элекке; *җиде диңгез артында* – бик еракта; *җиде җәһәннәм төбе* – чит күзләрдәнерактарак; *җиде иләктән үткәрү* – бик нык тикшерү; *җиде йозак астына бикләү* – яшерү; *җиде төн уртасында* – төнге вакытта, бик соң.

Җиде саны фразеологизмнарда күбесенчә арттыру мәгънәсен белдерә. Башка төрки телләрдә дә җиде санының фразеологизмнарда кулланылышы мисаллары. Үзбәк телендә: *Yetti notusimni yerga bukding-ku; yettinchi osmonda; yetti uxlab, tushiga kirmaslik* [5: 3]. Казах телендә: *жеті жұрт өткен жер; жеті жұрттың тілін білу; жеті қабат жер астында; жеті (қараңғы) түнде.*

Казах телендә җиде саны кулланылган *"жетіге келгенше бала жерден таяқ жейді"* дигән әйтем бар. Мәгънәсе: балага җиде яшь тулганчы, аңа җирдән эләгә, ягъни җиргә еш егыла.

Кыргыз телендә җиде саны хәтта ай атамасында очрый. Ноябрь ае кыргызча *жетинин ай* була. Кайбер чыганакларга караганда, ул җиде елга дигән мәгънәдә килә, ягъни елгалар ката дигәнне аңлата.

Шулай ук җиде саны кулланылган мәкальләр татар телендә шактый. *Җидесендә ни булса, җитмешендә шул булыр. Җиде атасын белмәгән – ятимлекнең билгесе. Җиденчели ни яман? Җитәкләшеп ятимнәр елый калса, шул яман. Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел. Дусыннан аерылган җиде ел елар, иленнән аерылган гомер буе лар. Ишәк җиде төрле йөзә белсә дә, су янына килгәч җидесен дә онытыр. Җиде кат үлчә, бер кат кис. Атлының юлы бер булса, җәяүленең сукмагы – җиде* [2: 4].

“Җиде күк каты” дигән гыйбарә дә төрки телләрдә еш кулланыла. Җиде сүзенең әлеге кулланылышы ислам диненә бәйле. Гомумән, ислам динендә 7 санына бәйләнешләр күп. Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренә хаҗга баручылар анда изге Кагъбә ташын *җиде* тапкыр әйләнә, изге Зәм-зәм суын эчә, әс-Сафа һәм әл-Мәрвә таулары арасыннан *җиде* тапкыр үтә. Пәйгамбәребез с.г.в. *җиде* яшьтән намаз укый башларга кушкан. “Фәтиха” сүрәсендә *җиде* аять бар.

Җиде элек-электән күп халыкларда изге сан буларак кабул ителгән. Бу төрки халыкларны гына түгел бөтен дөнья халыкларын берләштерә торган фактор. Җиде саны иске кирилл язуында “з” хәрефенең сан мәгънәсен аңлата һәм “земля” дигәнне белдерә, ягъни җир аңлатмасы белән тәңгәл килә. Мәсәлән, Вавилонда аллалар хөрмәтенә җиде баскычлы гыйбадәтханә төзелгән булган. Әлеге ил каһиннәре кешеләр үлемнән соң җиде капка аша үтеп, җиде дивар белән уратып алынган җир асты дөньясына эләгүләренә ышанган. Рим шәһәре җиде калкулык өстендә төзелгән. Грециядә җиделене Апполон саны дип йөрткәннәр, күп мифларда җиде саны очрый, мәсәлән, Калипсо Одиссейны әсирлектә җиде ел тоткан. Шулай ук бар кешегә дә дөньяның җиде могҗизасы таныш. Җиде саны тормыш-көнкүрешнең бар өлкәсендә дә еш очрый, шуңа да телдә дә актив кулланылышта саклана. Музыкаль ноталар саны – җиде, Салават күпере төсләре – җиде, хәтта Менделеев таблицасы да җиде периодка бүленгән.

Димәк, җиңе саны төрки халыклар арасында гына түгел, башка халыклар өчен дә үзенчәлекле мәгънәгә ия.

**Әдәбият**

1. Әхмәтҗанов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 543 б.

2. Исәнбәт Нәкый. Татар халык мәкальләре. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2010. – 798 б.

# ИКЕТЕЛЛЕЛЕК ШАРТЛАРЫНДА БАЛАЛАР СӨЙЛӘМЕНДӘ БАРЛЫККА КИЛГӘН ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

*Хафизова Я., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Г.Р. Галиуллина*

Сөйләм теле, әдәби нормаларның тиешенчә сакланмавы һәм гомумкулланылыштагы сүзләрнең күп булуыннан тыш, үз эченә диалектларны, гади сөйләм элементларын алу белән дә аерылып тора. Сөйләм телендә башка телләрдән кергән сүзләр дә, әдәби телдән беркадәр аермалы буларак, шактый иркен кулланыла. Алынмаларның бер төркеме матди байлык элементлары алышканда кергән булса, икенчеләре мәдәни яки сәяси бәйләнешләр, рухи мәдәният алмашу нәтиҗәсендә үтеп керәләр [3: 97].

Хәзерге татар сөйләм телендә рус теленнән үтеп кергән сүзләрнең актив кулланылышын аерым билгеләп үтәргә кирәк. Татар сөйләмендә рус сүзләре генә түгел, тотрыклы сүзтезмәләр, синтаксик конструкцияләр, морфологик чаралар да иркен кулланыла. Хәтта сөйләмдә татар һәм рус сүзләре үзара керешеп, гомуми лексик фонд хасил итә һәм ул чынбарлыкның аерым күренешләрен атау өчен, эмоциональ-экспрессив һ.б. максатлардан кулланыла башлый. Бу аңлы һәм аңсыз рәвештә булырга мөмкин [2: 31].

Бу үзенчәлек икетеллелек шартларында тагын да калку күренә. Икетеллелек – ул туган телне белү белән беррәттән, башка этнос белән теге яки бу коммуникация өлкәсендә аралаша алырлык тагын бер тел белү. Галимнәр бу күренешне билингвизм дип атыйлар, ә ике телне белүче кешене билингв дип йөртәләр. Билингвның “беренче теле” (туган теле, ана теле) – балачактан гаиләдә үзләштерелгән тел. “Икенче тел” – соңрак өйрәнелгән, сирәк очракта туган тел белән бер үк вакытта үзләштерелгән тел. Гадәттә әлеге телләрне белү һәм куллану дәрәҗәсе төрле: “икенче телдәге” аралашу компетенциясе түбәнрәк була. Әмма билингв күбрәк интенсивлык белән кулланган тел функциональ яктан беренче тел булып санала. Билингвның аралашу телен сайлау күп очракта коммуникатив өлкәгә һәм аралашу ситуациясенә бәйле [4: 30]. Билингвларның туганнан алып ике телне дә белү аларның эчке конфликтына китерергә мөмкин һәм китерә. Әлеге конфликт нәтиҗәсендә алар үз сөйләмендә күп кенә төрле типтагы хаталар ясый [5: 17].

Югарыда әйтеп кителгәнчә, аралашу өчен теге яки бу телне сайлау әйләнә-тирә мохиттән тора. Татар гаиләләрен алсак, авыл җирлегендә яки милли тирәлектә көн күргән гаиләләр татар мәдәниятенә өстенлек бирә һәм шуңа бәйле туган телдә аралашалар. Моннан тыш татар теле мондый очракта милли, мәдәни традицияләрне буыннарга тапшыру ролен башкара [1: 58]. Сөйләмдә кайсы телгә өстенлек бирү яшь үзенчәлегенә дә бәйле. Әгәр дә өлкәнрәк буын вәкилләре сөйләмендә рус теленең кулланылышы артык күзгә ташланмаса, яшьләр һәм балалар сөйләмендә бу – таралган

күренеш. Бигрәк тә балаларның сөйләменә игътибар итсәк, аларның күбесе татар теле белән рус теле лексикасын бергә кулланып сөйләшә, ә кайберләре туган телне аңласалар да, гомумән, рус телендә сөйләшәләр. Шәһәр балалары өчен бу үзенчәлек күптәннән хас булса, авыл һәм кечерәк шәһәр балалары арасында бу проблема чагыштырмача яңа барлыкка килде.

Безнең тикшеренүнең максаты – хәзерге татар балалары сөйләмендә икетеллелек нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзенчәлекләрне анализлау. Тикшеренү өчен без Мөслим төбәгендә яшәүче 6–13 яшьтәге алты баланың сөйләмен (икесе – малай, дүртесе – кыз) алдык. Әлеге балаларның гадәти көнкүрештәге сөйләмен аудиоязмаларга тупладык һәм җыелган материалларны тикшереп, анализлап без түбәндәге үзенчәлекләрне ачыкладык.

Беренче чиратта, балаларның барысы да сөйләмнәрендә рус сүзләрен үзгәртмичә, әзер килеш куллана. Әлеге күренеш барлык яшьтәге информантлар сөйләмендә да чагыла, мәсәлән, *Нигә* ***именно*** *мин чыгарга тиеш?* (13 яшь); *Хәзер мин,* ***например,*** *әнинең теелфоныннан әйбер карыйм* (7 яшь). Кайбер җөмләләрне алар, гомумән, рус телендә генә әйтәләр: *Я не умею, просто бывает так, что научилась* (9 яшь); ***Да, понятно, понятно*** (6 яшь).

Күпчелек очракта хаталар нәкъ менә рус теленнән әзер килеш кергән сүзләрдәге кушымчаларга бәйле. Мәсәлән, балалар сөйләмнәрендә рус телендәге сыйфатлар кулланыла, әмма аларда род төрләнеше сакланмый, бәлки барысы да диярлек мужской родта бирелә. Моңа мисал булып информантларның сөйләменнән әлеге репликаларны китерә алабыз: ***Зелёный*** *белән и* ***ещё красный*** *төсләрне* (6 яшь); *Ну, например,* ***домашнийларны*** (контекстта *домашнее животное*)*; Майнкрафт –* ***логичный*** *уен* (рус телендә: ***логичная*** *игра*) (7 яшь).

Бу хата сыйфат сүз төркеменә караган сүзләргә генә кагылмый. Балаларның шулай ук рус телендәге тышкы формасы белән сыйфатка охшаган исемнәрне дә (мәсәлән, животное, мороженое, существительное һ. б.) мужской родта куллануга игътибар иттек: *Синең нинди* ***животный*** *самый любимый?* (7 яшь).

Тагын бер үзенчәлек: балалалар әзер килеш кергән рус сүзләрен татар теленә хас юллар белән үзгәртәләр, мәсәлән, рус фигыльләренә татар телендәге ярдәмче фигыльләрне кушып сөйлиләр: *Без күбрәк качелида* ***качаться итәбез*** (9 яшь); *Әни, кулың* ***мешать итә!*** (6 яшь); *Удочкага морковка* ***привязать итсәң*** 〈...〉 (7 яшь). Бу күренеш шулай ук исемнәрдә, аларга татар аффиксларын өстәп, килеш, тартым һ.б. белән төрләндерүдә дә чагыла. Мондый үзенчәлекне барлык информант сөйләмендә таптык: *Без күбрәк* ***качелида*** *качаться итәбез* (9 яшь); *Аны* ***розовыйга*** *буярга кирәк* (6 яшь); *Обычно гуляем,* ***самокатта*** *катаемся* (9 яшь); ***Коровалар***

*пшеница ашыйлар.; Привязать итсән **свиньяга**⟨...⟩; **Понида** йорган бар.; Бу **выходнойлардамы**?* (7 яшь).

Рус сүзләрен куллану белән бәйле янә бер үзенчәлеккә тукталыйк. Без тикшергән балалар сөйләмендә кайбер сүзләр рус телендәге иркәләү-кечерәйтү формасында әйтелә: ***Огурчикны** буйыйм* (6 яшь); *Чучкага седло куйсаң, **удочкага морковка** привязать итсәң ⟨...⟩; **Цыплёнок** ошый миңа, ещё **овечка*** (7 яшь).

Балаларның күбесе сөйләмдә ясала торган паузаларда *ну* ымлыгын еш кулланалар: ***Ну**, кыяр и помидор и всё* (9 яшь); ***Ну**, как, кара ничек булды.*; ***Ну**, например, домашнийларны* (7 яшь); ***Ну**, Мөслимдә рәхәтрәк* (13 яшь); ***Ну**, икенче класста дүрт кеше, ә дүртенче класста дүрт кеше укый* (9 яшь); ***Ну**, белмим* (6 яшь). Шулай ук рус сүзе *просто* шактый күп кулланыла: ***Просто** кисәбез дә и всё бетте* (9 яшь); *Әни, мин просто алмаларны буяп бетерим әле!* (6 яшь). Моның сәбәпләреннән берсе булып, безнең фикеребезчә, татар телендә бу сүзләрне алыштырырлык кыска, кулланырга уңайлы лексик берәмлек булмауны билгеләргә кирәк.

Без игътибар иткән бер кызыклы күренеш: татар һәм рус мәктәпләрендә укыган балаларның сөйләмендә аерма сизелә. Без моны дәрес исемнәрен атаганда күрдек. Мәсәлән, 9 яшьлек татар мәктәбендә укыган кыз менә ничек әйтә: ***Рус теле,** инглиз теле, математика, әйләнә-тирә* (9 яшь). Ә рус мәктәбендә укыган информант: *Математика, **русский,** физкультура* (13 яшь). Бу, беренче чиратта, татар мәктәпләрендә туган тел аралашу чарасы гына булып тормый, уку-укыту процессының да нигезе булып торганлыгын раслый. Шуңа бәйле татар мәктәпләрендә укучы балаларның әйләнә-тирә мохите татар теле белән чолганып алынганлыктан, аның тәэсире зур.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, билингваль даирәдә туып үскән татар балаларының сөйләме әдәби телдән беркадәр аерыла. Аларның сөйләм телендә варваризмнар еш кулланыла, төрле сүзформалар барлыкка килә, шулай ук синтаксик конструкцияләрдә үзгәрешләр сизелә. Бала сөйләмендә бу хаталарның күләме, әлбәттә, яшәү җиренә, нинди мәктәптә белем алуына, тирәлектәге кешеләргә турыдан-туры бәйле.

**Әдәбият**

1. Галиуллина Г.Р. Икетеллелек шартларында татар гаиләсендә туган тел кулланылышының кайбер үенчәлекләре // Правовые основы функционирования государственных и региональных языков в условиях дву- и многоязычия. – Казань: ИЯЛИ, 2019. – С. 57–60.

2. Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар сөйләм телендә лексик интерференция күренеше // Tatarica. 2018. – № 1 (10). – Б. 22–35.

3. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – Т. II. – 392 б.

4. Словарь социолингвистических терминов. – М.: Ин-т ин. языков, 2006. – 312 с.

ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ АТ ОБРАЗЫ

*Хәбибуллина А., Казан, 11 нче татар гимназиясе, X сыйныф*
*Җит. – З.М. Хафизова*

**Акыллы кеше мәкальсез сөйләмәс**

Ат образының кулланылышын анализлау өчен, татар халык иҗатының бер төре булган мәкальләрне сайладык. Беренчедән, мәкальләр халык тормышының уртак бер кагыйдәле, уртак бер гореф-гадәтле булуына һәм уртак бер рухта саклануына нык кына ярдәм иткән, икенчедән, мәкальләр фольклор әсәрләренең төзелеше ягыннан иң кыскасы, ә эчтәлеге белән зур әсәрләргә сыярлык байлыгы бар.

Ә нәрсә соң ул мәкаль? “Мәкаль” сүзе безгә гарәп теленнән кергән. “Урынлы әйтелгән сүз” мәгънәсен аңлата. “Мәкаль сакалдан олырак”, – диләр. “Сакал” сүзе бу очракта “борынгы” мәгънәсендә килә. Димәк, мәкаль яшь ягыннан зуррак булып чыга.

Татар телендә, башка телләрдәге кебек, халыкның тормыш тәҗрибәсе нигезендә туган, тирән мәгънәле фикер белдергән һәм күчерелмә мәгънәдә йөри торган сәнгатьчә гыйбарәләр, канатлы сүзләр, фразеологик тәгъбирләр бик күп. Аларны хикмәтле сүзләр дип тә йөртәләр.

1. **Алмачуар.** Г. Ибраһимовның “Алмачуар” хикәясендә чабышкы атның кушаматы. Аксыл таплары булган җирән яки күк ат төсе.

“Закирларга ике алмачуар чабышкының анасын карынында бер колыны белән бүләк итәләр. Бурлы бия колынлый. Бу колын да сөякле булачак. Төсе алмачуарга әйләнәчәк. Сабан туе җитә. Данлыклы чабышкылар җыела. Хәлиткеч чабыш кызу була. Ә шулай да Алмачуар җиңә. Сабан туеның икенче көнендә Алмачуар үлә.

2. **Нәтиҗә.** ***“Алмачуар” сүзе*** уртаклык исемгә әйләнеп, ***йөгерек ат, җитез машина*** турында шаярып, яратып әйткәндә, я көрәш алдынгыларын, яу батырларын, я поэтик илһам символын белдергәндә кулланыла.

3. **Троя аты. Данайлылар бүләге.** Тәгъбирләр Троя сугышы турында грек риваятьләреннән барлыкка килә. Греклар Трояны 10 ел буена камап торалар һәм аны хәйлә белән алалар. Греклар, Трояны камаудан туктап, шәһәр стенасы янында зур агач ат калдыралар. Бу ат эчендә коралланган сугышчылар була. Троялылар атны шәһәргә кертәләр. Төнлә сугышчылар ат эченнән чыгалар да, капканы ачып, әйләнеп килгән сугышчы отрядларны кертәләр.Троя җимерелә.

**Нәтиҗә.** ***“Троя аты”*** яшерен, мәкерле уй мәгънәсендә кулланыла. “Данайлылар бүләге” – бүләкне алучыга үлем алып килә – тәгъбирнең мәгънәсе шулай.

4. **Төпкә җигелеп тарту.**

Атны төпкә җигү, тәртә арасына кертеп җигү. Атны парлап җиккәндә, берсе төпкә җигелә, икенчесе мичәүгә. Өчләп җиккәндә, берсе – төпкә, икесе ике якка – мичәүгә.

**Нәтиҗә.** Туры мәгънәдә крестьян лексикасыннан. Күчерелмә мәгънәдә – ярдәмче, көчәю.

Күзәтүләребездән чыгып, шундый нәтиҗәгә килдек: ат сүзе белән бәйле **метафоралар** да бар. Алар сөйләмдә, әдәби әсәрләрдә еш кулланыла.

*"Атка атланып", "Ат саклау", "Ат белән чыпчык куу","Ат җене кагылган", "Ат кебек таза", " Ат казану", "Ат күтәрү".*

**Фразеологизмнарда** да ат сүзе кулланыла. **Атландыру** – туры мәгънәсендә атка атланырга ярдәм итү, атка утырту.

**Атказанган** – мәдәният эшлеклесе.

Мәкальләрдә ат образының кулланылышын анализлагач, кулланылыш даирәсеннән чыгып, без аларны төркемләдек.

**1. Кешене хезмәт бизи (Хезмәтне ярату, һөнәр үзләштерү, уйлап һәм киңәшләшеп эшләү):**

"*Ат тешеннән билгеле, егет эшеннән билгеле.*"

*"Үзеңнең алама атың кеше чабышкысыннан яхшырак".*

**2. Адәмне адәм иткән – әдәп (Әдәплек, тыйнаклык, дуслык, намуслылык, кешелеклелек, батырлык):**

*Ак күңелленең аты армас, туны тузмас.*

*Яхшы күңелленең аты армый, туны тузмый.*

*Ат азгыны тайга иярә.*

*Ат тартмый, солы тарта.*

*Атны чыбыркы белән кума, солы белән ку.*

*Ат аунаган җирдә төк кала.*

**3. Балаларны усаллык белән түгел, җай белән тәрбияләргә кирәк, үскәч алар да лаеклы кешеләр булырлар дигән мәгънә салынган:** *Яшь колынны тиргәмә, үсеп җиткәч ат булыр.*

**4. Гаилә кору, тату яшәү.**

*Ат алсаң, арба кирәк, хатын алсаң, бар да кирәк.*

*Ат алсаң, якыннан ал, хатын алсаң,ерактан ал.*

*Атың начар булса да, хатының яхшы булсын.*

*Аты барның канаты бар, сыеры барның сые бар.*

*Җиккән атың җилдәй булсын.*

Мисаллардан күренгәнчә, мәкальләргә тирән һәм үткен фикерне җыйнак итеп, образлы формада әйтеп бирү хас. Алар сөйләмне матур, тәэсирле итәләр. Борынгы заманнардан ук халык аерым кешеләрнең эшеннән, холык-гадәтеннән гыйбрәт алып яшәгән, билгеле бер нәтиҗә, хөкем чыгарган. Әнә шул рәвешле мәкальләр барлыкка килгән. Аларда халыкның тарихы, тормыш-көнкүреше, рухи дөньясы, иҗтимагый-сәяси

карашлары сәнгатьчә чагылыш тапкан. Мәкаль элек-электән халыкның акыллы киңәшчесе, үгет-нәсыйхәт бирүчесе булып килгән. Рухи дөньясы нык үскән бүгенге кешенең күңеле табигыйлеккә, сафлыкка, халык иҗатының гүзәллегенә аеруча көчлерәк тартыла. Шуңа күрә, бүгенге катлаулы заманда, мәкальләрнең тылсымлы көчен киң файдаланырга һәм, алай гына да түгел, аның искиткеч тәрбияви, рухи дәвалау көчен дә кулланырга кирәк. Әби-бабаларыбызның күңел хәзинәләрен югалтмау, буыннан буынга тапшыру – безнең дә бурычыбыз.

## ФАТИХ ӘМИРХАН ПРОЗАСЫНДА КАЗАН ОБРАЗЫ

*Хәбибуллина А.Р., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – фил. фән. канд., доц. Т.Ш. Гыйлаҗев*

Татар мәдәниятенең үзәге булган мәһабәт башкалабыз Казан татар әдәбиятында зур урын били. XIX йөз ахырына кадәр милли әдәбиятта Казанга мәдхияләр дә, шәһәрне уңай һәм тискәре бәяләүләр дә, аны вакыйгалар бара торган урын буларак файдалану да бик еш очрый. Д. Заһидуллина фикеренчә,нәкъ менә XX йөз башында татарлар тупланган, татар мәдәниятенең үзәге булган Казанны нурлы мәркәз итеп караган миф мәйданга чыга [3: 20].

XX гасыр башы – татар әдәбиятының иң гүзәл алтын чоры. Бу вакытта милли әдәбият эстетик һәм фәлсәфи мөмкинлекләрен киңәйтә. Татар мәдәнияте кискен үсеш дәвере кичерә. Әдәбиятта яңару күренеше,татар җәмгыятенең үзәге булган Казанны яхшырту һәм камилләштерү, милләтнең рухын үзгәртү идеясе белән үрелеп бара. Әсәрләрдә милләткә, шул исәптән Казанга бәйле күп кенә мәсьәләләр күтәрелә [2: 7].

Язучылар әсәрләрендә, тәнкыйть итү ысулы белән татар җәмгыятен “йокыдан уятырга” тырыша. Аларда аерым шәхес тәнкыйтьләнми, киресенчә милләт, тирәлек, җәмгыятьтәге мәгълүм бер катламнар игътибар үзәгенә куела. Бу темаларны оста яктыртучы – Фатих Әмирхан.

Талантлы язучы һәм драматург, үткен тәнкыйтьче һәм ялкынлы публицист Фатих Әмирхан 1886 елның 1 гыйнварында Казанның Яңа татар бистәсендә дөньяга килә. Профессиональ тәнкыйтьче Җамал Вәлиди “Әдип Фатих Әмирхан” рецензиясендә мондый фикер әйтә: “Ф.Әмирхан, Г. Камал кебек Казан шәһәренең иске һәм яңа тормышының эчендә кайнап үскән, шуның өчен аны бик яхшы белүче һәм шуны хикәядә, сәхнәдә күрсәтә белүче сирәк кешеләрдән” [1: 184].

Казанда туып үскән Фатих Әмирхан башкаладагы күренешләрне тулы итеп бәяли, шәһәр образын чынлыкка туры китереп сурәтли алган. Ул 1907 елда иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Язучы үзенчәлекле әдәби әсәрләре белән милли сүз сәнгатенең яңгарышын, үсешен һәм камилләшүен билгеләүче шәхесләрнең берсе буларак таныла [1 :242].

Фатих Әмирхан проза әсәрләрендә Казан образына мөрәҗәгать итеп, татар милләтенең искен мәсьәләләрен калкыткан. Тикшерү нәтиҗәсендә Фатих Әмирхан Казан образы аша татар халкын мәдәниләштерү, культурасын, зәвыгын үстерү, мәдәниятләштерү проблемаларын күтәрүен ачыкладык.

Гомеренең күп өлешен Казанда үткәргән әдип мәркәзебезне бик яхшы белгән. Ул әсәрләрендә Казан образын чынлыктагы кебек сурәтләргә омтылган. Беренчедән, проза әсәрләренең каһарманнары безгә таныш булган урамнарда, базарларда, сәнгать учакарында йөриләр. Икенчедән, әсәрнең күпчелек геройлары – безнең яшьтәшләребез. 100 ел элек яшәгән студентларның тормыш-көнкүреше,XX гасыр башында сәяси фикерләре, җәмгятьтәге үзгәрешләр, аларның әдәбият һәм сәнгать турындагы фикерләрен белү шул чор Казан күзаллавыбызны киңәйтте.

Фатих Әмирхан XX йөз башы татар әдәбиятында Казанның, милләтнең яңа дәрәҗәгә чыгуы өчен күп көч куйган. Казанны нәкъ Тукайдагыча нур, тарих, мәгърифәт үзәге итү омтылышы белән төрледән-төрле әсәрләр, мәкаләләр язган.Тикшерелгән әсәрләрдә Казан образы төрлечә чагыла. Автор “Кадерле минутлар”, “Рәхәт көн” хикәяләрендә, “Урталыкта” романында шәһәрне ничек бар шулай реальитеп тасвирласа, “Гарәфә кич төшемдә” хикәясен, “Фәтхулла хәзрәт” повестен модернистик ысул кулланып язган. Анда автор алдагы гасырларда Казанның нинди булачагын шәрехли.

Казан шәһәре пейзажы әсәр геройларның эчке хис-кичерешләре белән бәйле: алар мәхәббәт утында янганда Казанның завод моржалары да гүзәл булып күренә (“Кадерле минутлар”), геройлар кайгы кичергәндә шәһәр караңгы, өметсез итеп тасвирлана (“Гарәфә кич төшемдә”).

Язучы XX гасыр татар әдәбияты өчен төп урынны алып торган татар милләтенең арталыгы мәсьәләсен кискен чагылдыра. Казан шәһәре вәкилләре арасында алдынгы фикер ияләре белән беррәттән иске тормыш вәкилләре дә сурәтләнә. Казан шәһәренең иске фикерле муллаларын, ишаннарын сурәтләп (“Фәтхулла хәзрәт”), язучы белемсезлек мәсьәләләрен чагылдыра.Татар милләтенең, мәдәниятенең начар якларын фаш итеп, тискәре бәяләр биреп, андагы кешеләрнең арталыгын күрсәтеп,автор татар милләтенмәгърифәтлелеккә өнди.Татар хатын-кызларының надан, дорфа булуларының сәбәбе – хатын-кыз ирексезлегендә икәнен ассызыклый (“Рәхәт көн”, “Урталыкта”). Автор рус телен, мәдәниятен, сәнгатен белү татар милләтен таныту өчен кирәк икәнен кат-кат дәлилли (“Урталыкта”, “Фәтхулла хәзрәт”).

Ф. Әмирхан әсрләрендә Казанга бәйле күп кенә мәсьәләләр күтәрелгәнлеге билгеләнде. Бу – надан һәм иске карашлы кешеләр булу, уку йортларының бик акрынлык белән үзгәрүе, милләтнең әдәбият-сәнгатьне әһәмиятле санамавы, матди кыйммәтләрнең рухи кыйммәтләрдән өстен куелуы мәсьәләләре. Әлеге мәсәләләрне чишү өчен

язучы үз геройларын тасвирлаганда, татар милләтенә хас булган сабырлык, юмартлык, мәрхәмәтлелек, намуслылык, малга табынмау, горурлык, тыйнаклык кебек күркәм сыйфатларны аерып чыгара.

Фатих Әмирхан милли фикерләү аша дөньяга яңа караш, фәлсәфәне формалаштырырга тырышып язган. Милләтебезнең яшәешен яхшырту өчен үзенең мөмкинлекләреннән чыгып эш иткән әдибебез, милләтне үстерү эшендә актив катнашкан. Аяклары богаулы килеш тел, милләт өчен тырышып йөргән милләттәшебез безгә үрнәк.Туган телгә куркыныч янаган вакытта, шушындый шәхесләрнең иҗатын өйрәнү – безнең төп бурычыбыз.

**Әдәбият**


1. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: ХХ йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 254 б.
2. Заһидуллина Д.Ф. ХХ гасыр татар әдәбияты тарихы. – Казан: Казан университеты, 2011. – 230 б.
3. Мәгариф. Казан: 2008. – №8. – 97 б.
4. Рухи мирас: эзләнүләр һәм ачышлар. – Казан: ИЯЛИ, 2016. – №. 2. – 300 б.


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КАПКА ЛЕКСЕМАСЫ


*Хәкимова Э., Казан, 177 нче лицей, IX сыйныф*

*Җит. – Л.Ш. Исхакова*


Татар телендә *капка* лексемасы кеше яшәешнең дөньяга карашларын чагылдыручы мөһим тел берәмлеге. Әлеге лексемада татар халкының милли, мәдәни, этнолингвистик, әхлакый мәгълүматы сакланып калган.

Капка лексемасына татар сүзлекләрендә түбәндәге билгеләмәләр бирелгән:

1) Корылма, стена, койма һ.б. урыннарда кереп-чыгып йөрү өчен киң капкачлы ачыклык һәм шул капкачларның үзләре [4: 231];

2) Ворота. *Капка асты* – подворотня. *Капка төбе* – подъезд к воротам [5: 528].

*Капка* сүзе борынгыдан ук килә. Күренекле галим Р. Әхмәтьяновның хезмәтендә *капка* сүзе борынгы төрки фигыль қап- // қапа “закрывать, прикрывать” сүзеннән барлыкка килгән дип белдерелә [1: 90].

Фәнни эшебезне үтәү барышында без татар телендә капка лексемасы белән бәйле *җилкапка, иннек капка, кала капка, урам капкасы, урыс капка, бакча капкасы, ындыр капкасы, зират капкасы, кыр капка* кебек берәмлекләр булуын күрдек. Шуларга аңлатма биреп китик:

*Җилкапка* – такта җитмәү сәбәпле, киртәләрдән оештырып ясалган ачылмалы капка. Капка баганалары өстә киң такта белән тоташтырылган, ләкин капка орчыгы озын булмаган, баганага ике җирдән бәйләп яки коршаулап куелган. Янәшәдәге кече капканың төзелеше дә охшаш булган (диагональ тоташтырмасыз). Ярлы халык хуҗалыгына хас җайланма булган [3: 119].

*Иннек капка* (арата капка) – берсе өстенә берсе куелган аркылы киртә-торыклардан торган капка. Башкача – киртә капка. Аннан кергәндә торыкларны оештырып ясалган булса да, орчыклы, ягъни ачылышлы булган.

*Кала капка (Урыс капкасы)* – Зур такта капка. Урыс капкасы узган гасырның урталарыннан һәр татар йортының капка төбен бизәп торган. Элек урыс капканың зурлыгына, бизәлешенә карап хуҗаның байлыгын да чамалап булган. Хәлле кеше генә мондый капка эшләтә алган. Аның өчен урманнан сайлап юан, төз имән баганалар кайтартылган. Читтән килгән яки авылның иң оста балта осталарына капка ясау, аны түбәләү, агачтан юнып милли орнаментлар белән бизәү өчен күп тырышырга кирәк булган.

*Урам капкасы* – борынгы һәм хәзерге вакытта киң таралыш алган. Тактадан ясалган, бер яки ике орчыктан торган, капка баганасына петля белә тоташтырылган. Татарларда урам капканың ике төре бар: *зур (олы) капка* һәм *кечкенә (бәләкәй) капка*. *Бакча капкасы* – бакчага чыга торган капка. *Ындыр капкасы* – ындырга (бәрәңге бакчасына) чыга торган капка. *Зират капкасы* – зиратка керә торган капка. *Кыр капка (басу капкасы)* – татар авылларында урам чикләрен билгеләү өчен куелган. Әйләндереп алу өчен, гадәттә, горизонталь колгаларга утыртылган киртәләр файдаланылган [2: 151].

*Капка төбе* – капка алды. Капка төбенә халык җыела торган була. Кунакка йөрешү, көтү озату, көтү каршылау, капка төбендә кич утыру – болар барысы да татар халкы өчен хас күренешләр. Элек капка төбендә кич утыру гадәте булган. Көн эчендә булган көнкүреш, гаилә, халык хәле, авылдагы, илдәге хәбәрләре көн тәртибенә салынган, анализланган, хөкем чыгарылган Болар барысы да гадәти хәл булып саналган. Ә җәйге чорда көтү куган чакта, көтүче килгәнен көтеп утырырга, яңгырдан ышыкланырга да шул капка төбе махсус функция үтәгән. Капка төбе иң үзенчәлекле сакраль урын булып санала. Капка төбе тискәре мәгънәви ягын да белдергән, ягъни ул гайбәт сүзенә синоним булып торган.

Күргәнебезчә, капка татар халкында бик күп төрләре сакланып калган. Әлеге төрлелек, бер яктан, татар мәдәни терминнарның күплелеге – халкыбызның югары дәрәҗәдәге мәдәни үсешкә ирешүенең бер чагылышы, икенче яктан, халыкның социаль статусын билгеләгән.

**Әдәбият**


1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.
2. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.
3. Сагитова А.М. Лексика деревянной архитектуры в татарском языке. – Казань: Фикер, 2004. – 160 с.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 510 б.
5. Татарча-русча сүзлек: Т. 1(А-Л). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 726 б.

# МИЛЛИ ГОРУРЛЫК ХИСЕ ТӘРБИЯЛӘҮДӘ ТЕЛЕВИДЕНИЕНЕҢ РОЛЕ

*Хәлилова Н., Алексеевск р-ны, Зур Тигәнәле мәктәбе, IX сыйныф*
*Җит. – Р.Р. Зарипова*

“Милләт язмышы кичектергесез мәсьәләгә әйләнгән заманда татар халкының телен кем саклый, милли узаң формалаштыру юнәлешендә ничек эшләргә, кайдан мәгълүмат тупларга?” дигән сорау белән үземнең чыгышымны башлап җибәрәсем килә.

Үзеңнең татар булуың белән, туган телең, туган җирең, халкың белән горурлану, башка милләт кешесенә тирән хөрмәт хисе – милли үзаң формалашуның мөһим компонентлары булып тора.

Милли үзаңның югары дәрәҗәдәге күрсәткече – ул милли горурлык хисе. Бу хиснең фомалашуында үз милләтеңнең уңай якларын, тарихындагы әһәмиятле вакыйгаларны, әдәбият, сәнгать, сәнәгать һәм башка өлкәләрдәге уңышларны белү зур роль уйный. Шулар арасында үз милләтеңнең күренекле шәхесләре турында белемнәр җыелмасына ия булу гаять зур әһәмияткә ия.

“Татарстан –Яңа гасыр” телеканалы Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче татарларның милли-мәдәни үзаңын үстерү юнәлешендә күпкырлы эш алып бара. Тупланып яшәүче милләттәшләребезне милли, мәдәни, тарихи аң дәрәҗәсендә берләштерә.

Милли үзаң формалаштыруда татар моңына, татар җырына мәхәббәт тәрбияләү, аны пропагандалау да мөһим. “Татарстан- Яңа гсыр” телеканалында чыгучы “Җырлыйк әле!” тапшыруында әдәбият-сәнгать әһелләре иҗаты да яктыртыла. Шунысы игътибарга лаек: тапшырулар берсен-берсе кабатламый. Һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтүче аерым профессия вәкилләренә багышлап әзерләнгән тапшыруларның кыйммәте бәхәссез.

Татар көе, татар җыры, татар моңы – гасырлар дәвамында сакланып килгән бөек мирасыбыз, рухи байлыгыбыз. Шул байлык, моң чишмәсе саекмасын, үссен, тирәнәйсен өчен яшь буынның җыр моңга тартылуы мөһим.

Рәсәйнең төрле төбәкләрендә сибелеп яшәгән татарларны берләштерүче, туплаучы, бәйләүче көч тә ул – җыр. Әлеге тапшыру тележурналистлары шушы хакыйкатьне яхшы аңлап, читтә яшәүче татарларны бергә туплап, махсус сәхифәләр әзерлиләр. Җыр- моң төшенчәсе төрле уен кораллары белән аерылгысыз бәйләнгән. “Җырлыйк әле”не оештыручылар төрле уен коралларында уйнап чыгыш ясаучыларны да тапшыру үзәгенә алалар. Шулай итеп, халкыбызның гасырлардан килгән, курай-кубыз моңнарын, тальянда уйнау осталыгын да пропагандалыйлар.

“Татарстан-Яңа Гасыр” каналында балалар өчен “Тамчы-шоу” программасы 2006 нчы елдан башлап эфирга чыга башлый. Тапшыруның максаты – республикабызда яшәүче сәләтле балаларны ачыклау, берләштерү,

белемгә, китап укуга мәхәббәт уяту, кечкенәдән татар зыялыларын үстерү. Телевизион уенда 6, 7, 8 нче сыйныф укучылары катнаша.

Алар – география, әдәбият, сәнгать, татар мәдәнияте һәм тарихы буенча белемнәрен күрсәтергә тиеш. Тамчыдан күлләр хасил булган кебек, милли үзаң төшенчәсе дә балачактан бала күңеленә сеңдерелергә тиеш. Шул очракта гына, үз милләтенә лаек булган, аны зурларлык, дөньякүләм дәрәҗәгә чыгарырлык шәхесләр тәрбияләргә мөмкин. Бу уңайдан заманча технологияләр белән коралланган телевизион тапшыруларның роле бәхәссез. Алар безгә-бала күңеленә тизрәк тә, тирәнрәк тә барып җитә.

Бу уенда безнең мәктәп командасы да бик теләп катнашты. Кукмара районы командасы белән көч сынашып, җиңү яуладык. Телевидениедә булу, яңа дуслар табу безнең күңелендә искиткеч җылы хисләр калдырды. Уенга әзерлек вакытында без бик күп яңа мәгълүмат алдык. Укучылар рәсем, театр, җыр сәнгате өлкәләрендә дә хәбәрдар булырга милли казанышларны яхшы белергә тиешләр. Әлеге тапшыру аларны зур мәйданга чыгара. Гомумән алганда, “Татарстан-Яңа гасыр” каналының балалар, яшьләр өчен тапшыруларга зур игътибар бирүе мактауга лаек. Алар буыннар чылбырын ялгарга, милли горурлык хисен тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Балалар бакчасына йөрүчеләр “Күчтәнәч” тапшыруыннан күп нәрсәгә өйрәнә ала. Дәү әни, дәү әти белән бала арасындагы җылы мөнәсәбәт, өлкән буынның балалар тәрбияләүдәге акыл хәзинәсе балачактан ук яшь буын күңеленә сеңдерелә. Әлеге тапшыру кысаларында яңгыраган балалр җырлары, халык әкиятләре – милләт киләчәген тәрбияләү чарасы. Туган телгә мәхәббәт тә уен формасында әкият геройлары аша бала күңеленә языла.

“Яшьләр тукталышы” – яшьләр өчен мәгълүмати күңел ачу тапшыруы. Милли узаң формалашу заман белән бергә атлаганда, үткән белән бүгенге бәйләнешне саклаганда гына нык була. “Яшьләр тукталышы” заманча музыка юнәлешендә иҗат итүче җырчылар, җәмгыять тормышының төрле өлкәләрендә сизелерлек уңышларга, танылуга ирешкән татар яшьләре белән таныштыра.

Без бу хезмәтебездә “Яңа гасыр” телевидениесенең музыкаль, күңел ачу жарындагы тапшыруларында милли узаң тәрбияләү мәсьәләлерен анализладык. Этномәдәни үсешнең күп факторлары арасыннан телевидение универсаль киң колачлы, комплекслы булуы, оператив эшчәнлеге белән аерылып тора. Ул милли узаң формалаштыруда зур роль уйный.

Милли узаң формалаштыру юнәлешендә “Яңа гасыр” телевидениесының төп функцияләре: милли телне актив куллану; рухи мәнфәгатьләрне канәгатьләндерү; аң-белем, мәгариф, тәрбия тарату; татар халкы өчен мөһим булган сәяси, икътисади, мәдәни мәгълүматны тарату; төрле регион һәм илләрдә яшәүче татарлар белән даими элемтә булдыру;

татар халкы һәм Татарстан республикасы мәдәнияте белән багланышлар өчен шартлар тудыру.

Милли узаң формалаштыруда телевидениенең мөһим урын тотуы түбәндәге критерийлар белән билгеләнә: телевидение милләтне төзүдә йогынты ясый; татар милли яшәешен саклауда һәм үстерүдә әһәмиятле фактор булып тора; күпмилләтле дәүләттә этномәдәни балансны тота; төп максатка ирешүдә тарихи этнорегиональ фикер йөртү формалаштыра; татар халкының яшәү рәвешен, мәдәниятен, тарихын, традициясен, символларын, кыйммәтләрен пропагандалый. Россия күләмендә, аеруча татарлар яшәгән регионнарда, татар халкының социаль, рухи тормышы, тарихы, мәдәнияте хакында гадел мәгълүматлар җиткерә.

## АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ СУРӘТЛӘНГӘН ДӨНЬЯ

*Хөсәенова Р., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – фил. фән. канд., доц. Г.Р. Гайнуллина*

Хикәя ул – катлаулы булмаган вакыйгаларны, күп очракта тормыш-көнкүрешнең бер эпизодын, кеше характерының, психологиясенең бер сыйфатын, чалымын сурәтләгән кечкенә күләмле жанр төре. Заман хикәясендә психологизм, фәлсәфи гомумиләштерүләргә алып килү, эмоциональлек, символлар теле белән эшләү кебек татар әдәбияты өчен традицион алымнарның яңа мөмкинлекләре күзәтелә.

Без моны хәзерге әдәбиятта традицион татар хикәясен үстерүдә үз сукмагын тапкан, лирик-эмоциональ дулкынны дәвам иттерүче язучыларның берсе Айгөл Әхмәтгалиева иҗатында күрә алабыз. А. Әхмәтгалиева әдәбият мәйданына XXI гасырның башында килеп кергән яшь әдибә. Аның әсәрләрендә күпмедер дәрәҗәдә XX гасырның икенче яртысында иҗат иткән авторлар тарафыннан күтәрелгән темалар да очрый. Табигатьне саклау, авылның бетүе, кеше холкының кырыслануы, эчүчелек, эшсезлек, ятимлек, тормышның үзгәрүе кебек мәсьәләләр авыл яшәешен прозада чагылдыручы язучылар иҗатында кат-кат күтәрелгән.

Айгөл Әхмәтгалиева әсәрләре беренче тапкыр укуда ук тормышчан, гади, аңлаешлы телдә язылуы белән аерылып торалар һәм үзләренә җәлеп итәләр. Чөнки әсәрнең беренче битеннән үк геройлар бн шул дөньяга чумасың, алда нәрсә булачагын көтеп, тизрәк беләсе килеп, әсәрне укып бетерергә ашыгасың. Шундыйлардан булып “Таң чыкларын җил үбә” һәм “Давыл” дип исемләнгән хикәяләре тора.

“Таң чыкларын җил үбә” хикәясен укый башлауга ук ниндидер бер тынычлык, сагыш тоясың. Чөнки хикәя догадан һәм аш үткәрүдән башланып китә. Ләкин инде алга таба бик күп вакыйгалар буласын аңлап аласың: кешеләрнең “...аш чыгарырга кирәк дип, тыз-быз чабыша...” [1: 27] башлаулары фикеребезне шуңа юнәлтә. Чынлап та, килен кешенең ашка

килгән кунакларны исемләп кыставыннан, төп герой – Гөлчирәнең таныш исем ишетеп алуыннан, аның уткәннәренә, яшьлек елларына, үкенечле язмышына әйләнеп кайтабыз. Сюжет сызыгы яшьләрнең, Гөлчирә белән Әнвәрнең, мәхәббәт тарихыннан башланып китә. Ләкин аларның сукмаклары өйләнешмичә дә төрле якка аерыла. 17 яшьлек кыз үзе алмаган әйберне дә, ялгыш әнисен гаепләмәсеннәр дип, чатнап торган тавыш белән “...мин алып кайттым арышны” [1: 28] дип, курыкмыйча, батырларча гаепне үз өстенә ала һәм аны бригадир караклыкта гаепләп, 5 елга сөргенгә җибәрә. Гөлчирә артыннан ук, Әнвәрне дә шундый ук язмыш көтә. Бригадир Хәйдәр үз өстеннән төшергән гаепне Әнвәр үз өстенә ала. Гөлчирәсез калгач, җир читенә дә китәргә әзер була ул.

Элеккеге заманның аянычлы вакытларын, ачы, авыр язмышларын күзәтәбез без бу хикәядә. Язмыш геройларны ничек кенә сынамый. Ачлык, сугыш еллары вакыты булуына өстәп, чәчәк кебек яшьлек елларыннан, саф мәхәббәтләреннән дә мәхрүм булалар. Бары тик бер өмет – кайчан да булса күрешәчәкләре генә яшәтә аларны. Нинди генә яшь булсалар да, бер эштән дә куркып тормаганнар, әниләренә, туганнарына хөрмәт белән караганнар, алар өчен утка да, суга да керергә әзер булганнар, үзләрен дә корбан иткәннәр. Һәм ничә дистә ел вакыт үткәннән соң, алар кабат күрештеләр. “Өлешеңә дигән бер тамчы бәхет калган икән – ул балдан татлырак, язмышлардан ачырак, гомерләрдән озынрак” [1: 31] була икән шул.

“Давыл” дип аталган хикәянең исеменә карап кына аның нәрсә турында баруын күзалласак, без дөрес фикер йөртмәс идек. Чөнки әлеге сүз бары тик символик мәгънәгә ия булып тора. Һәм хикәяне укый башлагач сүзнең бөтенләй дә башка нәрсә турында баруын аңлап алабыз.

Хикәянең сюжет линиясы кояшның чыгасы килмәвен күрсәтүдән башланып китә. Аның кечкенә итеп чагыштырылуы да безне бик үк шатлыклы эчтәлек көтмәвенә әзерли шикелле. Яисә алда буласы хәлләрдән хәтта кояш та оялган кебек.

Әлеге әсәрнең эчтәлеге үткән заман һәм хәзерге заман кешеләрен чагыштырудан гыйбарәт. Хикәядә әти-әни һәм балалар аерып күрсәтелә. Малайлары йөргән кызын таныштырырга дип алып кайткач та, ана кешенең күңеленә ятып бетми ул кыз. Чөнки чын татарча тәрбияләнмәгән була: булышырга да атлыгып тормый, киенүләреннән дә күрергә була. Уллары “безгә урынны бергә генә җәй, минем бүлмәгә” [2: 168] дигәч тә әнисе коелып төшә. Алай тәрбияләнмәгән булалар шул алар, хәтта яшь чакларында бергә кочаклашырга да ояла торган булганнар. Балаларына карап, күңеле белән үзләренең яшь чакларына кайтып килә Әлфинә, үзләренең башкача булуларын исенә төшерә. Тик малайларының гына “замана шаукымына ияреп, тормыш коруга бармак аша каравына” [2: 176] күңеле китә Әлфинәнең. Автор шушы хикәя аркылы яшьләрнең замана

агымына кереп китү проблемаларын күтәрә. Әсәрдә төп геройны – ана кешене борчыган уйлар дип китереп күрсәтеп, үзен борчыган сорауларны алгы планга чыгара: “Хәзерге заманның бар нәрсәне рәттән кырып-җимереп килгән давылы табигать зилзиләсеннән күпкә көчлерәк микәнни соң?”, “Балаларны ул афәттән сакларга ата-ананыңда көче җитмәсә, тора-бара кая тәгәрәр бу дөнья?” [2: 176]. Хикәянең ахыры да башы башланган кебек табигатьне сурәтләү белән тәмамлана: “Урам тын. Һәркем үз дөньясына кереп бикләнгән. Бар тарафтан куркыныч бушлык карап тора сыман” [2: 176]. Әйе чынлап та, ана күңелен бушлык биләп алды, ул алда нәрсә буласын белми, улының язмышы өчен борчыла. Ләкин хәзерге заман балаларына артык сүз дә әйтеп булмый, һәркемнең дөньяга үз карашы шул... Кояш хикәя башында да чыгасы килмичә генә чыкты һәм хикәя ахырында да “...бик каты оялгандай, бит алмасына ут капкандай тау башындагы биек наратлар артына кереп качарга җыена иде...” [2: 176].

Язучы Айгөл Әхмәтгалиева татар әдипләре арасында актив иҗатчылардан санала. Ул бүгенге җәмгыятьнең актуаль мәсьәләләрен күтәрә, аларны үткән белән бәйләп бүгенге көн яссылыгында күрсәтә. Хикәя жанрында үзеннән элгәреге әдипләрнең осталыгын дәвам итүче язучы югары сәнгать дәрәҗәсендәге әсәрләр иҗат итүгә ирешә бара.

**Әдәбият**

Әхмәтгалиева А.Г. Таң чыкларын җил үбә // Идел. – 2019. – №2. – Б. 27–31.
Әхмәтгалиева А.Г. Давыл. – Казан: Татар. кит. нәшир., 2016. – Б.164–176.

## ТАТАР ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕНДӘ ТЕКСТ ТЕОРИЯСЕН ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫ

*Хөсәенова Э., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Х.Х. Кузьмина*

XX гасырда төрки һәм татар лингвистикасында да текст теориясе мөстәкыйль тармак буларак формалаша. Текст мәсьәләсенә бәйле фикерләр гасыр башында ук Һади Максуди, Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди, Гыйбад Алпаров кебек галимнәрнең синтаксисны укытуга багышланган күпсанлы хезмәтләрендә урын алган. Текст төшенчәсе турыдан-туры кулланылмаса да, әлеге хезмәтләрдә ким җөмләләрнең бәйләнеше турында әйтелә, теземгә хас мәгънәви һәм структур үзенчәлекләр күрсәтелә [1: 13].

И.Б. Бәширова, С.Ш. Поварисов, В.Х. Хаков, Ф.С. Сафиуллина, Г.М. Шакирова, М. Шәехов кебек галимнәр дә үзләренең хезмәтләрендә текстка, стилистикага, тел үсешенә, әдәби әсәрне филологик анализлауга бәйле рәвештә текст төшенчәсенә ачыклык кертәләр.

Әйтик, М.З. Зәкиев текстны «Өйрәнү өчен алынган, эчтәлек һәм структур яктан оешкан тоташ сөйләм» дип билгели [3: 44]. «Мондый тоташ сөйләм (ягъни текст) буларак, соңгы елларда зур әсәрләрнең аерым бүлекләре, кыскарак хикәя һәм нәсерләр, аерым мәкаләләр, эш

кәгазьләреннән гариза, белешмә, ышаныч язуы, беркетмә һ. б. тулысынча алыналар һәм текст дип йөртеләләр. Шуның белән бергә мондый тоташ сөйләмнең аерым өлешләре дә текст буларак өйрәнелергә мөмкин. Беренче төр тоташ сөйләмне, гадәттә, макротекст дип, икенче төрен – кыскарагын микротекст дип атау да кабул ителгән» [2: 107]. Текстны шул рәвешле макротекст (тулаем текст) белән микротекстка бүлә, үз хезмәтләрендә төп игътибарны икенче төргә – синтаксик бөтеннәргә юнәлтә. Текст синтаксисын өйрәнүне беренче планга куеп, галим барлык синтаксик категорияләрнең текст эчендә генә тулысынча ачылып беткәнен раслый. Әлеге категорияләр арасыннан автор хәбәрлек белән модальлекне, ким һәм атау җөмләләрне, җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше белән сүз тәртибе проблемасын, теземнәр һәм чит сөйләм төрләренең кулланылашын аерып күрсәтә.

Ф.С. Сафиуллинаның да текст теориясенә багышланган хезмәтләре аерым игътибарга лаек. Галимә «Текст төзелеше» хезмәтендә тел гыйлемендәге текст теориясе казанышлары нигезендә, татар әсәрләренең текст буларак оешу закончалыкларын, текст берәмлекләре һәм алар арасындагы бәйләнешләр, ретроспекция белән проспекция, континуум һәм интеграция кебек текст категорияләре, әсәр башламнары, уртак сөйләм кулланылышын өйрәнеп, мондый нәтиҗәгә килә: «Текст – сөйләмнең аралашудагы иң зур берәмлеге. Текстны барлыкка китерүче билгеләр арасында төгәлләнгәнлек, мәгънәви бөтенлек, композицион-структур оешканлык, текст элементларының үзара тыгыз бәйләнеше, текстның атамасы булу, текстның язма хәлдә булуы шарт. Текстта һәрвакыт нинди дә булса хәбәр (информация) – яңалык була. 3 төрле информация күзәтелә: фактик, концептуаль, текст артындагы хәбәрләр. Алар төрле текстларда төрлечә белдереләләр. Һәрбер текст объектив һәм субъектив модальлек белән характерлана, әмма матур әдәбият әсәрләрендә субъектив модальлек өстенлек итә. Әдәби әсәрләрне өйрәнү текст теориясенә нигезләнгәндә генә кызыклы һәм көтелмәгән нәтиҗәләр бирә» [5: 23].

Публицист, язучы, журналист, галим Илдар Низамов та үзенең хезмәтләрендә сөйләм оештыру өчен кулланылган тел чараларын системага салып өйрәнү омтылышы ясый. Автор «Уем – тел очында» хезмәтендә адресатка, аралашу ниятенә һәм шартларына карап, сөйләмнең мотивларын, лингвистик һәм экстралингвистик чараларын билгели. Шулар нәтиҗәсендә галим сөйләмият фәнен тел гыйлемендә мөстәкыйль тармак итеп бүлеп чыгарырга тәкъдим итә һәм аның предметын, максат-бурычларын, берәмлекләрен аерып күрсәтеп, болай дип яза: «Аның нигезенә кешенең когнитив (танып белү) структуралары (чынбарлыкны аң белән кабул итүе, уйлау-фикерләве, аралашу-аңлашуы, зиһенләве, хәтердә

тотуы, эшләү-хәрәкәт итүе һ. б.) салынып, аларны тикшерү-өйрәнүнең максаты кешенең чынбарлык, яшәеш турында мәгълүмат, белемне ничек кабул итүен, туплавын, эшкәртүен, хәтерләвен, куллануын һ. б. төпле ачыклаудан, ягъни кеше акылының хәрәкәтен, яшәешен бербөтен система итеп күзалларга омтылу тора. Төп категорияләр (лексема, фразема, хәбәрләмә, фикерләмә, ининтонация һ. б.) фикернең, хис-тойгының хәрәкәттәге хәлен өйрәнүгә, шушы юнәлештәге нәтиҗәләрне гамәлгә кертә үк баруга мөмкинлек бирә, димәк, алар турыдан-туры сөйләм оештыруда катнаша» [4: 78].

Галим текст төшенчәсенең ике тармакта да (телдә һәм сөйләмдә) кулланылуын искәртеп, аны тел фәне берәмлеге һәм фикерләмәне белдерә торган чара дип күрсәтә. Аныңча, фикерләмә – сөйләм мотивларына нигезләнеп язылган текст + телдән башка чаралар [4: 79].

И.М. Низамов текстның төп сыйфаты дип, тәмамланган фикер бөтенлеген атый. Аныңча, анда тел чаралары фикер бәйләгеч ролен үти, шуңа күрә текст, нигездә, лингвистика берәмлеге. Галим текстның тоташлык сыйфаты һәм тәмамланганлык билгесе дип, башлам, очлам һәм башисемне күрсәтә: «Болар — бәйләгечләр, һәм алар башлыча тел чаралары белән (сүз, сүзтезмә, җөмлә һ. б.) белән белдерелә. Әлбәттә, бу күренешләрне төрле яссылыкта – әсәрнең төзелеш-композициясе өлеше буларак та, укучыга тәэсир итүнең сәнгати-хисси чарасы буларак та һ.б. яктан карарга мөмкин».

Нәтиҗә ясап әйткәндә, текст киң мәгънәгә ия төшенчә, ул төрле яссылыкта өйрәнүне таләп итә. Шуңа күрә дә татар тел белемендә текст теориясен өйрәнү актуаль мәсьәлә буларак хәзерге вакытта да дәвам итә.

**Әдәбият**

1. Гарифуллин В.З. Журналист текстында дәлил. – Казан: Казан ун-ты нәшр.,1996. – 22 б.
2. Зәкиев М.З. Синтаксис һәм пунктуация. – Казан, 1965. – 147 б.
3. Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971.– 192 б.
4. Низамов И.М. Уем – тел очында. Татар сөйләме нигезләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1995. – 287 б.
5. Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 264 б.

## РИЗЫК АТАМАЛАРЫНЫҢ ЙОЛАЛАР БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЕ

*Хөснуллина А., Балык Бистәсе р-ны, Биектау урта мәктәбе, XI сыйныф*
*Җит. – Г.Х. Гарипова*

Татар халкының милли традицияләргә бай ашлар әзерләү осталыгы бик күптәннән килә. Күп гасырларга сузылган тарих дәвамында милли оригиналь ашлар барлыкка килгән, алар үзләренә генә хас сыйфатларны әлегә кадәр саклаганнар. Аларның үзенчәлеге халык тормышының

иҗтимагый-икътисади, табигый шартларына, аның этник тарихына, йола, гореф-гадәтләренә бәйле [2: 7]. Шуларның кайберләрен тулырак карап китик.

*Бала туу* – гаиләдә зур вакыйга. Тормышы икмәккә бай, мул булсын дигәндәй, яшь баланың дөньяга килүе хөрмәтенә *икмәк* пешерелгән. Бала туган көнне ананың һәм баланың саулыгын, хәлен белергә *әлбә* яки *талкан* болгатып алып барганнар. Бүгенге көндә дә бу традиция яши, ләкин бала туган йортка икмәк яисә әлбә түгел, ә бәби бәлеше яки башка төрле ризык алып киләләр.

*Игеннәрне урып-җыеп бетергәч*, анда булышкан кешеләрне олылап, һәркайсына бөтен *икмәк* бүләк иткәннәр.

Менә яшь егет кыен һәм җаваплы *солдат хезмәте*нә китә. Ул, гадәттә, юлга чыкканда *икмәк*не авыз итә. Бу икмәкне солдат туган-үскән йортына яңадан әйләнеп кайтканчы киптереп саклаганнар. Монысы инде егетнең исән-сау әйләнеп кайтуын теләү йөзеннән шулай эшләнә торган булган.

Икмәкне олылау йолалары татар халкы һәм башка халыклар арасында да бик күп. Ике яшь кешенең тормыш юлына аяк басуы, *туй тантанасы икмәк*тән башка узмаган. Яшь киленне каршы алганда аңа бөтен икмәк тоттырып, йомшак мендәргә бастыралар. Икмәктән башка бер генә йола да узмаган. Туган көненнән башлап, күзе йомылганга кадәр икмәк кешенең иң кадерле юлдашы, бәхет, мул тормыш чыганагы, көч билгесе булып тора.

Кода-кодагыйлар беренче тапкыр танышканда, әлбәттә, төенчекләренә яңа гына пешкән *икмәк* төйнәлми калмаган. Ә өйгә килеп кергәч, икмәкне аркылыга кисеп, һәр ике кода тирәли әйләндерелгән һәм аларга ашап карау өчен тәкъдим ителгән. Бу – дуслашу, танышуның беренче йоласы булып саналган.

Егет белән кыз өйләнешкәндә аларны каршылау тантанасында иң элек кулларын бөтен икмәк аркылы кавыштыра торган булганнар. Туй башланыр алдыннан егет белән кызга шул ук икмәктән берәр телем, ә мәҗлестәгеләргә шакмаклап бүлеп биргәннәр. Туй табынына *бал-май, чәкчәк, пәхләвә, кош теле, гөбәдия, талкыш кәләвә* һ.б. куелмый калмаган. Туйга яисә башка берәр тантанага җиләк-җимештән яки балдан *ширбәт* ясаганнар. Элегрәк кияү кеше кәләшнең эти-энисендә айлар буе кунак булган, аның өчен *кияү пилмәне, кияү коймагы, кияү пәрәмәче* пешергәннәр [2: 127].

*Өй (бура) күтәрү йоласы* да игътибарга лаек. Бу вакытта зур казанны тутырып *ботка* әзерләгәннәр. Яңгыр яумыйча интектергән коры җәйләрдә “яңгыр боткасы” пешергәннәр, аны авылдагы бөтен урам халкына авыз иттереп чыкканнар.

Югарыда саналган гореф-гадәтләрнең кайберләре бүген дә яши. Билгеле булганча, туганнарыбызны, дус-ишләребезне, хәтта чит ил

кунакларын да ипи белән каршы алабыз. Моның белән бер-беребезгә исәнлек-саулык, озын гомер телибез.

*Каз өмәләре*н искә төшерик. Анда җыелган кыз-киленнәргә оннан *коймак (атаклы каз коймагы), ярма белән бәлеш* пешерелә.

Крестьян өчен *сыер бозаулаган көн* шатлыгын әйтеп кенә бетерерлек түгел. Ул көнне, әлбәттә, сөткә изеп *күмәч* пешерелә һәм туган-тумачалар чакырылган. Ләкин бу йола бүгенге көндә сакланып калмаган.

*Сабантуй* һәм *җыен* кебек язгы-җәйге бәйрәмнәргә *каклаган каз* белән *казылык* әзерләгәннәр.

*Гаилә йолалары*на килсәк, алары аерым үзенчәлеккә ия. Мәсәлән, кайбер татар гаиләләрендә ураза һәм корбан гаете көннәрендә генә *дучмак* пешерү гадәте бар.

*Кунакка, бәби туена, өй туена* пар бөтен *күмәч, пар бәлеш, как-төш (чәкчәк),* күп итеп пешерелгән *кош теле*, ә соңгы вакытларда *торт* алып бару гадәте яши.

Татар халкының борын-борынгыдан кунакчыл булуы һәркемгә билгеле. Кунакны каршы алса да, үзе барса да ул бервакытта да ризыксыз түгел. Боларның барысы да шул бер фикерне раслый: кая гына барсаң да, ни генә эшләсәң дә һәрвакыт икмәк кирәк [1: 43]. Барлык йола, гореф-гадәт нинди дә булса ризык белән бәйләнгән.

Шулай итеп, ризыклар белән бәйле күп кенә йолалар да, халкыбызның күңел һәм рухи байлыгы буларак, бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткәннәр. Ләкин аш-су йолаларын һәм йола ашларын, аларның атамаларын күбесенчә өлкән буын кешеләре генә хәтерли. Без бары авылларга экспедицияләргә чыгып, информаторларны, ягъни аш-су һәм тел осталарын эзләп табып, нечкәләп сөйләшеп, аерым очракларда теге яки бу ризыкны бергәләп пешереп карап өйрәнеп, аларның белеме, тел байлыгы, хәтере аша гына борынгыдан килгән милли хәзинәләребезне барлап чыгып күз алдына китерә алабыз. Шуның өчен, рухи һәм матди мәдәниятнең бик борынгы бер тармагы булган аш-суларны һәм аларга караган йолаларны, атамаларны өйрәнгәндә, җирле сөйләшләрдәге бүгенге көннәргә килеп җиткән тел байлыгына таянырга тиеш булабыз.

**Әдәбият**


1. Әхмәтҗанов Ю.Ә. Татар халык ашлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 318 б.
2. Баязитова Ф.С. Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. – Казан: Дом печати, 2007. – 480 б.
3. Нурмөхәммәтова Р.С. Татар халкының матди мәдәниятен чагылдырган лексик берәмлекләр буларак азык-төлек атамалары // Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 278 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.
5. Татар теленең этномәдәният сүзлеге: матди мәдәният лексикасы (ризык һәм савыт-саба атамалары) / Төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Ә.Ш. Юсупова Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Г.Н. Хөснуллина. – Казан:

Казан ун-ты нәшр., 2015. – 280 б.

## МЕТОД АНКЕТИРОВАНИЯ, КАК СПОСОБ ВЫЯВЛЕНИЯ ОСВЕДОМЛЕННОСТИ НАСЕЛЕНИЯ О КУЛЬТУРНОМ НАСЛЕДИИ

*Хузиахметова Г., КФУ, магистрант I курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ф.Х. Габдрахманова*

Библиотеки, музеи и другие учреждения культуры являются местом активного распространения и популяризации культуры. С появлением электронных средств связи, электронных книг и каталогов посещаемость таких учреждений заметно снизилась. Человеку проще всего открыть планшет или компьютер, найти нужную информацию или книгу в сети интернет. В учебных заведениях идет активная тенденция внедрения электронных и технических методов преподавания, электронных дневников и различного рода инновации. Популярность массовой культуры, трансляция культуры по совершенно другим образцам, изменение методов поиска и получения информации предполагает то, что заинтересованность современного поколения к истории и к наследию культуры заметно снизилось. Для того, чтобы узнать так ли это, в нашей работе был применен метод анкетирования. Преимущественно, нас интересовали вопросы следующего характера – как общество относится к истории в целом; знает ли оно о деятельности организации ЮНЕСКО; знают ли они, что представляет собой историко-культурное наследие; известно ли им о деятельности Республиканской организации «Возрождение» в этой области; и каким образом связана деятельность библиотек и музеев с возрождением и сохранением культурного наследия.

Исследование было посвящено степени осведомленности молодого поколения об историко-культурном наследии. Охватываемая возрастная категория анкетирования составила от 14 до 30 лет, всего 100 человек. Вопросы к анкете имели историко-культурологический характер, которых можно разделить на первичные вопросы (т. е. те, которые выявляют пол участников и род их деятельности) и вторичные (те, которые непосредственно имеют отношение к нашей теме). В ходе полученных ответов от респондентов нами был проведен анализ, который показал нам следующие результаты: во-первых, интерес к истории в основном выявлен у лиц женского пола, нежели чем у мужского (общее соотношение, примерно 50/20). Во-вторых, процент респондентов, учащихся в школе, мало осведомлено об историко-культурном наследии, а если осведомлено, то через СМИ или от родителей, знакомых и друзей. Это позволяет сделать вывод о том, что в школах недостаточно внимания уделяется изучению этой сферы или она вообще не изучается. По нашему мнению, для того, чтобы человек уважал свою историю и культуру, стремился ее сохранить и приумножить, нужно со школьной скамьи изучать эту сферу и напоминать актуальность сохра-

нения историко-культурного наследия. А вот число респондентов, которое учится в ВУЗе в какой-то степени осведомлено в этой области, это позволяет сделать вывод о том, что университеты уделяют достаточно внимания для преподавания студентам этой сферы. В-третьих, если все респонденты в той или иной степени слышали, а некоторые хорошо знают, об организации ЮНЕСКО, то о Республиканском фонде «Возрождение» мало кто знает в полной мере. Общая сводка данных показывает нам то, что есть процент людей, которые впервые слышат об этом фонде. Показатели, конечно, не так плачевны, но, все же оставляют желать лучшего. Фонд «Возрождение» является основополагающей организацией в области культуры, тогда почему же она не является такой популярной? Это связано с тем, что фонду не была сделана хорошая пиар компания на долгое время. Также, она не так актуальна еще и потому, что в учебных заведениях не имеет важного места в преподавательской деятельности в области историко-культурного наследия. Эта организация, которая имеет колоссальные результаты деятельности за годы ее существования (имеется ввиду то, что фонд добился включения в список Всемирного наследия 2 объекта, расположенного на территории Республики), не принимается во внимание в учебных заведениях и недооценивается. В-четвертых, было выявлено, что посещают библиотеки и музеи преимущественно студенты, учащиеся в ВУЗах, а вот лица школьного возраста и работающие люди ходят в эти учреждения редко и не заинтересованы в проводимых мероприятиях вообще. Активный интерес к мероприятиям, проводимые библиотекой или музеем, проявляют лишь лица, которые часто посещают эти учреждения. В-пятых, несмотря на то, что было выяснено, что многие недостаточно осведомлены о проблемах историко-культурного наследия и о деятельности в этой области государства и общественности, все респонденты осознают важность сохранения, возрождения и приумножения наследия истории и культуры наших предков. Значит, они считают, что культура и история очень важна для нашего цивилизационного развития. Это не может не радовать, ведь сохранение нашей истории и культуры зависит от каждого из нас.

**Литература**


1. Максаковский В.П. Всемирное культурное наследие: Научно-популярное справочное издание / Издательский сервис, 2000. – 416 с.
2. Скачков А.С. Роль ЮНЕСКО в защите всемирного культурного наследия [Электронный ресурс] / URL: https://cyberleninka.ru/article/n/rol-yunesko-v-zaschite-vsemirnogo-kulturnogo-naslediya (дата обрщения: 18.01.2020)
3. Тагиров Э.Р. Сабантуй в локальном и глобальном цивилизационном пространстве: (потенциал идей культуры мира в традиц. праздниках народов планеты) / Э. Р. Тагиров, Д. Р. Шарафутдинов. – Казань: [Центр. оператив. печати], 2004. – 47 с.
4. Татары. – М.: Наука, 2001. – 583 с.

# ПРЕЦЕДЕНТ ИСЕМНӘР ҺӘМ МЕТАФОРА ТЕРМИННАРЫ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Һадиева А., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Г.Р. Галиуллина*

Ономастика фәнендә прецедент исемнәрнең күчерелмә мәгънәдә кулланылышына бәйле төрле терминнар очрый: прецедент исемнең метафорик мәгънәсе, ономастик метафора, прецедент исемнең метафорик кулланылышы һ.б. Мәсәлән, Д.Б. Гудков [2003: 149], Е.А. Нахимова [2007: 207], И.Э. Ратникова [2003 :214], А.Д. Шмелев [2002: 496] кебек галим-тикшеренүчеләр хезмәтләрендә очрыйлар. Кайбер галимнәр метафора белән прецедент исемнәрне, мәсәлән, метафора-символлар [1997: 27] дип атыйлар.

Әдәбият белемендә бер әйбер, эш яки хәл үзара охшашлыгы нигезендә икенче бер әйбер, эш яки хәл атамасы белән алыштырып әйтелсә, метафора хасил була. Метафора – шул ук чагыштыру, ләкин кыскартылган яки яшертен чагыштыру; чагыштыруда ике мөстәкыйль сүз булса, метафорада бер генә сүз, – шул бер сүз охшаш күренешне (сурәтне) дә, исеме шул сүзгә күчерелгән әйберне (күренешне, эш яки хәлне) белдерә [2002: 123].

Журналистикада метафора – (грек. metapfora, тат. күчерү) – күренеш, гамәлне үз исеме белән әйтмичә, икенче сүз белән белдерү чарасы. Аристотель фикеренчә, метафора – чагыштыруның бер төре. Метафорада сөйләм объекты – чагыштырыла торган чара башка сүз белән алыштырыла. Тик барыбер сөйләм объектын күзаллыйбыз [2011: 148].

Прецедент исемнәрнең кулланылышын вакытлы матбугаттан тупланган мисалларда карап үтик: Исхакның бабасы атаклы ат карагы, ул заманның караклар атаманы Шәкүр карак белән элемтәдә булган (Хикмәтуллин С. «Атыңны төнлә йоклаган килеш җигеп алып кайтканмын» // Татарстан яшьләре. – 2018. – 22 март). Уф, сафура бураны булмый калды (Гарипова Ф. Көндәш // Безнең гәҗит. – 2015. – 1 июнь). Хәер, анысы барыбер инде Мамай заманыннан калган булгач... (Гайнанова Л. Габдерәшит кызы күпере // Мәдәни җомга. – 2014. – 4 авг.)

Беренче мисалда кулланылган Шәкүр карак прецедент исемнең тарихы болай:

Шәкүр Рәхимов, яки Шәкүр Карак – 20 гасыр башында эш иткән данлыклы ат карагы, татар риваятьләре каһарманы.1920 еллар башында республика партия органнарына АТССР Зөя өязенең Мәлки волостендагы Гөбенә елгасы буенча урнашкан Чүти авылында яшәүче (Татарстанның хәзерге Кайбыч районы) ат караклары турында шикаятьләр яза башлыйлар. Патша заманнарыннан ук инде бу авыл халкы караклыгы белән дан тоткан була. Караклар башында Шәкүр исемле җәйдак торган, аны авырулар, сугыш, ачлык, үлем дә әлегә урап узган. Шәкүр Рәхимов, яки Шәкүр

Карак – 20 гасыр башында эш иткән данлыклы ат карагы, татар риваятьләре каһарманы. Егерменче гасыр башында бер нәселдән башланган ат караклыгы елдан-ел үсә бара һәм алар йогынтысында Казан һәм Сембер өязе авылларында күпме курку белмәс бандитлар үсеп чыга. Аларның атаманы – араларындагы иң акылысы, кыю Шәкүр. Бу бандитларның шөгыле якын-тирәдәге авылларда вак-төяк урлашулар белән генә чикләнмичә, Россиянең бөтен почмакларында да алып барыла. 1910-1911 елларда Николай патша власте Чүти бандитларын каты кулда тота башлый. Яңа бандитлар барлыкка килүе туктала һәм Шәкүр кебек билгеле булган кешеләр Себергә һәм каторгога озатыла».

Шәкүр карак – биредә күчерелмә мәгънәдә бирелми, сурәтләү чарасы булып килми, яшерен чагыштыру да булмый. Димәк, биредә прецедент сүз метафора булмый. Икенче мисалда, сафура бураны – орышу, талашу мәгънәсен белдерә [2: 210]. Югарыда бирелгән мисалда автор киеренке мөнәсәбәтләрне сафура бураны белән чагыштыра. Безнең фикеребезчә, әлеге мисалны метафорага кертеп була, чөнки күчерелмә мәгънә, охшашлык нигезендә күчерү беренче планга чыга.

Өченче мисалда прецедент исем нигезендә барлыкка килгән Мамай заманыннан калу фразеологизмның мәгънәсе бик иске, күптәнге дигән мәгънәне белдерә. Мамай – Алтын Урданың хәрби һәм дәүләт эшлеклесе. Мамай хан XIV гасырда яшәгән, ә аның исеме бүген еш кына күчерелмә мәгънәдә матбугатта кулланыла. Биредә дә охшашлык нигезендә исемне күчерү төп рольне уйный.

Әлбәттә, кайбер прецедент исемнәр метафорага якын була ала, алар метафора составына керә, әмма шулай да прецедент исемнәр метафора була алмый, дип уйлыйбыз. Гомумән, кайбер галимнәр прецедент исемнәр, метафорага якын тормыйлар дигән фикердә. «Таза кешене Фальстаф, ә көнче кешене Отелло дип атау, метафора куллану дигән сүз түгел әле», дип яза Н.Д. Арутюнова [1: 20].

Безнең уйлавыбызча, журналистика кулланылган прецедент исемнәр метафора буларак кулланылмый, автор исемнәрнең үзенә басым ясый. Биредә яшерен чагыштыру юк. Прецедент исемнәр сүзне конкрет әйтә. Мәсәлән: М .Горький «свинцовые мерзости» дигән төшенчәне әдәбият тарихына Тукай чорында ук инде керткән иде (Хәбетдинова М. Тукайны пычрату кемгә кирәк? // Ватаным Татарстан. – 2018. – 26 март). Тукай чоры, белүебезчә, XX гасыр башы.

Нәтиҗәдә, халык Хуҗа Насретдинның ач торырга өйрәнеп җитә дигәндә генә үлеп киткән ишәге хәленә калмасмы (Хуҗиева Г. Хуҗа Насретдин ишәге хәлендә // Татарстан яшьләре. – 2015. – 7 апр.). Биредә кешенең ач торуы ач торган Хуҗа Насретдин ишәгенә ишарә ясала, әмма биредә бу сурәтләү чарасы түгел, ә прецедент исем була. Күп төрки

халыкларның фольклор персонажы Хуҗа Насретдинның фразеологизмнар һәм мәкальләр составында – Хуҗа Насретдин ишәге, Хуҗа Насретдин кошы, Хуҗа Насретдин әйтмешли һәм башкалар белән очрашуы да аны татар халкы арасында танылуы турында сөйли [5: 119].

Шулай итеп, без метафора һәм прецедент исемнәрне бердәй кабул итә алмыйбыз, чөнки метафора – ул сурәтләү чарасы, ә прецедент исем телнең бүтән прецедентлы феноменнары белән бәйләнештә тора.

**Әдәбият**

1. Арутюнова, Н.Д. Метафора и дискурс // Теория метафоры: Сборник. – М.: Прогресс, 1990. – С. 5–32.

2. Галиуллина Г.Р. Прецедентные имена в современном татарском языке // Ученые записки Крымского федерального университета имени В.И. Вернадского. Серия «Филологические науки». Том 2 (68), № 3. 2016. – С. 117–121.

3. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

4. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: мәгариф, 2001. – 335 б.

5. Фәттахов И.Ф. Әдәбият теориясе нигезләре: журналистика факультеты студентлары өчен. – Казан: К(И)ФУ нәшр., 2011. – 210 б.

## ОСОБЕННОСТИ РУССКОЙ И КИТАЙСКОЙ КАРТИНЫ МИРА

*Чан Ваньцзюнь, КФУ, магистрант III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Т.А. Корнеева*

Изучение этикетных рече-поведенческих стратегий и тактик, говорящих на русском и китайском языках требует глубокого исследования особенностей национальной ментальности, отражающих философские, морально-нравственные, этические и аксиологические воззрения народов. Особенно это актуально, если речь идёт о культурно-понятийной парадигме «Восток-Запад». Так, к характерным чертам западной культуры относят рационализм, прагматизм, антропоцентризм, анти-традиционализм, а особенностями восточной культуры считаются природоцентризм, бережное отношение к традициям, духовно-душевную гармонию («умное сердце»).

Этикетные нормы поведения определяются мышлением и отражают чёткую систему ценностей России и Китая.

Географические особенности, жизнь в тяжёлых погодных условиях, пространственная протяжённость явились причиной беззлобия, миролюбия в русском менталитете. Многие русские национальные черты имеют корни в религиозном видении мира. На православии основан русский национальный дух, национальная этика и нравственность. Это проявляется во взаимопомощи и заботе, так и в навязчивости, чрезмерном любопытстве. Носители русского языка на первый план ставят понятие соучастия. Соучастие и причастность имеют отношение к православной культуре, ключевым понятием которой признается явление соборности. Категорию со-

борности В.В.Колесов считает одним из главных проявлений русской ментальности, понимая соборность как некую целостность, которая определяет все особенности русского менталитета [1:135].

Китайская культурная традиция оказывает влияние на способ мышления китайцев (и приводит к контрасту с западной моделью). Такие ученые, как Пен и Нибсет [3: 744], отмечают, что китайцы привыкли воспринимать противоречия диалектически, считают, что все содержит в себе противоречия. «Лу-ньюй» Конфуция, «Дао Дэ Цзин» ЛаоЦзы, написанные более двух тысяч лет назад, и ряд других древних книг до сих пор оказывают влияние на мышление и поведение китайцев.

Диалектическое мышление, отраженное в конфуцианстве, буддизме и даосизме, основных течениях традиционной культуры, сформировало традиционный китайский менталитет. Основными особенностями такого менталитета являются противоречивость, целостность и практичность. Традиционная китайская философия признает существование всеобщего базового противоречия в качестве основы бытия, стремится в условиях взаимодействия противоречий познать и охватить единство и закономерность вселенной, познать единство и закономерность добродетельной жизни, неба и человечества.

Традиционный китайский менталитет имеет следующие характеристики:

1. Сосредоточенность на упорядоченности. В отношениях между человеком и природой китайский традиционный образ мышления сосредоточивает внимание на «единстве Неба и Человека», при этом не только рассматривает весь внешний естественный мир как одно целое, но и воспринимает все человеческое общество как взаимодействие с внешним естественным миром.

2. Тенденция к реалистическому образу мышления. Даосизм уделяет внимание способу самозащиты, закону успеха и искусству управления людьми, а конфуцианство – это, прежде всего, учение о стратегии управления господствующего класса.

3. Эклектический образ мышления. В рамках традиционного мышления китайцы стремятся гармонизировать различные противоречивые философские представления.

4. Диалектический образ мышления. Китайцы стремятся к гармонии в каждом человеке, к мировой гармонии.

В традиционной китайской культуре конфуцианское подчеркивает необходимость для определенного человека послушания, самоотречения, соблюдения ритуала, чтобы найти свое место в жизни. Хотя для достижения этой цели необходимо, чтобы люди сами неуклонно стремились вперёд и имели твёрдую несгибаемую волю, но личность была сильно ослаблена, даже утрачена, поэтому наблюдается отсутствие сильной индивиду-

альности и сильных качеств личности. Даосизм подразумевает обретение спокойствия за счет гармонии с природой. Согласно буддийским учениям, окончательное освобождение людей заключено в пепле, полностью лишенном человеческой жизни нирване в обмен на духовное утешение.

По мнению китайских мыслителей, менталитет (образ мышления) Китая обладает женским началом и качеством художника, стремящегося найти хорошее. Китайские политические моральные принципы основаны на этике и нравственности, физической и психической подготовке, гармонии в государстве. В политике стремление к умиротворению государства приводит к возникновению мышления «большого единства», стремлению к однородности. Сосредоточенность на политической этике неизбежно приводит к потере интереса к изучению природы, поэтому существует аналогия между природой и человеческой деятельностью, которая приводит к осознанию всеобщего единства, а вместе с ним и к решению проблем в политической, социальной и этической сферах жизни.

**Литература**

1. Колесов В.В. «Жизнь происходит от слова...». – СПб.: Златоуст, 1999. – 369 с.

2. Шелковая Н.В. Культуры Запада и Востока // URL: http://nowimir.ru/DATA/040029.htm (дата обращения 18.01.2020).

3. Peng K., Nisbett R. E. Culture, dialectics, and reasoning about contradiction // American Psychologist, 54(9), 1999. – С. 741–754. // URL:https://psycnet.apa.org/record/1999-11125-001 (дата обращения 18.01.2020).

## АРХЕТИПИЧЕСКИЕ ОППОЗИЦИИ В ИНТЕРНЕТ-ИГРЕ В АНТИФРАЗЫ

*Чэнь Ясин, КФУ, аспирант*

*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. Т.Г. Бочина*

В последние годы явление «загадка» приобретает более широкий диапазон исследования, она представляет собой стабильный объект научных изысканий лингвокультурологии, этнолингвистики, фольклористики и др. гуманитарных наук. Популярность данного явления в современной исследовательской сфере объясняется тем, что в текстах загадок сохраняется общая и ценная информация, которая отражает особенности мировидения, истории и национальной культуры данного народа.

Чрезмерной популярностью на страницах Рунета пользуется лингвистическая игра в загадки под названием «Антифразы». Правила игры в антифразы состоят в том, что одни участники игры заменяют все компоненты прецедентных единиц на антонимы или контрастные по смыслу слова с целью создания относительно осмысленной фразы, а другие участники должны отгадать исходные прототипы: ***Чужой чужого*** *слышит близко* (***Свой своякa*** *видит издалека); Ночью с* ***водой*** *найдешь (Днем с* ***огнем*** *не сыщешь)* и др.

В современной лингвистике была многократно отмечена структурная и функциональная близость загадки и пословицы. Рассмотрение зага-

док-перевертышей показывает, что «в антифразах не просто используется тот же универсальный лингвокогнитивный принцип контраста, что и в классических паремиях, но и наблюдается преемственность и в типах лексических средств выражения данного принципа, и в использовании ряда традиционных для русской лингвокультуры оппозиций» [1: 336].

Исследуя смысловую структуру пословичных изречений, Г. Л. Пермяков выделил ряд инвариантных пар, лежащих в основе предметных тематических групп пословиц, исследователь отмечает, что «практически почти все пословичные изречения (которых, как известно, огромное множество) укладываются в предметные тематические группы, основанные на инвариантных парах» [2: 118]. Наблюдение над корпусом антифраз показывает, что в антифразах контрастные замены нередко базируют на основе следующих традиционных архетипических оппозиций, зафиксированных в паремиологических единицах:

**1. Оппозиция свой – чужой.**

а) Вариант «свой – чужой» членит свои и чужие вещи, в том числе, свое и чужое добро (имущество), свои и чужие мысли, достоинства, недостатки, слова и т.п.: *На* ***свой калач*** *ухо не закрывай (На* ***чужой каравай,*** *рот не разевай); Палатку, которую сломал* ***Иван*** *(Дом, который построил* ***Джек)*** и др.

б) Противопоставление «родные – неродные» проводит грань между родными и неродными людьми, в том числе не только членами своей семьи, рода, но и соседями, знакомыми или просто сторонними людьми: *Чужой край – отчим,* ***родной*** *–* ***батюшка*** *(Родная сторона – мать,* ***чужая*** *–* ***мачеха****); Возьми доллар,* ***чужак*** *(Гони рубль,* ***родственник)*** и др.

в) дихотомия «свой - чужой» в антифразах нередко осложняется оппозицией «друг – враг», которая делит мир людей на друзей и врагов, сторонников и противников, приятелей и неприятелей: ***Друг*** *иногда превращается во врага (****Враг*** *обычно делается из друга); Ну, что же, посмотри драматурга? Настаиваю,* ***противники*** *(Ну что же, заслушаем клоунов? Прошу,* ***товарищи)*** и др.

**2) Гендерная оппозиция.**

В антифразах гендерные оппозиции, созданные на основе антропометрических лексем образуются следующим образом: а) по признакам пола (женщина / вумэн – мужчина / мэн, сэр – мадам): ***Мужчины*** *складывают чужие деньги в новое или уже приобретенное (****Женщины*** *делят свои вещи на старые и не купленные)*; б) по признакам возраста (юноша / парень – девушка / девица, старик – старуха): *Громче,* ***юноша! Мужчину*** *уродует наглость (Тише,* ***девушка! Женщину*** *украшает скромность);* в) по титулам (король – королева / царица, принц – принцесса): ***Король*** *пар-*

*ковки (**Королева** бензоколонки); г) по профессии (дворник – кухарка): Глупая **кухарка** (Умный **дворник**)* и др.

3. **пространственные оппозиции**

а) оппозиции слов, описывающих противоположные пространственные положения (или направления движения): а) верх – низ: *Деревня **внизу** (Город **наверху**)*; ***Сверху** мороженное (**Снизу** припека)*; б) назад – вперед: *Уползать **назад** (Забегать **вперед**);* в) лево – право: ***Правый** строй (**Левый** марш)*; г) восток – запад: *На **западе**, на **западе**, что за смерть без кофейни (На **востоке**, на **востоке**, что за жизнь без чайханы);* север – юг: *Мальчик с **юга** (Девочка с **севера**)* и др.

б) оппозиции слов, описывающих пространственные признаки предметов: а) высокий – низкий: ***Низкий** шатен в желтых тапках (**Высокий** блондин в черном ботинке);* б) широкий – узкий: *Умирать на **узкую** руку (Жить на **широкую** ногу);* в) глубокий – мелкий: ***Глубоко** тонешь / **Глубоко** летать (**Мелко** плаваешь)*; г) далекий – близкий: ***Далеко** колено, да не лизнешь (**Близок** локоть, да не укусишь)* и др.

Итак, лингвистическая игра в антифразы представляет собой своеобразные загадки, созданные по универсальному принципу контраста; в качестве игрового материала используются прецедентные единицы, которые составляют главное содержание русской лингвокультуры; широкое распространение в антифразах архетипических оппозиций, характерных для русских прецедентных единиц, свидетельствует о лингвокультурной преемственности данной игры.

**Литература**

1. Бочина Т.Г. Принцип контраста: от пословицы до интернет-игры в антифразы // Komparacja systemyw i funkcjonowania wspyiczes-nych jkzykow siowiacskich. T. 3 «Frazeologia»/ Red. nauk. W. Mokijenko i H. Walter. – Opole: Universitдt Greifswald – Institut fьr Slawistik; Uniwersytet Opolski – Instytut Fililogii Polskiej, 2008. – P. 329–338.

2. Пермяков Г.Л. Паремиологический сборник. Пословица. Загадка (Структура, смысл, текст). – М.: Наука. 1978. – 320 с.

# ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ ИҖАТЫНДА КҮТӘРЕЛГӘН ТЕМАЛАР

*Шакирова Г., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Ф. Каюмова*

Шәүкәт Галиев (Һидиятуллин Шәүкәт Галиулла улы) – Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, Х.К. Андерсен исемендәге халыкара әдәби премия иясе, Татарстан Республикасының халык шагыйре. Ул поэзиянең өч өлкәсендә: лирика, сатира һәм балалар шигырендә бердәй уңышлы иҗат иткән шәхес. Аның иҗатында аеруча сугыш, табигать, хайваннар, кошлар, туган як, туган тел, Г. Тукай, мәхәббәт, ата-ана һәм балалар, милләтебезнең күп кенә күренекле, танылган шәхесләренә багышланган темалар урын ала. Без мәкаләбез барышында шуларның берничәсенә тулаемрак тукталып үтәрбез.

Әдип әледән әле, еллар аша сугыш темасына әйләнеп кайта. Ул вакытта күргәннәре, кичергәннәре аның күңелендә күрәмсең төзәлмәс яра калдырганнар һәм хәтеренә уелып калганнар. Ул үзе дә: “Сугыш вакыты – тормышымда иң яхшы белгән, миңа каләм алдырган язмышым” [3: 376], – дип әйтә. Шул елларның кайгы-хәсрәте аның: “Күңел тартты тагын шул якларга”, “Сугышлардан калган мина...”, “Кулын кыса алмадым”, “Дулкыннарда сугыш шаулаганда...”, “Сугышка дип чыгып киткән иргә...”, “Нюра”, “Хәтимә апа”, “Сугышларда калган егетләрнең...”, “Каберләре бөтен Европада...”, “Ул фронтка бәхилләшеп китте...”, “Бер мең дүрт йөз унсигез көн...”, “Күңелемдә күп кешеләр тере...”, “Сугыштан кайтмый калган 169 авылдаш истәлеге”, “Гыйльман, Вилдан” һәм башка шигырьләрендә урын ала.

Шулай ук, әдипнең иҗатында табигать темасы да зур урын алып тора. Аның шигырьләре табигатьнең матурлыгына соклану, туган җиргә, туган ягына, туган авылына карата тирән мәхәббәт хисе белән сугарылган. “Авылда туып үсүем белән үземне бәхетле саныйм. 〈...〉 Авыл мохите әхлак, зәвык, фикерләү – дөньяга караш формалашуның табигый мәктәбе булган” [1: 6], – дип искә ала Ш. Галиев. Күрәмсең, шуңа күрә дә аның шигырьләрендәге туган ягын, авылын ярату укучыларны битараф калдыра алмый. Шагыйрь иҗаты ярдәмендә башкаларга да туган җирен үзе яратып, яраттыра белә. Әлеге шигырьләргә мисал итеп: “Әллә бергә үскәнгәме...”, “Тып-тын урамнардан”, “Кипарислар мине аңламаслар”, “Казлар оча шәһәр өстеннән”, “Күз күнекмәгән...”, “Якташларга әйтер сүзем”, “Без – олы бакырчылар!”, “Мин Кайбычка кайттым”, “Аңлашу”, “Сагыну сабаклары” һәм башкаларны китерергә була.

Ш. Галиев милләтебезнең күренекле, танылган шәхесләре: язучылары, галимнәре, артистлары, җырчылары, композиторлары, рәссамнары турында да яза. Әдипнең шундый шигырьләренә мисал итеп: “Илһам Шакировка”, “Кол Галигә”, “Тирән тамырлар” – Г. Ибраһимовка, “Хәтер иясе” – язучы һәм галим М. Госмановка, “Халык артисты Айрат Арслановка”, “Сара Садыйкова урамы”, “Тормыш-язмыш” – рәссам Ф. Зыязовка, “Котбетдин котлавы” – А. Гыйләҗевка, “Кем ул Роберт Миңнуллин?” һәм башкаларын китерергә була.

Шулай ук, әдипнең иҗатында, халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышлап язган шигырьләре дә бар. Алар: “Сабый чагым дисәм”, “Туры Тукай”, “Тукай Кырлаенда”, “Тукайга”, “Тукай васыяте”, “Уй елгасы”, “Казан арты”, “Тукай рәсеме” һәм башкалар.

Ш. Галиев хәреф таныйганчы ук, әтисе белән әнисеннән Тукай исемен ишетеп белә. Чөнки алар бөек әдипнең шигырьләрен Коръән укыган кебек көйләп, матур аһәң белән укый торган булганнар. Соңрак бу хакта шагырь үзе болай дип искә ала: “Тукайны гел шулай укыйлар

дип белəм, изге китаптыр – əнə бит, шкаф өстендə янəшə алар (Коръəн турында əйтелə). Шагыйрь берəү генə, Тукай гына була, моңлы була, ятим була” [2: 17].

Ш. Галиев Тукай турындагы беренче шигырен 1946 елда язып карый. Əлеге шигырь – “Ун ел үткəч” дип атала. Чөнки əтисе Г. Тукайның илле еллыгы көнендə “Кызыл Татарстан” газетында аның басылып чыккан кульъязмаларын күрсəткəн һəм яңадан мондый язуларны бары ун елдан соң гына күрə алырсың дип əйткəн була. Лəкин Ш. Галиев бу өйрəнчек шигырен берəүгəдə күрсəтми, ə əтисе 1943 елда Бөек Ватан сугышында һəлак була.

1957 елда, янəдəн ун ел үткəч, Ш. Галиевның Г. Тукайга багышлап язылган “Сабый чагым дисəм” шигыре беренчелəрдəн булып дөнья күрə.

Əйткəнебезчə, Ш. Галиев əтисен иртə югалта һəм əлеге вакыйга сабый күңелендə тирəн эз калдыра, аңа əтисе җитми. Бу аның əтисенə багышлап язылган: “Гали” диеп аны йөрттелəр...”, “Əткəй рəсмен илтсəм фотографка...”, “Буран сарган тəрəзəдəн карыйм...”, “Əткəй китте, җыры гына калды...”, “Əтилелəр əти кадерен белми...” шигырьлəрендə ачык күренə. Əдип: “Əткəй – тормышта ымсынып калган бəхетем, татлы сагышым. Əткəй – илһам биргəн бəхетсезлегем...” [3: 377], – диеп искə ала.

Күплəргə таныш булган “Əткəйгə хат” дигəн поэмасын əдип башта гомумəн поэма итеп язарга планлаштырмаган була. Ул ни бары ике куплеттан торган шигырь генə була. Танылган язучы С. Хəким əлеге шигырьне укыганнан соң: “Һəр фикернең үз чамасы бар, ник аны сигез юлга кысырыкларга? Ə менə моны син болай гына əрəм итмə, иркенрəк язып кара” [3: 375], – дип киңəш бирə. С. Хəкимнең биргəн киңəше урынлы була, дəһшəтле сугыш елларының барлык моң-зарын, ачы хəсрəтен, əрнү-сагышларын, югалтуларын, күплəрнең күңелендə кичергəннəрен Ш. Галиев “Əткəйгə хат” поэмасы аша əйтеп бирə. Əлеге поэма автор тарафыннан гаҗəеп тиз иҗат ителə, аны язу өчен ни бары унбиш көн җитə. Ул үзе бу хакта: “Рəхəт язылa. Əдəби əсəр дип уйламыйм, əткəй белəн күптəн көткəн, булмый калган сөйлəшү, күңелдəгене бушату бу” [3: 376], – дип яза.

Шул рəвешле, Ш. Галиев иҗатында күп кенə мəңгелек темалар: мəхəббəт, сугыш һəм тынычлык, ата-ана һəм балалар, туган як темалары урын ала дип əйтə алабыз. Шулай ук, мəкалəбез барышында, əдипнең сугыш, ата, туган як һəм Г. Тукай темаларына җентеклəбрəк тукталдык, аларның ни өчен əдип иҗатында киңрəк яктыртылуының сəбəплəрен билгелəп үттек.

**Əдəбият**

1. Галиев Ш.Г. Илһамым-мəхəббəтем: Лирик язмалар. – Казан: Татар. кит. нəшр., 2006. – 447 б.

2. Галиев Ш.Г. Сайланма əсəрлəр: I том. – Казан: Татар. кит. нəшр., 2002. – 480 б.

3. Галиев Ш.Г. Сайланма әсәрләр: Биш томда, V том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 495 б.

# БУА РАЙОНЫ СӨЙЛӘШЛӘРЕ

*Шакирова Ф., Буа р-ны Әлки мәктәбе, X сыйныф*
*Җит. – Г.Т. Исмәгыйлева*

Бер генә сөйләш тә китапта бирелгән үзенчәлекләр кысасына кереп бетми. Һәр сөйләшнең үзенчәлекләрендә әледән-әле башка диалекталь формалар да очратырга була.

Безнең Буа районы кешеләренең сөйләмендә тау ягы татарлары сөйләшенең кушылмасы, ягъни синтезы киң таралган. Мишәр диалекты да очрый. Шундыйларның берсе: кели сүзе. Мәсәлән: барма кели, кайтма кели, ашама кели, язма кели, сөйләмә кели, җырлама кели, уйнама кели һ.б. Бала урынына малай сүзен дә еш кулланалар. (Малай тапкан). Ызба (өй), ындыр (өстәмә бакча), койрык арты (бәрәңге бакчасы), рәт чиреге (армиягә озату мәҗлесе) сүзләре дә кулланыла.

**Сөйләшнең грамматик үзенчәлекләре:**

Әдәби телдәге билгесез үткән заман кушымчасы -ган, -гән урынына кушма форма -ырлык, -ерлек кулланыла: Җул кайтырлык түгел (Юл кайта торган түгел ). Бу эшләрлек эш түгел (Бу эшли торган эш түгел).

Үткән заман хәл фигылне белдерү өчен кушма форма *-гачтын, -гәчтен, -гачтан, -гәчтән* файдаланыла: *баргачтын, (баргач), килгәчтен,* (килгәч), җырлагачтын (җырлагач), сөйләгәчтен (сөйләгәч), биегәчтен (биегәч).

Хикәя фигыльнең күптән үткән заманын белдерү өчен кушма форма -дырые, -дерие файдаланыла: кайтадырые (кайта иде ), сөйлидерие (сөйли иде), язадырые (яза иде), уйныйдырые (уйный иде).

**Морфологик үзенчәлекләр:**

**Алмашлыклар** әдәби телдәгечә. Тик нәрсә сорау алмашлыгы нәстә вариантында да кулланылуын күрсәтеп үтәргә кирәк: (Тагы бер киемем бар әле, ансысы (анысы) нәстәнекедер (нәрсәнекедер)).

**Фигыльләрне кыскартып сөйләү**

Апбардым – (алып бардым), апкайттым – (алып кайттым). Пырдымсызланды – (тынычсызланды). Арган – (арыган).

**Сөйләшнең лексик үзенчәлекләре;**

Бал кашыгы (чәй кашыгы ), калай әтәч (мактанчык ), марта (бал корты), печтик кенә (кечкенә генә), төнәгенә (кичә), тәпи (аяк), җепшек (епшек), мачы (мәче), акырын ( әкерен), лампы (лампа), пич (мич), инә (энә), сад-бакча (яшелчә бакчасы), кечеткән (кычыткан) һ.б.

Татар теле лексикасында һәр төбәкнең үз җирлеге өчен генә хас булган тагы бер төркем сүзләр яшәп килә. Сүз кечкенә балаларны сөйләшергә өйрәткәндә зурлар телендә очрый торган кайбер гыйбарәләр турында бара.

Ит ярдәмче фигыле белән ясалган сүзләр:

Ә-ә-ә итә (йоклый).

Чәп-чәп итә (мунча керү);

Пәп итә (үбеп ала);

Бу-бу итә (авырта).

Пеш итә (пешерә).

Уп итә (егыла).

Ам итә ( тешли яисә ашый)

Җирле сөйләшләргә бәйле рәвештә төрле вариантлары булган сүзләр:

Мәм-мәм, мәми (ризык, тәмле әйбер).

Тәти ( уенчык һәм чиста, матур әйбер мәгънәсендә).

Бәби ( кечкенә бала яисә курчак).

Какай ( пычрак, тотарга ярамый торган әйбер).

Моннан тыш күпчелек сабыйлар машинаны – түтүт, аякны – пәпи яисә тәпи, сикертеп уйнатуны – үчтеки кебек сүзләр белән алыштыралар.

**Фонетик үзенчәлекләре:** х – к тәңгәллеге: якшы – яхшы, вахыт – вакыт.

“Х” авазы гарәп-фарсы сүзләрендә “һ” авазын да алмаштыра: хава-һава, хаман – һаман, хәйкәл – һәйкәл, шахит-шаһит, хәрбер – һәрбер.

Җ-ләштереп әйтү: җәме – яме, җарар – ярар, җөрәк – йөрәк, җалганчы – ялганчы, җабалак – ябалак, җарый инде – ярый инде, җырак – ерак, җегет-егет, җон- йон, җылак-елак, җылан-елан, җыл – ел, җымычка (йомычка) һ.б.

Ң урынына н куллану: Миңлегөл-Миннегөл;

А ны каты итеп әйтү: Нәзирә – Назыйрә.

Сингармоник вариантлар булу: арчу һәм әрчү, әз-мәз һәм аз-маз, ачы һәм әче, мачы һәм мәче.

И- э тәңгәллеге: инә-энә, ире-эре.

Рус сүзләрен үзгәртеп әйтү: Гөрбиян – грубиян, зерә – зря, кенәгә –книга, кәнсәләр – кацелярия, прит – председатель, перәшкә – пряшка, скамья-эскәмия, шляпа – эшләпә.

**Ассимиляция-диссимиляция күренешләре:**

а) з>ч: килегечче ( килегезче), барыгыччы (барыгызчы).

б) н>м: томбоек (төнбоек), комбагыш, гомбагыш ( көнбагыш).

в) л>ң: суң кул (сул кул ), җаңгыз (ялгыз), җаңгыш (ялгыш).

г) н>ң: сиң генә (син генә ), миң генә (мин генә).

д) с>ч: урычча (русча ), хакачча (хакасча).

ж) ш>ч: чуачча (чувашча).

з) ц>ч: немеччә (немецчә).

и) ф>к: куфайка (фуфайка).

Кеше исемнәрен кыскартып йөртү характерлы: Ислам (Исламетдин), Шәйхи (Шәйхетдин), Хәлим (Хәлимулла), Кәрип (Кәрибулла), Шәрә (Шәрәфетдин).

Диалекталь сүзләрне урынлы-урынсыз куллану телебезне аңлаешсыз итәргә, чүпләргә мөмкин. Шуны онытмаска кирәк: үрнәк сөйләм – әдәби сөйләм.

**Әдәбият**


1. Әхәтов Г.Х. Татар диалектологиясе. Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

2.Әхәтов Г.Х. Татар диалектологиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.

3. Зәкиев М.З. Төрки татар этногенезы. – Казан: Фикер, Мәскәү: Инсан, 1998.


# БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИЛЕШ РАЙОНЫ ЙОННЫ АВЫЛЫ ТУРЫНДА


*Шәяхмәтова Г., М. Акмулла ис. БДПУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. И.С. Насипов*


Аерым торак пунктка бәйле микротопонимнарны тарихи-лингвистик өйрәнү билгеле бер төбәкнең ономастиконы үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Мондый тикшеренүләр бигрәк тә күп телле төрле милләт халыклары яшәгән регион өчен әһәмиятле. Йонны авылы үз тарихы белән шундый торак пунктлар исәбенә керә. Йонны авылы микротопонимикасында бу үзенчәлекләр шулай ук чагылырга мөмкин. Шуңа күрә авылының микротопонимикасы үзенчәлекләрен өйрәнү бик актуаль, ләкин бу мәсьәлә бүгенге көнгә чаклы тиешле фәнни дәрәҗәдә тикшерелмәгән.

Без бу мәкаләдә махсус рәвештә Йонны авылы атамасының килеп чыгышына бәйле фольклор материаллары, авылның микротопонимикасына караган кайбер ономастик берәмлекләр (елга, тау, чокыр, басу, урман) атамаларын өйрәнүне максат итеп алдык.

Һәр авыл җир йөзендәге меңләгән торак пункт арасыннан кайсыдыр ягы белән аерылып тора. Сүз башында мин дә үз авылымның тарихына күз салып узасым килә. Авыл тарихы турында миңа билгеле чыганаклар аз булу сәбәпле, аның барлыкка килү вакытын якынча гына билгеләү белән чикләнергә туры килә. Борын чорларда ата-бабаларым Базы елгасы буйена килеп утырганнар, авылның нигезен корганнар. Авылга нигез салучы Йонны исемле кеше булган.

Авылларның килеп чыгышы турында төрле легендалар бүген дә яшәп килә. Яркәй авылы хакындагы легендаларның берсендэ Базый карт турында сүз бара. Ул Урал таулары ягыннан килеп, елгада туктап атын эчергән. Елганы үз исеме белән Базый дип атаган. Тора-бара ул Базы яңгырашын алаган. Базый картның өч улы булган: Яркәй, Йонны, Янтуган. Безнең авылга исемне бәлки шул Йонно исемле малае калдыргандыр, дигән фараз бар.

Йонны авыл китапханәсендә авыл турында легенда варианты саклanган. Легенданы Вахитова Фәһимә апа язып калдырган. Текст мәктәп дәфтәре битенә кулдан язылган: “Борон-борон заманда Базый карт булган.

Ул Урал таулары ягыннан килеп туктап, атын су эчергән. Елгага үз исемен биргән Базый елгасы булган. Тора-бара ул Базы яңгырашын ала. Базый картның өч улы була Яркәй, Йонны, Янтуган. Авылга исемне бәлки шул Йонны исемле малае калдыргандыр, дип сөйлиләр".

Бу легенданың икенче варианты башка чыганакта теркәлгән: "Өлкәннәр сөйләвенә караганда, Йонны авылы кеше исеменнән килеп чыккан булырга тиеш. Өч бертуган ага булган, имеш: Яркәй, Рсай һәм Юньле. Алар өчесе өч урынга барып төпләнгән. Юньле исеме тора-бара Йонныга әйләнгән. Хәзер Йонны икегә бүленгән: Югары Йонны һәм Түбән Йонны. Алар арасыннан Базы елгасы ага. Географик яктан Йонны Рсай һәм Яркәй авыллары арасында урнашкан" [3: 61, 62].

Авылның аксакалы, укытучы Фәтхлислам Шәйхелисламов абый үзе белгәннәрдән чыгып, түбәндәгеләрне язып калдырган: "Авыл халкы буа буып, тегермән төзегән һәм шул рәвешле судан энергия алганнар Азмы-күпме үзләренчә яшәү теләге булганнар тормыш дәрәҗәләрен күтәрү юлларын эзләгәннәр. Суга якын булмаган җирләрдә яшәүчеләр җил тегермәне корган. Ул тирмәннәр күрше авыллардан килүчеләрне дә хезмәтләндереп торган. Халык бер вакытта да яхшы оннан өзелмәгән. Тора-бара Йонны авылы зураеп китә. Акырынлап авыл халкы елганың ике як ярына да йортлар сала башлый. Шуңа күрә бүгенге көндә ул ике исем белән атап йөртелә: Югары һәм Түбән Йонны авыллары. Елганың сул ягында Югары Йонны, уң ягында – Түбән Йонны. Аларны Базы елгасы аша салынган күпер тоташтырып тора. Беренче йортлар Базы елгасының сул ягына салынган булган" [2].

Базы елгасын буганнан соң су күбәеп, балык үрчетү өчен мөмкинлек туган. Татарлар балыкны якын-тирәдәге рус авылларына барып, бәрәңгегә алыштырганнар. Авылда бер генә кешедә ике төп алмагач үскән булган, әммә халык шалканны күп үстергән. Исәпсез хәзинә саклаган урманнар да калын булган бу якларда. Әммә утын кисү, чыбыкка кагылу тыелган була. Мичкә ягулык итеп сыер тизәген кулланганнар.

Йонны авылының уратып алган җир-су объектларының атамаларына килгәндә, аларның һәрберсе формасы, урыны, зурлыгы, күләме һәм башка үзенчәлекләренә бәйле исемләнгән. Мәсәлән; *Йомры күл, Тирән күл чокыры, Кыска күл чокыры*. Икмәк чәчкән басулар да төрлечә исемләнгән, халык телендә сакланып калган: *Кыеш тау басуы, Пистолет басуы*. Шулай ук җир-су атамаларында җир катламының казылма байлыклары исемнәренә бәйле булганнары бар. Базы елгасының бер урыныннан халык төзелештә кулланыр өчен кызыл балчык алган. Шуңа бу җир *Кызыл яр* атамасын алган. *Акбур тавында* халык күптәннән ак бур чыгарган. Башта известьне тазартып, мичтә яндырганнар. Көйледә

төйгәннән соң, суда еретеп, мич агартканнар. Ак бурны Яркәй базарына алып барып сатканнар.

Элекке чорларда татар, башкорт гаиләләрендә хатын-кызлар күбрәк йорт эшләре белән шөгелләнгәннәр: бала караганнар, ашарга әзерләгәннәр, йорт-җирне тәртиптә тотканнар. Ә ирләр хуҗалык, барлык авыр эшләрне башкарганнар: көтү көткәннәр, сунарга йөргәннәр, эш кораллары җитештергәннәр, йорт, каралты-кураны төзегәннәр, җир эшкәрткәннәр, чәчү чәчкәннәр. Кыскасы ир-атлар табигать белән күбрәк бәйләнештә булганнар. Шуңа күрә дә жир-су атамалары күбрәк ирләр исеме белән аталып йөртелгән: *Хөрмет чиялеге – Хөрмәтулла; Сәлли посадкасы – Сәлимҗән; Левен тирмәсе – Людвик; Аркашка карт тирмәсе – Аркадий* һ.б.

Авыл эчендә җирле географик объект, корылма урнашуга бәйле булган атамалар да байтак - *Мәчет борылышы, Кое урамы* кебек атамалар да очрый. Элек Йонны авылында рус гаиләләре дә яшәгән. Югарыда әйтелгәннәргә шуны өстәр идем: руслар тирмәннәр төзүдә зур өлеш керткәннәр. Шуңа бәйле җирле халыкка эш тә булган. Базы елгасы буенда 33 тегермән төзелә, һәм барысының да хуҗалары урыс милләтеннән була.

Төрле тарихи хәл-вакыйгаларга бәйле җир-су атамалары да бар: *Баяр урманы, Сугыш чокыры* һ.б. *Сугыш чокыры* дип аталган урынның тарихы турында шундый истәлек сакланган: Ул урын Йонны һәм Рсай авыллары арасында була. Җир бүлгән вакытта, җир үлчәүчеләр Бөре өязеннән киләләр. Чокырлы һәм урманлы 13-14 га җир кайсы авылга булырга тиеш? Халык аптырауга кала. Ике авыл арасында тавыш куба. Җир үлчәүчеләрне ике як та төрлечә сыйларга тотыналар; ит, бал, май, йомырка, акча бирәләр. Кайсы авыл күбрәк ришвәт биргән, шул авылга бу җирне биреп киткәннәр. Бер караганда – җир Рсайлыларга, икенче караганда – Йонны авылына күчкән. Халык моның белән килешә алмыйча, көче кулланып көрәшергә була. Билгеле бер көн билгеләнә. Ике якның да ирләре таяклар белән коралланып, бу урынга җыелганнар. Йонны авылыннан атаман Зәйнетдинов Мөхәммәтдин исемле кеше, ә Рсай авылыннан Әхмәтдин исемле кеше бермә-бер көрәшкә чыгалар. Җиңүче ягына җир калдырылырга тиеш була. Йонны атаманы Әхмәтдинне ерткычларча тукмап үтерә, һәм моны карап торган халык бөтенесе бер юлы бер-берсенә ташлана. Йонны халкы Рсайларны авылларына хәтле куып алып бара. Имеш, шул көннән башлап бу кан коелган җир *Сугыш чокыры* атамасын йөртә.

Кеше киләчәккә карап яши, ләкин йортның стенасын нигезсез күтәреп булмаган кебек, кеше дә үзенең үткәнен онытса, аның бүгенгесе дә, киләчәге дә булмый. Ата-бабаларыбыз безгә телебезне, мәдәниятебезне калдырганнар, һәм без аларны сакларга тиешбез.

**Әдәбият**

1. Генеалогии и архивы. Илишевский район. д. Юнин. URL: http://www.ufagen.ru/places/ilishevskiy/yunino.html (дата обращения: 15.12.2019).

2. Башкортостан татарлар фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төз., кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөйләйманов. – Уфа: Китап, 2018. – 344 б.

## РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ИҖАТЫНДА ӘХЛАК ТЕМАСЫ

*Шәйхетдинова З., КФУ, III курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Ф. Каюмова*

Стиль сүзе телнең нинди максатларда һәм ничек кулланылышын белдерә. Язучы үз әсәренең үзенчәлекләреннән чыгып, төрле тел чараларын сайлый һәм аларны үзе теләгәнчә файдалана. Сүзләр мәгънәви яктан күп төрле. Үзләре үк образга әйләнгәннәре (символлар), күчерелмә мәгънәлеләре (метафора, метонимия, сынландыру, гипербола, юмор), предметлы сурәтләү чаралары (синонимнар, антонимнар, эпитет, чагыштыру), әдәби нормаларга туры килмәгән лексик чаралар (диалекталь, гади сөйләм, арго һәм жаргон сүзләр, варваризмнар) бар. Р. Миңнуллин – әнә шул тел-стиль чараларына җан кертеп, аларны иң оста кулланып язучыларның берсе.

Мәсәлән, “Трамвайда “куян” булып йөрергә яраткан малай турында” шигыренә игътибар итик. Әсәрнең исеме нәкъ эчтәлегенә тури килми, малай “куян” түгел:

*Әздер миннән*
*Көлсәң дә –*
*Билет булган*
*Кесәмдә!* [3: 111].

Автор алдан малайны билетсыз итеп сурәтли, биредәге малай хисләрен бирүдә градация алымын куллана:

*Мин шундый каушаганмын,*
*Мин шундый курыкканмын* [3: 111].

“Табын янында” шигырендә Нур белән Вилнең ярышуы сурәтләнә. Белгәнебезчә, табын алдында мондый ярышлар үткәрү урынлы түгел. Р. Миңнуллин ситуацияне кабатлаулар аша бирә:

*Виле: “**Бетә бит**!” – дип, Нурны*
*Тора котыртып.*
*Нуры тиз-тиз ашый ашын,*
***Бетә дип** куркып* [4: 110].

“Нишләрбез инде?!” шигырендә тыңлаусыз Ләлә сурәтләнә:

*Инде берәр эш кушсалар,*
*Әй Ләлә чәбәләнә,*
*Киреләнә, үҗәтләнә,*
*Кыскасы, кәҗәләнә!* [3: 116].

Әлеге күренешләрне төгәлрәк, бер-бер артлы килүче процессларны биръ автор синонмнарны куллана: *чәбәләнә, үҗәтләнә, киреләнә* һәм *кәҗәләнә* дип берләштереп куя.

“Томау, җиң һәм кулъяулык” шигырендә баланың борынны җиңенә сөртүе тасвирлана. Бала безне кисәтеп тә куя:

*Юпь-юеш шул, юпь-юеш,*
*Тагын сөртер идем дә.*
*Борчылмагыз!Минем әле*
*Бар икенче җиңем дә!* [4: 119].

Биредә автор юмор, йомшак көлү чарасы, җиңелчә елмаюга мөрәҗәгать итә, шаян мөнәсәбәтне белдерә.

“Таш, чыпчык һәм алма” шигырендәге фикер түбәндәге юлларда белдерелә:

*Әмәлен ләкин таптым –*
*Агачка мин таш аттым.*
*Юк ла, алмага аттым,*
*Чынлап та, аңа аттым.*
*Юк ла, чыпчыкка аттым!*
*Ахрысы, юкка аттым...* [4: 60].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: Р. Миңнуллин шигърияте төрле сурәтләү чараларга бик бай. Р. Миңнуллин сүзләрнең лексик чараларыннан да актив файдалана, аларны сурәтләү чарасына әверелдерә.

Шулай итеп, Р. Миңнуллин иҗаты, шигърияте, аның иҗат теле – әле ачылып бетмәгән сер. Мавыктыргыч, үзенә тартып-чакырып тора торган сер. Аның теленең тылсымлы көчен ныграк өйрәнгән саен, бу серле шигъри дөньяның асылына якынаябыз. Шуңа күрә, шагыйрь иҗатының индивидуаль лексик үзенчәлекләрен, стилистик алымнарының бирелешен, андагы урынлы кулланылган бай, энҗе бөртекләредәй тел-бизәкләү чараларын өйрәнү мөһим.

**Әдәбият**

1. Миңнуллин Р.М. Әсәрләр. Җиде томда. Т.3: балалар өчен шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр, мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 543 б.
2. Миңнуллин Р.М. Әсәрләр. Җиде томда. Т.4: балалар өчен кечкенә әкиятләр, ирекле тәрҗемәләр, төрле язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 528 б.
3. Шәймәрданов М.Х. Татар милли педагогикасы: югары һәм урта педагогика уку йортлары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.

## ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ ТАРТЫКЛАР ЧИРАТЛАШУЫ ОЧРАКЛАРЫ

*Шәнгәрәева А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. М.Р. Саттарова*

Җанлы сөйләм процессында авазларның еш кына үзгәрүе, бүтән авазлар белән алмашуына тап булабыз. Бер ук морфема төрле аваз

вариантларында йөрергә мөмкин. Авазлар үзгәрү хәзерге телне, яисә аның элекке кагыйдәләре нигезендә бара. Бер морфема составындагы төрле авазларның теге яки бу кагыйдә нигезендә тәңгәлләшүе ***чиратлашу*** дип атала[4: 234].

Тартык авазларның чиратлашуына карата тел белгече Л. Яфаров: "Татар телендә, шул ук вакытта башка төрки телләрдә дә, саңгырауларның яңгыраулаша баруы эпохалар буена килгән үсеш, үзгәреш һәм камилләшү процессы буларак, телдәге күп кенә тарихи фактлар белән исбатлана", – дип язды [5: 55].

Башкорт һәм татар телләренең казах, себер татарлары, удмурт, марый телләре белән лингвоэтник бәйләнешләре бар. Башкорт теле грамматикасына зур өлеш керткән галим Н.К. Дмитриев "Грамматика башкирского языка" монографиясендә авазлар чиратлашуы мәсьәләсенә аерым бүлекчә багышлый [2: 28]. Әлеге хезмәтендә ул *п, т, к, къ* саңгырауларының *б, г, гъ* яңгыраулары белән чиратлашу мәсьәләсен карый, түбәндәге мисаллар китерә: сап-сабы, аяк-аягъы, һ.б. Шулай итеп, чиратлашу күренешен Дмитриев мәҗбүри характерга ия ди, әдәби норма буларак, орфографиядә чагылуын табигый күренеш, дип яза [2: 30-31]. Башкорт телендә аваз чиратлашуы авазларның сөйләмдә бер-берсенә тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килә: әгәр [к], [қ], [п] тартыкларына тәмамланган сүзләргә сузык авазга башланган кушымча ялганса, ике сузык арасында калган әлеге тартыклар, шул сузыклар тәэсирендә яңгыраулашалар, мәсәлән, ак-а > ага, түк-ә > түгә, төп-е > төбе һ.б. Акустик яктан бу беренче формантаның түбән төшүендә һәм спектрда борын тартыкларында була торган өстәмә форманта пәйда булу белән тәкъбир ителә. Авазларның нигез ахыры һәм аффикслар башында яңгыраулыкта һәм саңгыраулыкта параллелизмга дучар булуы төрки телләрнең барлыкка килүеннән үк башланып, хәзерге көнгәчә дәвам итә, дип яза Дмитриев [2: 33-35].

Башкорт телендә аваз чиратлашу һәм татар телендә аваз чиратлашу арасында параллель үткәреп була. Башкорт телендә, татар телендәге кебек, сыйфат дәрәҗәләре, төгәлрәк әйткәндә, чагыштыру дәрәҗәсе *-раҡ, -рәк, -ыраҡ, -ерәк, -ораҡ, -өрәк* кушымчалары белән ясала: *йәшел – йәшелерәк, кара – каранак, кызыл–кызылрак, зәңгәр-зәңгәррәк*. Еш кына, мондый очракларда тартыклар чиратлашуына тап булабыз: әгәр сыйфат-сүз к, ҡ, п авазларына бетә икән, чагыштыру дәрәҗәсе ясалган вакытта әлеге авазлар г, ғ, б авазлары белән чиратлаша: *күк – күгерәк, ябыҡ – ябығыраҡ*.

Шуны өстәп әйтергә кирәк, чиратлашу рәвеш дәрәҗәләре ясалганда да барлыкка килә: *күп – күбрәк, шәп – шәберәк, озак – озаграк.*

***Абайлабыраҡ*** *ҡараһа, күрше урыҫ ауылындағы белешенең өйө икән. Инде ни эшләргә? Көн дә кисләп бара, үгеҙҙең дә көйшәп алғыһы*

*килгәндер. (Батырҙар тураһында әкиәттәр). Сәлмән үҙе килһә, утынды икәүебеҙҙән дә* ***күберәк*** *тейәп алып ҡайтыр. Әсәйебеҙ беҙҙе түгел, уны маҡтар (Батырҙар тураһында әкиәттәр).*

Әлеге мисалларда [п] һәм [б] авазларының чиратлашуына тап булабыз. Татар теленнән аермалы буларак, чагыштыру формасы ясалганда, шул исәптән чиратлашу барлыкка килгәндә дә, авазлар редукциягә бирешми.

Тартым белән төрләнгән очракта да, тартык авазлар чиратлашуга дучар булалар:

*Һаман өҙөлөр ул, "балам", тиеп,*

*Һыҙлаһа ла* ***йөрәге*** *яраһы* (Кәтибә Кинйәбулатова).

*4. Әбей, килеһенен тағы ла* ***шәбен*** *ҡыуалап, ҡыҙҙарҙы ашайым тип, ҙур өмөт менән ауыҙ һыуҙарын йотоп, шәберәк китте, ти (Башкорт халык әкияте).*

Башкорт телендә саңгырау тартыклар яңгыраулашуының тагын бер сәбәбе: әлеге авазлар алдында сузыкка яисә яңгырау тартыкка беткән сүз килеп, алар арасында пауза булмау (*бергөн = бер+көн; казғанаты = каз+ канаты*). Татар телендә исә кушма сүзләрдә язылыш кагыйдәсе саклана: *беркөн, аккош, акбур, өчпочмак тимераяк* һ.б. Тарихи искәрмә: *бүген* (*бу+көн*).

Шулай итеп, татар һәм башкорт телләрендә тартыклар чиратлашу очракларының төрлесенә тап булабыз. Һәр ике телдә дә чиратлашуны билгеле бер фонетик закончалыкка бәйләп булса, аерым бер мисалларның тарихи чиратлашуга, сөйләмгә инде нәкъ шул вариантта кулланганлыгын да күзәтә алабыз. Бу мәсьәләдә сузыклар чиратлашуы да аерым игътибарга лаек. Төрки телләрнең чагыштырма фонетикасы белемендә бу сорау әле дә ачык тора.

**Әдәбият**


1. Академический словарь башкирского языка. в 10 тт. / под ред. Ф. Г. Хисамитдиновой. – Уфа: Китап, 2011. – Т. 1. – 432 с.
2. Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка. – М.: Наука, 2008. – 342 с.
3. Татар грамматикасы. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т. I. – 512 б.
4. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2002. – 406 б.
5. Яфаров Л.И. Татар теле фонетикасының кайбер закончалыклы тенденцияләре: Филол. фән. канд...... дисс. – Казан, 1955. – 264 б.


## БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИЛЕШ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЯРКӘЙ АВЫЛЫНЫҢ ГОДОНИМНАРЫ


*Юнысова Р., М. Акмулла ис. БДПУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. И.С. Насипов*


Урам исемнәре безнең тарихи мирасыбыз булган торак пункт топонимикасының мөһим өлеше. Исем – урамның «визит карточкасы» гына түгел, ул үзе барлыкка килгән чорның үзенчәлекле һәйкәле, алар ата-

бабаларыбыздан калган тарихи ядкяр. Шул сәбәпле,мине күптәннән туган авылмның урам исемнәре кызыксындыра.

*Югары Яркәй* – Башкортостан Республикасының Илеш районы үзәге. Шулай ук Югары Яркәй авыл совет биләмәсе үзәге дә булып тора. Уфадан 160 км ераклыкта Базы елгасы буенда урнашкан. Административ үзәктә 10 меңнән артык кеше яши. *Яркәй* авылы XVII гасыр уртасында *Елан* дип аталган.Соңрак авылның абруйлы кешесе - Яркәй Янчурин исемен алган. Бүген Югары Яркәй һәм Түбән Яркәй авыллары бар.

Югары Яркәй авылында 82 урам бар.

*Елга* урамы. Бу урам үз исемен XIX гасыр ахырында, Базы елгасының уң як яры буенда урнашканлыктан алган. Ул вакытта *Елга* урамы бердәнбер урам булган һәм Яркәй Янчуринның нәсел варислары да шунда яшәгән. 1935 елда *Куйбышев* урамы итеп үзгәртелә. Совет чорында мондый идеологик яссылыкта барлыкка килгән урам атамалары байтак. *Совет* урамы. Элек бу урам Уфа, Мәскәү, Бөре, Минзәлә кушылган трактка бәйле *Таш* урамы дип аталган. Ул 1937 елдагы картада теркәлгән. Халыкта аны *Екатерина юлы* дип йөртәләр. Риваять буенча, император үзе бу юлны төзергә кушкан, имеш. Әкренләп урам Иске Күктау авылы ягына, көнбатышка таба киңәя. *Ленин* урамы.Ул Бөек Ватан сугышыннан соң барлыкка килә. *Коммунистик* урамы бөтен авыл аша, көньяктан төньякка таба уза. Ул 1930 елларда барлыкка килә. 1950 елларда да биредә җирле административ органнар урнаша башлый. *Комсомол* урамы атамасы яшьләр оешмасы хөрмәтенә кушылган. Мондыйлар рәтенә шулай ук *Дзержинский, Ульянов, Зорге, Фрунзе, Киров,Чеверев,Чапаев* исемле урамнарны да кертеп була. *Кызыл Армия* урамы КПССның Илеш райкомы беренче секретаре Т.Л. Рахманов тәкъдиме белән аталган.

Илебезнең күренекле шәхесләре исемнәре белән аталган урамнар да байтак: *Пушкин, М. Горький, Фадеев, Шолохов, Гагарин, Салават Юлаев, Ломоносов, Жуков* исемнәрен йөртүче урамнар шундыйлардан.

XX гасырның 80 нче елларында *Октябрьнең 50 еллыгы, Яшьләр, Матросов* урамнары, *Каразирек* елгасы аша төзелгән күпергә бәйле *Күпер* урамы барлыкка килә.

XX гасыр азагында Югары Яркәйдә авыл урамнарына исем бирүдә сакчыл,уйлап карар кабул итү сизелә. Урам атамалары итеп күренекле якташларыбыз исемнәре алына: *Яримов* урамы (Яримов – җирле мәгърифәтче һәм сәясәт эшлеклесе), *М. Гәрәев* урамы (Муса Гәрәев – ике тапкыр Советлар Союзы Герое),*Абдуллин* урамы (Әнвәр Абдуллин – Советлар Союзы Герое) *Р. Хәйри* урамы (Ринат Хәйри – күренекле шагыйрь һәм журналист), *Г. Рәфыйков* урамы,(Габбас Рәфыйков – Илеш район Советының беренче рәисе), *С. Газизова* урамы (Сәлимә Газизова - БАССРның атказанган табибы, Ленин ордены һәм Хезмәт Кызыл Байрагы

ордены кавалеры), *Г. Сираев* урамы (Габдрахман Сираев – “Башкортстан” колхозы рәисе), *Х. Сарьян* урамы (Хәсән Сарьян – күренекле татар язучысы).

Авылның һәм төбәкнең тарихы да урам исемнәрендә чагылган. *Иванов* урамы атамасы 1960 елда яшәүдән туктаган элеккеге *Ивановка* хуторы исемен алган. Ул бүген авыл эченә кереп китеп бара. *Яркәй Янчурин* урамы *Яркәй* авылына нигез салучы кешеләрнең берсе Яркәй Янчуринның исем-аты.

Күренекле татар һәм башкорт әдипләренең исемнәре дә кушылган урамнар бар. Алар атамаларында Һ. Такташ , Ш. Бабич, Х. Дәүләтшина, З. Биишева, М. Җәлил исемнәре мәңгеләштерелгән.

*Спорт* урамында бик күп спорт мәйданчыклары һәм спорт комплекслары урнашкан. Казан юлы М-7 трассасы аша күрше Бакалы районына таба бара торган юл янәшәсендә *Бакалы* урамы сузылган.

Илебез тарихында урын алган күренекле бәйрәмнәргә бәйле *Олимпия*, *Җиңүнең 70 еллыгы урамы*, *9 Май* урамнары аталды. Топонимнардан *Баймак* һәм *Урал* атамалары да урам исемнәре буларак урын алган.

Соңгы елларда яңа урамнарга *Яшел* (Зелёная), *Роща* (Рощинская) , *Ылыслы* (Хвойная), *Нарат* (Сосновая) кебек матур исемнәр кушу да күзәтелә. Югары Яркәйдә шулай ук ике тыкырык бар – *Китапханә* һәи *Чеверев* тыкырыклары.

Шулай итеп, *Югары Яркәй*нең урам исемнәре авылның үткәнен һәм бүгенгесен чагылдыра. Алар аша без туган якның тарихын,үсеш-үзгәрешен күзәтә алабыз, күренекле шәхесләре белән танышабыз. Шулай ук бу атамалар район, республика һәм Туган илебез тарихына да бәйле. Шуңа күрә без аларны өйрәнү аша яшь буында туган телебезгә, тарихыбызга сакчыл караш, хөрмәт һәм горурлык хисе тәрбияли алабыз.

**Әдәбият**


1. Никонов В.А. Введение в топонимику. – М., Наука, 1965. – 179 с.
2. Усманова М.Г. Имя отчей земли. Историко-лингвистическое исследование топонимии бассейна реки Сакмар. – Уфа: Китап, 1994. – 272 с.
3. Хисамитдинова Ф.Г. Башкирская ойконимия XVI-XIX вв. – Уфа: Башир. кн. изд-во, 1991. – 304 с.
4. Шакуров Р.З. По следам географических названий. – Уфа: Башк. кн. издво, 1986. – 184 с.


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЫШАНУЛАР


*Ягафарова А., Казан, 6 нчы гимназия, XI сыйныф*

*Җит. – Г.Н. Хафизуллина, М.З. Закирова*


Безнең бүгенге әдәбиятыбыз халыкның поэтик иҗатына, аның сүз сәнгатенә, фольклорга барып тоташа. Фольклор сүзе “халык акылы” дигән мәгънәгә ия. Ә халык акылы бик күп гасырлар дәвамында формалашкан. Бүгенге көндә фольклорда бик күп төрле жанрлар билгеле.

Татар халык авыз иҗатында киң таралган жанрлар булып җырлар, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, әкиятләр, легендалар, мәзәкләр, бәетләр, дастаннар санала. Галимнәр фикеренчә, бу жанрлар борынгы ышану-мифлардан килеп чыккан. Борынгы мифлар халык авыз иҗатының нигезен тәшкил итә. Шулар арсында ышанулар да бар.

Бүгенге көндә дингә ышанучылар бик күп булса да, кешеләрнең күбесе хаман да төрле мифик затларга, ияләргә ышанып яши бирә. Тормыш-көнкүрештә бу бигрәк тә ачык күренә.

Мәсәлән, гади халык яшәешеннән моңа мисалларны шактый күп китерергә була:

- *Ашаган сыныгыңны калдырсаң, иптәшең ташлар, яки бәхетең тулы булмас;*
- *Ашап утырган чәйгә икмәк кисәге төшсә, өйгә кунак килә;*
- *Бусагага утырсаң, үсми каласың;*
- *Берәр кеше ерак юлга киткәч, аның артыннан ук идән себерергә ярамый* һәм башкалар.

Әлеге һәм башка ышануларны без көн саен диярлек ишетеп яшибез, аеруча әби-бабайлар белән бергә яшәгән гаиләләрдә алар еш ишетелә.

Эзләнү эше барышында без үзебезнең гаиләләрдә ишеткән ышануларны тупладык, аларны җентекләп өйрәндек. Безнең фикеребезчә, ышануларны берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. Ашау белән бәйле ышанулар:

*Тоз чәчелсә, талаш чыга;*

*Идәнгә төшкән ризыкны кабарга ярамый – җен кагылган булуы бар* һ.б.

Киенү белән бәйле ышанулар:

*Киемне кигәндә җырларга ярамый, салганда елавың бар;*

*Ккиемне өстеңдә кигән килеш тегәргә яки ямау салырга ярамый – сәламәтлегең белән кыенлыклар кичерерсең* һ.б.

2. Юлга чыгу белән бәйле ышанулар:

*Юлга чыгар алдыннан киемне ямарга, төймә тагарга ярамый – юлда бәхетсезлек саклап торыр;*

*Юлга чыккач, әйберең онытылса, кире кайтырга ярамый, кайткан очракта көзгегә карап алырга кирәк* һ.б.

3. Хуҗалык кирәк-яраклары белән бәйле ышанулар:

*Җирдә яткан көрәк, тырманы атлап чыксаң, бәхетсезлек килер;*

*Кояш баеганнан соң чүп ташларга ярамый* һ.б.

4. Йорт белән бәйле ышанулар:

*Бусагага утырсаң, үсми каласың;*

*Идән себергәндә ишеккә таба түгел, киресенчә, ишеккә каршы себерергә кирәк, йорт бәрәкәте чүп чыгарга мөмкин* һ.б.

Мисалларга караганда, ышанулар безнең халык күңелендә шактый нык урын алган, аларга игътибар итүчеләр дә, ышанмаучылар да бар.

Татар халык авыз иҗатында ышануларга бик охшаш жанр – сынамышлар да билгеле. Сынамышлар һәрвакыт авыл кешесенең көндәлек эшләре, көнкүреше, ахыр чиктә аның ач яки тук булуы белән бәйләнгән. Сынамышның төп максаты – киләчәкне хәбәр итү, һава торышы ничек булыр, күпме уңыш алыныр, кайсы игеннәрнең күпләп уңуын фаразлау.

Ышану һәм сынамышларның икесенең дә нигезендә нинди дә булса вакыйга-күренешнең булачагына ышаныч белән карау, өмет итү, фараз кылу ята. Халыкта ышанулар ул шул ук сынамышлар диеп кабул итү яшәсә дә, алар арасында аерма зур. Төп эшебездә китерелгән билгеләмәләргә карасак, сынамышлар төрле табигать күренешләре арасындагы бәйләнешләр, элемтәләр турында мәгълүмат бирсә, ышанулар үзәгендә мистик подтекст ята.

Сынамышлар бүген дә бик популяр. Чөнки аларда әйтелгән фаразлар күп очракта дөреслеккә туры килә, чынга аша. Бигрәк тә һава торышына бәйле сынамышлар кешеләр өчен кызыклы, кешеләр андый төр сынамышларга күпләп игътибар бирә. Мәсәлән:

*Карлыгачлар түбән очса, яңгыр явар, югары очса, аяз һава булыр;*

*Апрель актыкларында җылы яңгырлар булса, игеннәр яхшы булыр;*

*Беренче мартта буран булса, карабодай уңар.*

Ышанулардан аермалы буларак, сынамышларны төркемләүдә авырлыклар юк, аларны 4 ел фасылына – җәй, көз, кыш, яз айларына бәйләп, төрле төрләргә бүлеп карарга була. Әйтик, халык арасында кышка, язга бәйле сынамышлар аеруча киң таралган.

Ышану һәм сынамышлар халкыбызның ерак тарихын, милли үзенчәлекләрен, яшәү кагыйдәләрен өйрәнү чыганагы булып та торалар. Аларда борынгыларның фәне дә, сәнгате дә, педагогикасы да чагылыш таба. Шуңа күрә аларда аңлату да, кисәтү дә, тәрбия дә бар.

Халыкның үткәнен белмичә, киләчәге турында сүз йөртеп булмый. Ышану-юраулар, сынамышлар үткән заманны бүгенге һәм киләчәк белән тоташтыра, буыннарның рухи бәйләнешен тәэмин итә.

**Әдәбият**

1. Татар мифлары. Беренче китап: Иялəр, фаллар, ышанулар, им-томнар, мифлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 388 б.

2. Татар мифлары. Икенче китап: Иялəр, фаллар, ышанулар, им-томнар, мифлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 432 б.

3. Бакиров М. Татарский фольклор. – Казань: Ихлас, 2012. – 400 с.

4.Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. / Ф. Урманче. – Казан: Мәгариф, 2009. II т. (Д-С). – 343 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «ТАМЧЫ» КОНЦЕПТЫ

*Япбаров А., Түбән Кама, 20 нче мәктәп, X сыйныф*

*Җит. – И.Ш. Ишмөхәммәтов*

Телне мәдәни күренеш буларак өйрәнү бүгенге көндә бик актуаль. Татар телендә күп кенә концептлар инде тикшерелгән, алар буенча фәнни эшләр башкарылган, ә “тамчы” концепты әлегә кадәр тикшерелми кала бирә. Шуны истә тотып, үз алдыбызга “тамчы” концептының татар телендә чагылышын тикшерү максатын куйдык.

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә “тамчы” концептының 5 мәгънәсе бирелә [7: 30].

“Татарча-русча сүзлек”тә тамчы сүзенең 3 мәгънәдәге тәрҗемәсе китерелгән [5: 309].

Г.Х. Әхәтовның “Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге”ндә “тамчы” концепты кергән фразеологизмнар теркәлмәгән. Ә.Н. Исәнбәтнең “Татар теленең фразеологик сүзлеге”ндә 2 фразеологик әйтелмә очратырга була [3: 108]. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә, боларга өстәп, түбәндәге фразеологизмнар китерелә: 1) *тамчы гына черем итү* – бик аз гына йоклап алу; 2) *тамчы бөртек* – бик аз гына, бер бөртек кенә; 3) *катрә бөртек (катрә бөртеге) кадәр* – бик аз гына. “Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек”тә “тамчы” концепты кергән 4 фразеологик әйтелмәгә тап булдык [6: 204]. “Татарча-русча сүзлек”тә түбәндәге фразеологизмның тәрҗемәсе китерелгән: 1) *тамчы бөртек тә* – ни капли [5: 309].

Г. Саттаровның “Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге”ндә “тамчы” концепты кергән *Тамчы* татар антропонимы теркәлгән. Аның синонимы буларак Нотфә гарәп антропонимы китерелгән [9: 398, 417].

“Татар теленең зур диалектологик сүзлеге”ендә “тамчы” концептының тара сөйләшендә *тамы* дигән диалекталь варианты бирелгән һәм мисал буларак *тамы да* сүзе тәкъдим ителгән. *Тамы да* – бөртеге дә, тамчысы да (ни крошки, ни капли) [8: 605].

Татар теленең синонимнар сүзлегендә тамчы сүзенең синонимнары күрсәтелмәгән. Тик шулай да, тикшерену барышында, аңлатмалы сүзлек, татар исемнәре сүзлеге һәм диалектологик сүзлектәге мәгълүматларга нигезләнеп, без тамчы сүзенең *катрә* [1: 206], *нотфә* (гарәпчә *тамчы*) [9: 398] һәм тамы [8: 605] дигән синонимнары барлыгын ачыкладык [7: 242].

Г. Тукайның шигърият теле сүзлегеннән күренгәнчә, шагыйрь үз иҗатында “тамчы” концептын шулай ук оста кулланган. “Актык *тамчы* яшь” шигырендә әлеге концепт шигырь исемендә теркәлгән. “Яхшы хәбәрләр” шигырендә “Язгы яңгыр *тамчысы* бер башка *тамчыдан* сорый”, “Мәхәббәт” шигырендә “Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр *тамчысы”*, “Ана догасы” шигырендә “Тамадыр мискинәмнең *тамчы-*

*тамчы* күзләреннән яшь", ә "Укыгыз, кызлар…" шигырендә "*Тамчы-тамчы* тамган судан тирән диңгезләр булыр" юлларында кулланылган [10: 160].

М. Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре" теле сүзлегендә "тамчы" концепты кергән строфаларны шулай ук очратырга була. "Кичер, илем!" шигырендә "Соңгы тамчы каным тамса тамсын, тик антыма таплар кунмасын!", "Сандугач һәм Чишмә" балладасында "Бер *тамчы* эчә дә чишмәгә егыла", "Ах, әгәр булсачы бер генә *тамчы* су! , Зөбәрҗәт *тамчылар, Тамчылар* сикерми, "Кар кызы" шигырендә Кызның йөзендә тама *тамчылар* "Күлмәк" шигырендә "Ике генә *тамчы* яшь чылатты гөл чуклары төсле керфеген", "Һәр чигештә күпме яшь*"*, "Соңгы үпкә" шигырендә "Мин тапмадым җирдә бер *тамчы* су", "Ана бәйрәме" шигырендә "Һәр *тамчысы* хәләл сөтемнең, "Чәчәкләр" шигырендә "Йотып тир һәм яшь *тамчысын"*, "Яңа ел теләкләре" шигырендә "Яшебезнең кайнар *тамчысын* кебек" "тамчы" концепты кергән юллар бар [2: 131].

Дөнья тел картинасын анализлау өчен мәкаль һәм әйтемнәрне анализлау мөһим санала. Шуның өчен без "тамчы" компоненты булган мәкаль һәм әйтемнәрне дә барладык. Н.С. Исәнбәтнең "Татар халык мәкальләре" (I том) җыентыгында "тамчы" сүзе аерым сүзлек мәкаләсе буларак кулланыла һәм ул концепт кергән 21 берәмлек китерелә [4: 336].

Интернет челтәрендәге татар халык мәкальләре тупланмасында боларга өстәп тагын 6 мәкаль-әйтем очраттык: 23) Бер тамчыдан диңгез булмый. 24) Күл тамчыдан җыела. 25) Тырышкан *тамчы* таш тишкән. 26) Адым-адым – юл булыр, *тамчы-тамчы* – күл булыр. 27) Ике *тамчы* су кебек.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: "тамчы" концепты телдә югары ешлыкка, күпмәгънәлелеккә ия; актив лексика; актив ясагыч нигезле сүз (таму, тамчылы, тамчыдай, тамчылану, тамчыландыру, тамчылап, тамчылау һ.б.). "Тамчы" бер составлы атау җөмләнең баш кисәге, шигырь исеме була ала ("Бер тамчы жылылык", "Мәхәббәт тамчылары", "Там там, тамчы, там", "Тамчылар", "Тамчы гөл", "Тик бер тамчы якты кирәк җанга", "Тамчы гөлем", *"Тамчылар маршы"*). "Тамчы" лексемасының синтагматик бәйләнешләре дә киң: тамчы – тама, тишә, җиңә, яра, уйный.

Бу концептны репрезентацияләүче тел һәм сөйләм материаллары халык тарихын, халыкның тормышка мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә. "Тамчы" концепты милли концепт критерийларына туры килә.

Шулай итеп, "тамчы" концептын тикшерү барышында без аның татар теле дөнья күренешендә мөһим урын алуын, аны баетуга өлеш кертүен ачыкладык. "Тамчы" концепты да халыкның дөньяны танып белү үзенчәлекләрен, яшәү принципларын билгеләргә ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре / К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 792 б.

2. Муса Җәлил. “Моабит дәфтәрләре” теле: Сүзлек / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина, Л.С. Минһаҗева. – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.
3. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. 2 томда. Т. II. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 365 б.
4. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 2-нче басма. Т. I. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 622 б.
5. Татарско-русский словарь: В 2-х т. Т. II (М–Я). – Казань: Магариф, 2007. – 309 с.
6. Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек. – Казан: Хәтер, 2010. – 296 б.
7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, Т. III. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 831 б.
8. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.
9. Саттар-Мулилле Г. Татар исемнәре ни сөйли?: Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге. – Казан: “Раннур” нәшр., 1998. – 485 б.
10. Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2009. – 527 б.

## ЭЧТӘЛЕК


**Аббазова Р.** Сонеты в творчестве Уильяма Шекспира и Рената Хариса ............................4
**Абужалитова А.** Білім мазмұнын жаңарту жағдайында критериалды бағалау – оқушылардың ізденімдік-танымдық құзыреттілігін қалыптастырудың негізі ...................6
**Альмеева М.** Этнонациональное в пословицах татарского народа....................................10
**Аманжанова А.** Репрезентация языковой картины мира в жанрах фольклора .................12
**Амирханова Л.** Насколько друг друга понимают азербайджанцы и татары .....................14
**Арипбай А.** Әлемдік тілдік бейнесіндегі «Аққудың» танымдық сипаты ...........................17
**Әбрарова А.** Казан шәһәре урам исемнәренең орфографик үзенчәлекләре.......................20
**Әминова Г.** Эмоцияләрне белдерүдә синонимлык мөнәсәбәтләре .....................................22
**Әсхәдуллина Г.** Татар мәдәниятендә хатын-кыз сыйфатлары бирелеше...........................25
**Әхмәдиева Й.** Шагыйрь шәхесен мәңгеләштерү: Татарстанда Тукайга һәйкәлләр..........27
**Әхмәтгәрәева Г.** Фэнтези әсәрләренең татар һәм төрек тәрҗемәләрендә реалияләр бирелеше .......................................................................................................................29
**Әхсәнова Г.** Олуг шәхес – Рәшит Рәхмәти Арат ....................................................................31
**Бариева А.** Чыңгыз Айтматов әсәрләренең татарчага тәрҗемә үзенчәлекләре.................34
**Баһавиева Ч.** Татар халык сынамышларында кулланылган тезмә сүзләрнең ясалыш үзенчәлекләре ..........................................................................................................36
**Болгарова А.** Сравнительные конструкции в фольклорных текстах (на материале татарских и русских загадок)...........................................................................................38
**Ван Янь.** Ассоциативное поле лексемы «счастье» в русском языковом сознании… 40
**Вәлиева А.** Якташ шагыйребез иҗатында поэтик бизәкләр ................................................42
**Вилданова Ә.** Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романында һәм аның рус теленә тәрҗемәсендә синонимик парлы сүзләр .............................................................................44
**Волков Т.** Сөйләшсәк тә төрле телләрдә ..............................................................................46
**Габдрахманова Л.** Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал иҗатларында маринистик пейзаж 48
**Габдуллазянова Г.** Роль повтора в создании ритма и рифмы в произведениях детского фольклора.............................................................................................................50
**Габдуллин Р.** Г. Сабитов хикәясендә образ тудыру үзенчәлекләре .....................................52
**Габдуллина А.** Лингвострановедение как область методики и лингвистики....................54
**Габидуллина Э.** И. Юзеевның «Мәңгелек белән очрашу» поэмасында символик образлар ..........................................................................................................................56
**Гайнуллина Д.** Ә. Еники публицистикасында бөек шәхесләр язмышы............................58
**Гайфуллина И.** Россия Федерациясенең төрки антрополисонимнары .............................60
**Галәветдинова Л.** Массакүләм мәгълүмат чараларында спорт терминологиясе .............63
**Галеева А.** Интертекстуальные вкрапления в творчестве татарского поэта XX века Ильдара Юзеева..............................................................................................................65
**Галиәхмәтова Д.** Һ.Такташ иҗатында тел-сурәтләү чаралары ...........................................68
**Галиева К.** Равиль Бухараев – интеллектуальная гордость нации!.....................................70
**Галимбикова И.** Национальная и культурная идентичность в рамках межкультурного взаимодействия .............................................................................................73
**Галимова Д.** Лилия Гыйбадуллина иҗатында образлар бирелеше .....................................75
**Гарипова Д.** XIX гасыр татар һәм чуваш әдәби телләрендә фонетик вариантлар............77
**Гафарова А.** Язык жестов в произведениях Рината Мухаммадиева ..................................79
**Гафиятова И.** Габдулла Тукай һәм Ленар Шәехнең балалар өчен язылган шигырьләрендә тиңдәш кисәкләр.....................................................................................82
**Гафиятуллина Э.** Ә. Еники иҗатында фольклор традицияләре ..........................................84
**Гафурова И.** Татар теле дәресләрендә төбәк тарихына караган материалларны куллану ...........86

**Гәрәев А.** Флүс Латыйфинең «Хыянәт» романында тел-бизәкләү чарасы буларак искергән сүзләр ........................................................................................................88
**Гәрәева А.** Лингвокультурологик текстларның стилистик үзенчәлекләре ........................90
**Гетманская С.** Лингвокультурологический компонент в преподавании иностранного языка с помощью социальных сетей (на примере инстраграм) ..................92
**Гилмутдинова Ә.** Татарларда сәер исемнәр ...............................................................94
**Гыйздәтуллина Н**. Татар таҗына лаек олуг шәхесләр ..................................................96
**Гыймадиев Б.** Зөлфәт Хәкимнең «Телсез күке» драмасында символик образларның әдәби функциясе .........................................................................................98
**Гыйниятуллина Д.** Сынлы сәнгатьтә Бакый Урманче ...................................................100
**Гыйсмәтуллина Д.** Мансур Гыйләҗевның «Бичура» пьесасы буенча куелган спектакльдә Бичура мифологик образы ..........................................................................103
**Давлетзянов И.** Язык сказок Алиша и экологические задачи .......................................105
**Джумагалыева Р.** К вопросу о национальных особенностях языковой картины мира (на примере казахского и русского народов) ......................................................107
**Дурдыева М.** Язык и культура .......................................................................................109
**Евдокимова А.** Туфан Миңнуллинның «Гөргери кияүләре» этнографик музыкаль комедиясендә образлар бирелеше......................................................................................110
**Ержан Г.** Структура романа О. Уайльда «Портрет Дориана Грея» в свете философии Платона ..........................................................................................................112
**Ершова Е.** Универсальные черты и свойства «детства» в произведениях М. Горького .........................................................................................................................116
**Жалгасова Ж.** История изучения казахского народного лиро-эпоса «Кыз жибек».........118
**Жантасова Н.** Академик Р. Сыздық және қазақ тіл білімінің өзекті мәселелері .............120
**Жаскайратова А., Сарсенгалиева А.** Ауэзов и о переводе калмыцкого героического эпоса «Джангар» ........................................................................................122
**Җамалетдинова Д.** Юридик лексикада гарәп алынмалары ...........................................124
**Җиһаншина М**. Татар халык җырларының поэтик үзенчәлекләре.................................127
**Закирова А.** К проблеме исследования концепта «хлеб» в разных лингвокультурах 129
**Закирова Ә.** «Ватаным Татарстан» газетасында сәламәтлек темасына багышланган мәкаләләрнең үзенчәлеге .............................................................................132
**Зарипова З.** Проблемы переключения кода при обучении английскому языку (татар и русских).............................................................................................................134
**Зәйнетдинова Р.** Татар теле дәресләрендә аудиовизуаль чаралар ..................................136
**Зиннурова Э.** Формирование речевых компетенций на иностранном языке....................138
**Ибраһимова А.** Татар паремияләренең лингвокультурологик потенциалы .....................141
**Ибраһимова Д.** Әдәбият дәресләрендә нәзари төшенчәләрне өйрәнү ..............................142
**Ибраһимова Р.** Рабит Батулла иҗатында Тукай образы....................................................144
**Ибраһимова Э.** Кабатлаулы фигыльләрнең эмоциональ-экспрессив мәгънәләре ...........146
**Исламгареева Г.** Башкортостан Республикасы Шаран районы Күгәрчен-Бүләк авылы топонимикасы.............................................................................................................149
**Исламова Л.** Татар һәм казах телләрендә соматизмнар ...................................................152
**Исхакова Г.** Грамматические переводческие соответствия в переводах стихотворений А. Ахматовой на турецкий язык ..................................................................................154
**Кабдрашова М**. Қазақ тіл біліміндегі гендерлік зерттеулер ............................................156
**Кадыйрова Г.** Паремияләрдә хатын-кыз образы ...............................................................159
**Қазмағамбетова А.** «Қыз жібек», «Айман-шолпан» жырларының басылымдары жөнінде.............................................................................................................................161
**Камалдинова И.** Этикет татарского застолья в селе Токаево ..........................................164

**Камалова Д.** Лингвистик тикшеренү объекты буларак поэтик текст ....166
**Канапьянова Д.** Шәкәрім шығармашылығы – рухани білімнің қайнар бұлағы ....168
**Кашаева А.** Использование мнемотехнических приемов при обучении детей в школе ....171
**Каюмова А.** Роль родного языка при изучении иностранного языка на примере звуковых систем английского и татарского языков ....173
**Кәлимуллина А.** Гаяз Исхакыйның драма һәм проза әсәрләрендә милләт язмышы 175
**Кәримова А.** Мин кулыма китап алам ....178
**Көшімбет М.** М. Әуезов драмаларындағы вестиалды лексиканың рөлі ....180
**Құлмағамбетова Ж.** Жазба жәдігерлер тілі мен қазіргі қазақ тілі: ұқсастықтар мен айырмашылықтар ....183
**Құмарова Э.** Общая характеристика восточной поэмы «Гяур» Джорджа Гордона Байрона ....187
**Ли Цзюньин**. К вопросу семантизации национально-культурной единицы в современных словарях лингвокультурологического типа ....190
**Макаров И.** Технология обучения аудированию ....192
**Матигуллина Р.** Башкортостан Республикасы Балтач районы Югары Карыш авылы тарихы турында ....194
**Мингалиева К.** М. Хөсәеннең «Кытай дусыма» шигырендә тел-бизәкләү чаралары ....196
**Минемуллин Р.** Зөфәр Рәмиевның гыйльми эшчәнлегендә Габдулла Тукай энциклопедиясен төзү мәсьәләләре ....198
**Миннекеева А.** Кулинария текстлары тәрҗемәсендә транслитерация алымы ....201
**Миннибаева А.** Башкортстан Республикасы Ярмәкәй районы Абдулла авылы топонимикасы ....203
**Мисбахова С.** Матур әдәбият әсәрләрендә чагыштыруларны тәрҗемә итү үзенчәлеге (Г. Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» әсәре материалында) ....205
**Михайлов А.** Керәшен халкының йола, бәйрәмнәренә кагылышлы сынамышлар ....208
**Мойнакова А.** Қазақ тілі терминологиясының қазіргі жағдайы ....211
**Mohamed Lamine Mariko.** Understanding text complexity ....214
**Мөдәрисов Д.** Tatar-inform.ru. һәм bashinform.ru сайтларында кулланылган спорт лексикасының структур үзенчәлекләре ....215
**Мөхәммәдиева А.** Халкым өчен мәңге кирәк туган телем! ....218
**Мөхәммәтгалиева Г.** Аналитик һәм синтетик чараларны өйрәтү методикасы ....220
**Мөхәммәтшина А.** Фигыльләрнең кытай һәм татар телләрендәге урыны ....224
**Мухаметзянова Л.** Обучение языковым лакунам на основе текстовой деятельности 226
**Мухаметова И.** Особенности изучения религиозной лексики в современном татарском языке ....228
**Насыйбуллина К.** Татар телендә ризык атамалары системасы формалашу үзенчәлекләре ....230
**Низамиев И.** Р. Шәйдуллинаның «Ялантауга ай кунган» әсәрендә табигатьне саклау һәм кеше бәхете мәсьәләсе ....233
**Низамутдинова Э.** Лингвокультурологический компонент в преподавании иностранного языка с помощью подкастов (на примере немецкого языка) ....235
**Оспанова Ж.** О функциональном аспекте метафоры ....237
**Павлова З.** Тел – милләтнең кыйммәтле ядкяре ....239
**Пазюкова И.** Нәкый Исәнбәт – драматург ....242
**Рамазанова А.** Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романындагы этнолексика ....244
**Рамазанова Г.** Ф. Яруллинның әкиятләрендә хыял һәм чынбарлыкны бирүдә 246

тылсым элементлары.......................................................................................................
**Рамазанова Г.** Ф. Яруллин әкиятләрендә тел-стиль чаралары һәм алар аша дөньяны сурәтләү ...........................................................................................................248
**Рахматуллина Ф.** Лингвокультурологические особенности речевого акта «обещание»..............................................................................................................251
**Сабирова Н.** «Мәдәни җомга» газетасында теркәлгән кеше шәхесе белән бәйле атамалар ...............................................................................................................253
**Сабитова Л.** Ә.Еникинең «Матурлык» хикәясендәге фразеологизмнарны төрек теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре (Фатыйх Котлының «Güzellik» тәрҗемәсе нигезендә)................................................................................ 255
**Сағызбаева А., Ғалымжанова А.** Халық ауыз әдебиетінің әлеуметтік маңызы .............258
**Саетгараева Л.** Морфологические и синтаксические характеристики текста кулинарного рецепта (на материале поваренной книги Е. Молоховец) .............................259
**Сайфиева М.** Сравнительные конструкции как способ отражения языковой картины мира (на материале русского, татарского и английского языков) .......................261
**Салахова Т.** Чтение как вид речевой деятельности в обучении иностранному языку.....................................................................................................................263
**Саяпова В.** Образ праведника в русской и татарской прозе (на материале рассказа А.И. Солженицына «Матренин двор» и повести А. Гилязова «В пятницу, вечером») .........266
**Сэйфетдинова Д.** Әдәбият дәресләрендә фольклоризмнарны өйрәтү (Г. Тукайның «Шүрәле» әсәре мисалында)..............................................................................268
**Сәлахов Д.** Әмирхан Еникинең «Җиз кыңгырау» әсәрендә күрүне белдергән фигыльләр................................................................................................................271
**Сәлахова А.** Ф.С. Сафиуллинаның синтаксис өлкәсендәге хезмәтләре ............................273
**Сеэрмамайти Касэнму.** Отражение лексики словаря Махмуда Кашгари «Диван лугат ат-турк» в современном татарском языке.................................................275
**Сиразова С.** Татар халык мөнәҗәтләрен өйрәнү тарихыннан ............................................277
**Сулейменова А.** Қазақ әдебиеті сабақтарын интеграциялап оқытудың әдеби және әдістемелік аспектілері ....................................................................................279
**Сымахэцзань Илиясы.** Татар һәм казах лингвомәдәниятендә исәнләшү йолалары 281
**Сяфукатэ Иэрцзати.** Уйгырлар: мәдәният һәм сәнгать.......................................................283
**Тилеуова Н.** Көркем мәтіндегі кейіпкер бейнесі.................................................................284
**Тимашева А.** Башкортстан Республикасы Бакалы районы Яңа Маты авылында яшәүче керәшеннәрнең йола лексикасы ...........................................................................287
**Тимофеева Т.** Керәшен халык уен-бию җырларының һәм такмакларының поэтик эшләнеше (Кукмара районы Югары Чура авылы мисалында)............................................290
**Узум С.** Татар һәм төрек телләрендә исем сүз төркеме.......................................................292
**Уметбаева Н.** Номинация лиц в детской речи.....................................................................295
**Фаезова Л.** Репрезентация мотива странничества в творчестве М. Юныса.......................297
**Фазылҗанова Г.** Казан шәһәренең гастрономик туризм потенциалы ..............................301
**Фатыйхова И.** Психологик алым буларак тавыш (Шәриф Камалның «Курай тавышы» хикәясе мисалында) ..........................................................................304
**Фәсхетдинова А**. Бүгенге көн татар яшьләренең рухи-әхлакый кыйммәтләре (ассоциатив экспериментлар материалында)...........................................................306
**Фәттахова А.** Ф. Әмирхан иҗатында музыка тәнкыйте мәсьәләләре...............................308
**Фэн Юньхэ.** Национальная специфика образных сравнений (на материале повести А.И. Куприна «Поединок»)..............................................................................310
**Хаерова Л.** Аш-су рецептларының баш исемнәрен тәрҗемә итү үзенчәлекләре.............312
**Ханмурзин С.** Ренат Харис иҗатында туган телнең чагылышы ........................................314

**Ханмурзина Н.** Гөлнур Айзатуллова иҗатында сугыш темасы ........................................317
**Хасанзянова Г.** Особенности перевода экономических терминов с английского языка на русский язык ........................................................................................................319
**Хасбиева А.** Транслингвизм в изучении языков в би- и полилингвальной среде ............322
**Хасбиуллина Г.** Җиде саны мисалында тел һәм мәдәният бәйләнеше ............................324
**Хафизова Я.** Икетеллелек шартларында балалар сөйләмендә барлыкка килгән үзенчәлекләр .......................................................................................................................326
**Хәбибуллина А.** Татар халык мәкальләрендә ат образы .....................................................329
**Хәбибуллина А**. Фатих Әмирхан прозасында Казан образы................................................331
**Хәкимова Э.** Татар телендә капка лексемасы .......................................................................333
**Хәлилова Н.** Милли горурлык хисе тәрбияләүдә телевидениенең роле ..........................335
**Хөсәенова Р.** Айгөл Әхмәтгалиева хикәяләрендә сурәтләнгән дөнья................................337
**Хөсәенова Э.** Татар тел гыйлемендә текст теориясен өйрәнү тарихы ..............................339
**Хөснуллина А.** Ризык атамаларының йолалар белән бәйләнеше........................................341
**Хузиахметова Г.** Метод анкетирования, как способ выявления осведомленности населения о культурном наследии ........................................................................................344
**Һадиева А.** Прецедент исемнәр һәм метафора терминнары мәсьәләсе ............................346
**Чан Ваньцзюнь**. Особенности русской и китайской картины мира .................................348
**Чэнь Ясин.** Архетипические оппозиции в интернет-игре в антифразы............................350
**Шакирова Г.** Шәүкәт Галиев иҗатында күтәрелгән темалар ...........................................352
**Шакирова Ф.** Буа районы сөйләшләре ...................................................................................355
**Шәяхмәтова Г.** Башкортстан Республикасы Илеш районы Йонны авылы турында .......................................................................................................................................357
**Шәйхетдинова З.** Роберт Миңнуллин иҗатында әхлак темасы .......................................360
**Шәнгәрәева А.** Татар һәм башкорт тел белемендә тартыклар чиратлашуы очраклары ........................................................................................................................................361
**Юнысова Р.** Башкортстан Республикасы Илеш районы Югары Яркәй авылының годонимнары .................................................................................................................................363
**Ягафарова А.** Татар телендә ышанулар..................................................................................365
**Япбаров А.** Татар телендә «тамчы» концепты ....................................................................368

*Научное издание*

# ТЮРКСКАЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ: ПРОБЛЕМЫ И ПЕРСПЕКТИВЫ

Материалы XI Международной научно-практической конференции учащихся, студентов и аспирантов

Казань, 20–21 февраля 2020 г.

Подписано в печать 19.02.2020.
Бумага офсетная. Печать цифровая.
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Times New Roman».
Усл. печ. л. 21,86. Уч.-изд. л. 23,16.
Тираж 100 экз. Заказ 103/2

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии Издательства Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
тел.: (843) 233-73-59, 233-73-28